Борынгы татар ташъязмаларында иң еш урын алган Коръән аяте, төгәлрәк әйткәндә, аять өлеше – «Күллү нәфсиң зәәикатүл-мәүүт» («Һәр җан иясе үлемне татыячак») («Гыймран» сүрәсе, 185 нче аять; «Әнбия» («Пәйгамбәрләр») сүрәсе, 35 нче аять; «Ганкәбүт» («Үрмәкүч») сүрәсе, 57 нче аять). Ул Коръәндә өч урында искә алынган. Болгар ташларында аның «Әнбия» сүрәсендәге: «Сүммә иләйнә түрҗәгуун» дигән өстәмә өлешен дә китерергә онытмаганнар. Бу аять Алтын Урда чорыннан алып, XX гасыр башына хәтле һәрвакыт язылып килгән.

Шунысын да әйтеп узарга кирәк: кайбер эпиграфист белгечләр җөмләдә баш килештә торган «күллү» («көлле») сүзен ни өчендер «күлли» («көлли») дип укый. Шул үзенчәлекләрне белү бик мөһим, югыйсә гарәп җөмләләрен биргәндә күп кенә хаталар ясарга мөмкин. Мәгълүм ки, Коръәннең изге аятьләре, ислам дине буенча, бары тик тәҗвид кагыйдәләре буенча гына укылырга һәм язылырга тиеш, шуңа күрә аятьләрнең укылышын

тулысынча шуңа нигезләнеп бирергә кирәк. Шул сәбәпле, «күллү *нәфсин* зәәикатүл-мәүүт» дип уку дөрес булмый, чөнки «нәфс» сүзендәге тәнвинле «нүн» «зәл» хәрефенә очраганга күрә, «н» хәрефе «ң» хәрефенә әверелә. Коръәнне бозмау өчен бу бик мөһим һәм һәр эпиграфистка, гарәп телен белүдән тыш, тәҗвид кагыйдәләреннән дә хәбәрдар булырга кирәк.

Ташбилгеләр текстларында иң еш кулланыла торган аяти кәримәләрдән икенче урында «Күллү мән галәйһәә фәән» («Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани»), ягъни «Әр-Рахмән» («Рәхимле») сүрәсенең 26 нчы аяте тора. Болгар ташларында без бу изге аятьне, гомумән, очратмадык, ул XX йөз башына хәтле татар эпитафияләрендә актив кулланышта йөргән. Казан ханлыгы чорында бу сүрәнең 26 нчы аятенә «Вә йәбкаа вәҗһү Раббикә зүл-җәләәли вәл-икраам» («Фәкать Олуглык һәм хөрмәт иясе булган Раббыңның йөзе генә калачак») дигән 27 нче аятен дә өстәп язуны тиеш күргәннәр.

Өченче урында «Вә мәә тәдрии нәфсүм би-әййи әрдыйң тәмүүт» («Һичбер кеше кайсы җирдә үләчәген белмәс») («Локман» сүрәсе, 34) дигән изге аять саналырга хаклы. Ул да Алтын Урда чоры ташъязмаларында телгә алынмаган, димәк, Казан ханлыгы чорында гына ташбилгеләргә «Локман» сүрәсенең 34 нче аятен язу традициясе барлыкка килеп, XX гасыр башына кадәр актив кулланышта йөргән. Арча районы Кызылъяр авылы зиратындагы бер ташта аның оригиналь тәфсире дә китерелгән: «Һичкем белмидер: ята торган җире коры җирме, дәрьямы, тигез җирме, таудамы – кайда булачак [икәне] мәгълүм түгелдер».

Борынгы ташбилгеләрдә еш язылган аятьләрдән тагын «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи раажигуун» («Бәкара» («Сыер») сүрәсенең 155 нче аяте) дигән илаһи сүзләрне атап үтәргә мөмкин. Ул бигрәк тә XIX йөз ахырында – XX йөз башы ташъязмаларында киң кулланылган. Кайбер очракларда ташка язу осталары аны ташның йөзлегенә түгел, ә уң һәм сул якларына яза торган булганнар.

«Күллү шәйиң һәәликүн илләә вәҗһәһ» («Аның [Аллаһның] йөзеннән кала һәрнәрсә һәлак булучы») («Касас» («Хикәя») сүрәсе, 88 нче аять) Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорлары кабер ташларында язылмаса да, XIX гасырдан алып XX гасыр башына хәтле бик киң кулланышта булган, бигрәк

тә Казан арты төбәгендә әлеге аять язылган гаять күп сандагы эпиграфик истәлекләр сакланып калган.

Коръәннең иң беренче изге аяте – «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим» сүзләре – Алтын Урда чорыннан ук эпитафияләрдә кулланыла башласа да, XV–XIX гасырларда ул ташбилгеләрдә сирәк язылган. Ләкин XX йөз башында ул тагын актив кулланышка кереп, хәзерге эпитафик текстларда да иң күп язылучы бердәнбер аять буларак санала. Әгәр дә, гомумән, борынгы һәм хәзерге заман эпитафияләренең барысын бергә җыеп карасак, «бисмилла» кабер ташларында иң күп языла торган аять булыр иде, әмма без бу мәкаләбездә борынгы эпитафияләрне генә тикшерүне күздә тоттык.

Борынгы татар эпиграфик истәлекләрендә язылган Коръән аятьләре, әлбәттә, болар белән генә чикләнми. Бу алты аятьтән тыш, борынгы кабер ташларында чагыштырмача сирәк очраган тагын ике дистәгә якын төрледән төрле аятьләр язылганлыгын ачыкладык. Мәсәлән, «Бәкара» сүрәсенең 186 нчы һәм 255 нче («Аятел-көрси») аятьләре, «Шөгара» сүрәсенең 88 нче аяте, «Гыймран» сүрәсенең 194 нче аяте, «Бәни Исраил» сүрәсенең 84 нче аяте, «Фәҗер» сүрәсенең 27-30 нчы аятьләре, «Әнбия» сүрәсенең 89 нчы аяте, «Бүруҗ» сүрәсенең 12 нче аяте һ.б.

Борынгы татар эпитафияләренең кереш өлешендә кешене уйландыручы, ахирәтне искә төшерүче, Аллаһның кодрәтен күрсәтүче, тынычландыручы Коръән аятьләре урын алган. Аларның күбесе, традиция буенча, Алтын Урда чорларыннан алып XX йөз башларына хәтле кабер ташларында язылып килгән һәм кайберләре хәтта хәзерге көндә дә кулланыштан чыкмаган.

Ортодоксаль ислам дине кабер өстенә нинди дә булса таш куюга, корылма коруга тискәре караган [2, с. 18; 4, с. 277], кабер ташларына Коръәннән нәрсә дә булса язуны милләтебезнең мәшһүр дин галимнәре өнәп бетермәгәннәр. Мәсәлән, мөҗтәһид Ризаэтдин Фәхретдин түбәндәгечә язып калдырган: «Оренбург, Уфа, Казан шәһәрендәге каберлекләрдә гарәпчә язылган язулар бик күп күрелә. Бу да тиешсез эш. Кабер ташлары нотык һәм хөтбәләр язылачак дәфтәрләр, матур язу күнегүләре өчен кара такталар түгел. Шуның өчен мәрхүмнең исеме, гаилә һәм фамилиясе дөрес язылу, туу һәм вафат көннәре хатасыз теркәлү җитә» [5, б. 556]. Шул сәбәпледер, олуг галимнәр Ш. Мәрҗани (шул исәптән аның ата-анасы һәм

балалары), Р. Фәхретдин, Г. Баруди кабер ташларында Коръән аятьләре язылмаган.

Күргәнебезчә, борынгы татар эпитафияләре бик бай эчтәлекле булган: кабер иясе хакында гына мәгълүмат биреп калмыйча, ислам дине өйрәтмәләрен, фәлсәфәсен үз эченә алган төрле аяти кәримәләр белән бизәлгәннәр. Кабер ташы янына килгән кешене алар дингә өндәгәннәр, уйланырга мәҗбүр иткәннәр, шул ук вакытта якын кешеләрен югалткан бәндәләрне тынычландырганнар, үзенә күрә ниндидер бер психологик ярдәм күрсәтү функциясен үтәгәннәр. Шуңа күрә татарларда ташка язу сәнгате, үзенә генә хас үзенчәлекләргә ия булып, иң югары баскычларга ирешә алган, хәтта башка милләтләрнең эпитафик истәлекләренә дә йогынты ясаган.

**Әдәбият**

1. Гайнетдинов А.М. Борынгы татар эпитафияләренең структурасы һәм эчтәлеге // Актуальные проблемы современной фольклористики. Вып. 1. Казань: Ихлас, 2016. Б. 137–141.

2. Гайнутдинов А.М. Эпиграфические памятники Арского района Республики Татарстан // Материалы Конгресса исламской археологии России и стран СНГ. Казань: Институт археологии АН РТ, 2016. Б. 89–94.

3. Мухаметшин Д.Г. Татарские эпиграфические памятники. Региональные особенности и этнокультурные варианты. Серия «Археология евразийских степей». Казань: Институт истории АН РТ, 2008. Выпуск 6. 132 с.: с илл.

4. Поляков С.П., Черемных А.И. Погребальные сооружения населения долины Заревшана // Домусульманские верования и обряды Средней Азии. М.: Наука, 1977. С. 261–279.

5. Фәхретдин Р. Габдессәлам мөфтинең хәтер дәфтәре // Шура. 1913. № 18. Б. 555–557.

**Галләм Р.Г.**
**Казан**

# УРТА ГАСЫР ТӨРКИ-ТАТАР МӨСЕЛМАН КАБЕРТАШЛАРЫНДА АЛТЫ ПОЧМАКЛЫ ЙОЛДЫЗ СУРӘТЕ (ГЕКСАГРАММА):

## килеп чыгышы, таралышы һәм символик мәгънәсе мәсьәләләре

*В статье рассматриваются вопросы происхождения, распространения и символического значения шестиконечной звезды (гексограммы), встречающейся на татарских мусульманских намогильных камнях эпохи Средневековья.*

Төрки-татар, ислам символикасы, борынгы төркиләрнең ышанулары-күзаллаулары яссылыгында әлегә Урта гасыр төрки-татар каберташлары чагыштырмача аз өйрәнелгән. Һичшиксез, борынгы төрки-татар каберташларындагы төрле символик сурәтләр, тамгалар (шул исәптән, нәсел тамгалары да), башка төрле билге-бизәкләр, ул каберташларның формалары, эшләнеш рәвешләре, сыйфатлары-материаллары кебек үк, үзе бер гыйльми-гамәли мәгълүмат чыганагы булып тора.

Мәгълүм булганча, алты почмаклы йолдыз сурәте (яки гексаграмма, «Давид йолдызы», «Соломон мөһере» һ.б.) Урта гасыр төрки-татар кабер ташларында, бигрәк тә XIV гасырга – Алтын Урда дәүләте чорына караганнарында, әледән-әлегә очраштыргалый. Гомумән алганда, ул төрки, мөселман эпиграфикасы, шул исәптән, төрки-татар эпиграфикасы өчен дә ниндидер бер ят күренеш түгел. Мәсәлән, Красноярск крае татарларында каберташларына бу билгене төшерү гадәте безнең заманнарга кадәр сакланган.

Шул ук вакытта хәзер бу билге күбесенчә яһүдиләргә, яһүди дингә тәгаенләнгәнлектән, күп кенә милләттәшләрдә берникадәр гаҗәпсенү хисе дә уята. Әмма башлангыч чорда Яңа эрага кадәрле VII–VI гасырлардан ук мәгълүм бу билгенең яһүдиләргә дә, яһүди дингә дә катнашы булмый. Якын Көнчыгышта ул соңрак, б.э.к. IV гасыр ахырыннан – III гасыр башыннан башлап кына таралыш ала. Мәсәлән, борынгы Мисырда, Финикиядә ул кешелек яшәешендә матди, рухи башлангычларның бергәлеген чагылдырган. Моннан тыш, Якын Көнчыгышта, борынгы Фарсы илендә Астарта исемле алиһә культын гәүдәләндергән һ.б.

Җыеп әйткәндә, әле башлангыч чорда ук ул төрле өлкәләрдә – дин, им-том, тылсым өлкәләрендә, шулай ук башка максатларда кулланылган халыкара, универсаль бер символга әйләнә. Аның таралышы да Борынгы Һиндстан, Төркестан, Фарсы җирләреннән алып, Якын Көнчыгышка, Төньяк Африкага, Ауропагача була (мәсәлән, бу билгенең борынгы кельтларда да таралыш алганлыгы билгеле).

Бары тик Урта гасырларда, Ауропада Яңарыш чорыннан, якынча XIV–XV гасырлардан башлап кына ул яһүди диннең, яһүдиләрнең рәсми дини, милли символына әйләнә. Шул ук вакытта башка диннәрдә, илләрдә, халыкларда да киң кулланыла.

Шул рәвешле, алты почмаклы йолдыз ул бары тик яһүдиләрнең, яһүди диннең символы түгел, ә бәлки төрле кыйтгаларда, илләрдә, халыкларда, диннәрдә таралыш алган халыкара универсаль бер символ. Бу – төп нәтиҗәләрнең берсе. Аерым алганда, мәсәлән, ул символ индуслар динендә дә кулланыла һ.б.

Шул исәптән, VII гасырдан башлап, бу символ ислам динендә дә таралыш ала. Мәсәлән, алты почмаклы йолдыз (гексаграмма) сурәтен изге Кәгъбәнең ефәк япмасында да, изге китап Коръәндә дә (аерым алганда, мәсәлән, «Ясин» сүрәсендә), мәчет бизәлешләрендә дә, ислам диненә нисбәтле төрле басмаларда да очратырга була. Моннан тыш, аны үзләренең илаһи фәлсәфә эшчәнлегендә суфыйлар да куллана.

Димәк ки, бу символның Урта гасыр төрки-татар мөселман кабердашларында урын алуы да, бу вакытларда Урта Идел буенда исламның таралышы турында сөйли. Ул ташларда гарәп шрифтендә язылган борынгы язулар да мәрхүмнәрнең әһле ислам динендәге затлар булуы турында сөйли.

Инде хәзер исламның бер символы буларак, гексаграмманың асыл мәгънәсен дә шәрехләп китәргә тырышып карыйк. Инде әйтелгәнчә, борынгы Мисырда бу билге яшәештә матди, рухи башлангычларның бергәлеген аңлаткан. Моннан тыш, башка очракларда ул анда ир-ат һәм хатын-кыз яисә ут һәм су башлангычларының бергәлеген дә аңлаткан. Шул рәвешле, символ халыкларда төрле чорларда төрле сурәттә шәрехләнгән. Әмма аның асыл мәгънәсе уртак – яшәештә үзара капма-каршы башлангычларның бергәлеге: матди, рухи байлык, ир-ат һәм хатын-кыз, ут һәм су һ. б.

Тагын бер шундый сорау туа – ни өчен Урта Идел буендагы XIV гасырдан соңрак чорларга караган кабердашларда алты почмаклы йолдыз сурәте күренми диярлек? Башка мөмкин булган сәбәпләрдән тыш, моның геополитик сәбәпләре булуы да ихтимал. Чөнки, әйтелгәнчә, Ауропада Яңарыш чорыннан (XIV–XV гасырлардан) башлап, алты почмаклы йолдыз («Давид йолдызы») яһүдиләрнең рәсми символына әйләнү сәбәпле, мөселманнар белән яһүдиләрнең үзара капма-каршылыгына, тартышына бәйле, аның ислам дине тарафларында куллану сферасы берникадәр тарая төшкән булуы да ихтимал. Шулай да ул, элеккечә үк, ислам диненә хас символларның берсе буларак әле дә булса кулланылышта.

Йомгаклап шуны әйтергә була: әлбәттә, безнең бу нәтиҗәләр, фаразлар башлангыч, беренчел характерда. Күтәрелгән мәсьәлә алга таба да максатчан тикшеренүләрне, гыйльми эзләнүләрне сорый.

**Галимҗанова Э.М.**
**Казан**

## ФАЗЫЛ ТУЙКИННЫҢ СӘЕТ ВАХИДИГӘ ЯЗГАН ХАТЛАРЫ

*В статье освещается деятельность писателя, фольклориста Фазыла Туйкина (1887–1938) в качестве археографа. На примере двух писем, адресованных Саиду Вахиди, раскрывается интерес Ф. Туйкина к поиску рукописных произведений.*

XX гасыр башында яшәп иҗат иткән, күпкырлы эшчәнлек алып барган Фазыл Туйкинның милли тарихыбызны торгызуга, язма әдәбиятыбызны саклап калуга куйган хезмәте зур.

Ул – халкыбызның рухи байлыгын, гасырлар буена тупланып килгән уй-фикерләрен чагылдырган халык авыз иҗаты җәүһәрләрен җыйнап өйрәнүче галим. XVII йөз татар әдәбиятының күренекле вәкиле Мәүла Колый шигырьләрен табып, аларның суфыйчылык мотивлары белән иҗат ителүе хакында тәүге фикер әйтүче, Татарстанның Әлмәт районы Сөләй авылында XIX йөз урталарында яшәгән Вильдан Мөхәммәтьяров кебек әдәбиятыбыз тарихында аз билгеле булган шагыйрь турында мәгълүмат туплаучы, XVIII йөз татар тарихи ядкәре «Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе»нең борынгы бер нөсхәсен табучы да Фазыл Туйкин булды.

Галимнең бу өлкәдә актив эшчәнлек алып баруы Гыйльми Үзәккә һәм Татарстан җөмһүрияте Үзәк музеена юлланган хатларыннан ачык күренә [2; 6].

ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Сәет Вахиди фондында Фазыл Туйкинның ике хаты бар [6].

С.Вахиди 1926 елның 1 ноябреннән 1930 елның 1 сентябренә кадәр Үзәк музейның «Көнчыгыш кулъязмалары һәм документлары» бүлеген җитәкли һәм тарихыбызга караган экспонатлар, язма мирас туплау өстендә зур эшләр башкара.

«Өлкәне өйрәнү яки тарихи хатирәләрне өйрәнү һәм җыю эше белән кызыксынучы аерым кешеләр яки җәмгыятьләр»не барлау; «язма китаплар, урыс яки татар телендә язылган документлар яки шәҗәрәләр, иске хатлар» булдыру; «борынгы сугыш урыннары, искедән калган язулы кабер ташлары, тау тишекләре яки акчалар, кылыч, сөңге кебек кораллар табыла торган урыннарны» ачыклау һәм табылганнарын музейга алдыру; «борынгы гадәтләр, йолалар, им-том, ырым вә багу итүләр турында тулы мәгълүмат» алу; «1905–1917–1918 елларның революция тарихын өйрәнүдә нинди риваятьләр һәм документлар бар» һ.б. шундый мәгълүмат һәм материаллар туплау йөзеннән ул, анкета төзеп, илнең төрле почмакларына тарата. 1929 елның 23 сентябрендә төзелгән әлеге анкета 12 пункттан гыйбарәт була [3, б. 36–41]. Әлеге эш үзенең яхшы нәтиҗәләрен бирә. С. Вахидигә илнең төрле почмакларыннан меңләгән хатлар килә башлый. Шулар нигезендә күп кенә экспедицияләр оештырыла, шактый мәгълүмат, матди һәм язма мирас туплана.

Ф. Туйкин хатларының беренчесе – 1929 елның 8 декабрендә язылган һәм «Татарстан Үзәк музее Шәрекъ кулъязмалар бүлеге мөдиренә» дип юлланган [6, б. 61]. Эчтәлегеннән күренгәнчә, хат анкетага җавап рәвешендә язылган. Анда Фазыл Туйкин үзенең бу өлкәдә инде 18 елдан артык хезмәт итүе һәм шактый гына материаллар туплавы хакында яза. «Гәбдрәхмән волостендәге Мачкара елгасы башыннан табылган айбалта (Чынгыз гаскәре коралы)», «Тымытык волосте Урсай авылында кантон булып торган *(туктап торган мәгънәсендә)* Нугайбәкнең 18 уклы, көмеш белән бизәлгән садагы *(җәя һәм ук савыты),* ау карчыгасы бәйләре, Екатерина II нең Урманай һәм Уразай дигән башкорт атамаларына карата язылган манифесты, Уразай һәм Урманай картның Чалпы авылына (Бөгелмә кантоны) биргән җир мөгаһадәсе *(килешүе)* кебек тарихи материаллар табылуы хакында сүз бара. Ул, аларны югалтудан куркып, Бөгелмәдә татар клубы каршында оешкан «Шәрык музее»на тапшыруын әйтә. Кызганычка каршы, «хәзер аннан җилләр исә, кая киткәнен белүче дә юк» дип, аларның аянычлы язмышын җиткерә.

Билгеле булганча, 1920 елларда ук Үзәк музей белән берәттән кайбер районнарда да музейлар эшли башлый. Хәтта

Үзәк музейдан кайбер экспонатларның район музейларына вакытлыча бирелеп торуы да мәгълүм [4, с. 55]. Әмма Идел буенда хөкем сөргән 1921 елгы ачлык нәтиҗәсендә әлеге музейларның күбесе ябыла [4, с. 56]. Бөгелмә шәһәре музее да шул агымга эләгә. 1929 елның ахырыннан шәһәрдә янәдән музей эшли башлый. Бу хакта К.Р. Синицынаның «Полвека музеев Казани и Татарии. Очерки истории 1917–1967 годов» исемле китабында болай диелә: «В Бугульме отделение Общества изучения Татарстана вновь создало музей в октябре 1929 года, выделив средства на его организацию. В музее было собрано около 1400 предметов и открыто шесть отделов. Наиболее богатым был историко-культурный отдел, содержавший 613 предметов: оружие, украшения, монеты и т.д.» [4, с. 77].

Ф. Туйкинның музейга материалларны кайсы елларда тапшыруы хакында мәгълүмат юк.

Әлеге хатында ул шулай ук «Идел буеның беренче шагыйре Мәүла Колыйның 1858 елда Вильдан мулла каләме белән күчерелгән китабы, «Исмәгыйль сәяхәтнамәсе»нең башкорт балалары (*фетнәләре*) чорында ук гаепләнеп асылган Сәлимулла каләме белән язылган нөсхәсе», 1815 елда Мәүла Гыйрфан каләме белән күчерелгән Габдерәхим Утыз Имәнинең 1797 елда Бохарадан кайтканда «Каурмач» илендә үлеп калган хатыны Хәмидәгә багышлап язылган «Мәрсияи Хәмидә, зәүҗәте Габдерәхим әл-Болгари» исемле мәрсиясе һәм «Француз сугышы бәете»нең 1858 елгы нөсхәсе кулында булуы хакында да яза.

Икенче хат – 1930 елның 9 апрелендә «Татарстан җөмһүриятенең Үзәк музеена, С.Г. Вахидигә» юлланган [6, б. 72]. Бу хат җавап алынганнан соң язылган булырга тиеш. Чөнки ул «Минем җавапларыма каршы музей идарәсенең 1930 елның 9 гыйнварында 232 сан белән җибәргән мөрәҗәгатен мин бары 27 мартта гына алдым», – ди. «Хәзерге көндә минем кулымда булган тарихи материаллар бары язма әсәрләр генә» дип, беренче хатта телгә алынган 4 кулъязма әсәрне (җыентыкны) Үзәк музейга җибәрүен хәбәр итә. «Боларның кайчан, кайдан табылулары, кайчан, кем тарафыннан язылулары һәм эчләрендәге материалларның содержаниеләре, һәркайсы җыентыкның үз янына информация рәвешендә язылып теркәлгән» дип белдерә. Алга таба да бу юлда эш алып барылуын искәртеп: «Бөгелмә

кантонының тарихи урыннарын һәм тарихларын тикшерүне дә дәвам итәм», – ди ул. «Революция тарихына бәйле булган “Солдат вакыйгалары”, Кама елгасы буеннан табылган мамонт сөякләре, Мачкара елгасы башыннан табылган сигәй-айбалталар *(борынгы корал)*. Ул мәсьәләләр өстендә эшләүне сорыйлар әле» дип, киләчәктә дә бу өлкәдә эшләнәсе эшләрнең күплеген билгеләп үтә.

С. Вахидигә язган әлеге кыска гына хатлардан да Ф. Туйкинның бу өлкәдә күпме дәрәҗәдә зур эш башкарганлыгын күрергә мөмкин. Ул алып барган археографик эзләнүләрнең мәдәни мирасыбызны баету һәм киләчәк буыннарга җиткерү юлындагы әһәмияте зур. Шуңа да аның бу өлкәдәге эшчәнлеге тарихыбыз битләрендә үз урынын тапты.

**Әдәбият**

1. Борынгы Болгар шагыйре // Кызыл Татарстан. 1926. 9 апрель.
2. Отдел рукописей и редких книг Научной библиотеки Казанского федерального (Приволжского) университета. № 938Т. С. 1–22.
3. С. Вахиди тарафыннан төзелгән анкета // Духовное наследие: поиски и открытия / под ред. И.Г. Гумерова. Казань: ИЯЛИ. 2017. Вып. 4. 280 с.
4. Синицына К.Р. Полвека музеев Казани и Татарии. Очерки истории 1917–1967 годов. Казань: «KAZAN-Казань», 2002. 280 с.
5. Тузанлы шүрлекләрдән // Безнең юл. 1928. № 9.
6. ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. 53 ф., 4 тасв., 19 сакл. бер., 61, 72 кәг.

**Гараева Н.Г.**
**Казань**

## САИД ВАХИДИ – СОБИРАТЕЛЬ РУКОПИСЕЙ

*Рукописная коллекция археографа Саида Вахиди, которую он собирал и исследовал около четверти века, вошла в фонды шести современных учреждений России: библиотек, академических институтов, музея. По примерным подсчетам, она включала свыше трех тысяч «названий сочинений и различных записей». В статье представлен предварительный обзор материалов этих коллекций.*

Татарский историк и педагог Саид Вахиди[1] (1887–1938 гг.) потомкам больше известен как неутомимый и удачливый археограф, делом жизни которого стали целенаправленный сбор и изучение рукописных книг и документов на арабской графике – письменных источников по истории и книжной культуре татарского народа.

Понимание ценности рукописных книжных памятников у С. Вахиди без сомнения сформировалось и систематизировалось в 1905–1911 годы, когда он учился в Казани в медресе «Мухаммадийа», шакирдом которого стал в возрасте 18 лет. Влияние Галимджана Баруди (1857–1921), основателя и руководителя медресе, собравшего богатейшую библиотеку рукописных и печатных книг, стало заразительно определяющим. В годы прибывания в Казани С. Вахиди оказался в среде образованной и реформаторски настроенной татарской интелегенции. Это была эпоха перемен, связанных с событиями Первой русской революции (январь 1905 г. – июнь 1907 г.) и последовавшей за ней реакции. Буржуазно-демократические свободы, ставшие итогом революции, открыли возможность для стремительного становления татарской периодической печати, на страницах которой обсуждался широкий спектр проблем, давно волновавших татарское общество России. Одной из постоянно обсуждаемых тем на страницах таких журналов, как «Ад-Дин ва-ль-адаб» (Религия и нравственность), «Дин ва магыйшат» (Религия и жизнь), «Шура» (Совет), многочисленных татарских газет, стал вопрос сохранения письменного наследия народа и его доступности в бесплатных общественных библиотеках, которых в начале XX века в России для татар не было. Только с предоставлением гражданских прав и свобод всем слоям населения Российской империи впервые в Казани удалось добиться открытия Мусульманского отделения Казанской городской публичной библиотеки, получившего известность с названием «Кутуп-хане исламия» (январь 1906 г.)[2]. Ахмад-Хади Максуди (1868–1941), возглавивший инициативную группу, которая обратилась к властям

[1] Саид Габдульманнанович Вахидов – современная устоявшаяся орфография имени и отчества С. Вахиди. В личных рукописях С. Вахиди прописывал свое имя как Сейид Габдульминанович Вахидов [13].

[2] На открытие этого отделения Казанская городская дума выделила 590 рублей [8].

с ходатайством о создании казенной библиотеки для татар, видел в открытии «Кутуп-хане исламия» символ возрождения легендарной библиотеки сейида Кул Шарифа, живущей в народной памяти и утраченной во время осады Казанского Кремля в 1552 году.

После завершения учебы в медресе С. Вахиди приступил к учительской работе. В 1912 г. ему удалось открыть в родном ауле русско-татарскую начальную школу, позднее он учительствовал в новых школах в округе Мамадыша. С назначения учителем в третью Казанскую школу в 1914 г. он ведет занятия по татарской литературе и истории тюрко-татарских и русского народов.

Одновременно с педагогической деятельностью С. Вахиди целенаправленно и систематически продолжает свои научные исследования в области археографии. Одной из наиболее значительных находок С. Вахиди становится обнаруженный у Рахматуллы агая, жителя аула Мамалай в округе Мамадыша (современное Мамалаево Сабинского р-на), неизвестный науке того времени редчайший документ периода Казанского ханства – подлинник тарханного ярлыка, выданного в 1523 г. Сахиб-Гирей-ханом татарским феодалам. Вначале в большой спешке С. Вахиди удалось сделать лишь копию с этого документа, которая с согласия С. Вахиди, была включена в материалы книги Х. Атласи «Казанское ханство». С началом первой мировой войны С. Вахиди оказался на передовой. В фронтовых условиях к нему пришло понимание итогов революции 1905 года, что нужно для просвящения «темного» народа и возрождения угнетенной нации, достижения социальной справедливости, прекращения империалистической войны. Поэтому после событий февральской революции он с большим энтузиазмом воспринял победу Октябрьской революции.

После возвращения с фронта С. Вахиди с увлечением принялся за учебно-просветительскую работу. В 1918–1920 гг. работал лектором на краткосрочных педагогических курсах, готовивших по ускоренной программе учителей для новых, только открывающихся, многочисленных школ; участвует в открытии подобных курсов в Спасском, Лаишевском и Мамадышском кантонах. С октября 1919 г. до конца 1921 г. преподает на рабфаке Казанского университета. Начиная с этого времени С. Вахиди активно сотрудничает с возникающими в Казани научными объ-

единениями или обществами, такими как Татарский Академический центр, Научное общество Татароведения, Общество научного исследования Татарстана, Общество археологии, истории и этнографии при Казанском университете. В 1919 году Вахиди начинает системные археографические разыскания и разрабатывает специальное методическое пособие для выезжающих в экспедиции – «Анкета по поиску, сбору и изучению исторических рукописей». После создания в 1928 году при Обществе научного исследования Татарстана специальной археографической комиссии С. Вахиди поручается сбор и исследование рукописей. В 1930 г. после открытия научно-исследовательского экономического института Татарстана С. Вахиди поступает туда на работу. Со второй половины 30-х годов он возглавляет отдел в Центральном (Государственном) музее Татарстана.

Независимо от места работы С. Вахиди всегда занимается сбором и исследованием рукописей. Наиболее значительных успехов в археографической работе С. Вахиди добивается после Октябрьской революции. Самым крупным его успехом остается ярлык Сахиб-Гирей-хана, исследованием которого по-настоящему ему удалось заняться только в советское время. Во время разъездов по делам просветительской работы С. Вахиди вновь оказывается в ауле Мамалай и на этот раз ему удается убедить Рахматаллах агая передать ему свиток ярлыка. В течение следующих четырех-пяти лет С. Вахиди занимается тщательным исследованием документа [4–5]. Сведения, обнаруженные в ярлыке, способствовали формированию более полных представлений об аграрных отношениях Казанского ханства. Достоверность сведений ярлыка Сахиб-Гирей-хана об общественно-социальном устройстве Казанского ханства была полностью подтверждена обнаруженными позднее актами правителя Казани Ибрагима и официальными документами Крымских ханов [2–3; 8; 10; 16; 17].

Интерес С. Вахиди к сбору рукописей, начавшийся в 1905 г., способствовал формированию у него к середине 20-х годов XX века личной коллекции, обширной по количеству рукописей и чрезвычайно ценной по ее качественному составу. В то время сохранить подобное собрание в частном владении было немыслимым, поэтому, осознавая это, С. Вахиди 10 февраля 1925 г. подарил более 200 рукописей и документов (в том

числе и ярлык Сахиб-Гирей хана) на восточных языках в отдел восточных рукописей Центрального музея ТР через Академический центр Татнаркомпроса[1].

В 1929 г. С. Вахиди участвует в комплексной экспедиции Научного общества Татароведения по исследованию Мензелинского кантона.

В 1930 г. (5 августа) создан Татарский Научно-исследовательский экономический институт, для укрепления его научно-исследовательской базы С. Вахиди вновь безвозмездно передает из своей коллекции 1127 рукописей (лично составив инвентарную опись переданных книг) [10, 16].

В 1934 г. С. Вахиди передает часть собранных им рукописей в Ленинградское отделение Института востоковедения АН СССР. Об этом факте сообщает Вали Забиров (ум. 1939) в Отчете о деятельности Археографической экспедиции АН СССР, в котором он характеризует цели экспедиции в условиях жесткой антирелигиозной идеологической политики государства. «В 1930 г. Азиатский музей АН СССР был реорганизован в Институт востоковедения. Хотя в связи с реорганизацией изменились цели и задачи учреждения, а также расширился фронт его деятельности, вопросам пополнения фондов придавалось столь же серьезное значение, как и прежде. Но если прежде стоял вопрос главным образом о пополнении фондов, то теперь речь шла о спасении национального богатства – культурного наследия многих народов, входящих в состав СССР, в частности народов Кавказа и Закавказья, Поволжья и Средней Азии. В 1934 г. в Татарскую АССР была направлена Археографическая экспедиция Академии наук, в состав которой входили научный сотрудник ИВ АН СССР В.А. Забиров и казанский ученый, библиофил, краевед и историк С.Г. Вахидов. Эта экспедиция приобрела для Института 1564 рукописи (включая 362 единицы собрания, подаренного Институту самим С.Г. Вахидовым). 17 декабря 1934 г. В.А. Забиров выступил с отчетом о результатах экспедиции на объединенном заседании Группы историков, социологов и экономистов с Группой востоковедов

[1] Однако вскоре этот отдел был расформирован, а коллекция рукописей предположительно была передана в библиотеку Казанского университета (возможно, одновременно с коллекцией А.Ф. Лихачева).

при Президиуме АН СССР. Было принято решение «продолжить работу по выявлению и собиранию рукописей, включив в нее уже не только Татарскую АССР, но и все Поволжье, вплоть до Астрахани, охватив Башкирию и полосу по р. Уралу» [12, с. 281].

Жизнь С. Вахиди оборвалась на пике его профессиональной зрелости и активности: он был необоснованно репрессирован (арестован 29 ноября 1937 г., растрелян 5 января 1938 г.).

Собранные С. Вахиди в течение более 25 лет рукописи в настоящее время рассеяны по фондам нескольких учреждений России: Института восточных рукописей РАН, Отдела рукописей Российской национальной библиотеки, Национального музея РТ, Отдела рукописей и редких книг Научной библиотеки им. Н.И. Лобачевского КФУ, Центра письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, Центральной научной библиотеки Казанского научного центра РАН.

Подсчитать общее количество рукописей и документов, собранных С. Вахиди, пока не представляется возможным, поскольку еще не завершено исследование основных комплексов, переданных им археографических материалов. Поэтому мы все еще оперируем примерными цифрами: согласно доступным на сегодняшний день данным, общее число может составлять свыше 3000 названий сочинений и документов [16]. Трудность подсчетов связана с несогласованностью принципов учета. Составленные С. Вахиди описи показывают, что С. Вахиди считал сочинения рукописи по их названиям, а не книжные блоки рукописей. При таком подсчете количество названий сочинений в несколько раз могло превысить число рукописных книг. Материалы археографической экспедиции ленинградского Института востоковедения учитывались по рукописным книгам. Как известно, далеко не всегда одна рукописная книга содержит текст одного сочинения, часто это – сборник, в котором приведены несколько сочинений. Следовательно, количество сочинений несомненно превысит общее число рукописей, привезенных экспедицией.

Согласно составленной С. Вахиди машинописной описи, он пожертвовал Научно-исследовательскому экономическому институту «восточных рукописей и различных записей в количестве 1000 названий» [13]. Поскольку здесь речь очевидно

идет о названиях сочинений, то можно смело количество книжных блоков, как минимум, уменьшить на треть, т.е. это чуть больше 700 рукописных книг. Опись отражает репертуар сочинений коллекции С. Вахиди, которые после переформирования НИЭИ оказались в библиотеке Казанского университета. Упомянутая опись содержит отнюдь не краткий перечень переданных сочинений, а развернутые описания с сопоставлением текстов по имеющимся в библиотеке университета классическим справочникам – «Кашф аз-зунун ʻан ал-асами кутуб ва-л-фунун» («Раскрытие мнений относительно названий книг и отраслей наук») Хаджи Халифы (1609–1657) и «Каталогу арабских рукописей библиотеки Берлина» Вильгельма Альварта (1828–1909) [17]. Среди описанных С. Вахиди сочинений – широко известные арабские трактаты «ʻАкаид ʻадудиййа» [13, с. 105], «Шарх ал-викаййа» [13, с. 88], «Кади Мубарак» [13, с. 107], «Аййуха ал-валад» [13, с. 107], а также популярные у татар «Ахыр заман китабы», «Кисек баш китабы», «Бадавам китабы» [13, с. 108], экземпляры «Йусуф китабы» Кул Гали, «Киссас ал-анбиййа» Наср ад-дина б. Бурхан ад-дина Рабгузи [13, с. 143], «Мухаммадиййа» [13, с. 187] и др.

Из заявления о пожертвовании, направленного в ТНИЭИ в августе 1930 года, понятно, насколько С. Вахиди было нелегко расстаться с коллекцией, изучение которой было в разгаре и он горел желанием его завершить. «Занимаясь в течение 18 лет собиранием и изучением восточных рукописей и документов, часть которых с ценнейшим памятником эпохи Казанского ханства – ярлыком Сахиб Гарей хана – я пожертвовал в Центральный музей Т.С.С.Р.», – писал С. Вахиди. – «В настоящее время в ознаменование X-летия Т.С.С.Р. и открытия первого в Т.С.С.Р. научно-исследовательского института приношу в подарок Институту коллекцию восточных рукописпей и различных записей в количестве 1000 названий с тем, чтобы дать возможность широким массам трудящихся и научных работников использовать их значительную ценность. Ввиду того, что я занимаюсь научной работой и собиранием этих материалов, я не успел дать их необходимое научное описание и произвести исследования большинства из них, я считаю нужным выставить следующие условия передачи: 1. [обеспечить] хранение этого собрания полностью в Институте; 2. их публикация допустима лишь с

моего ведома; 3. предоставить мне возможность, как знатоку этого дела, описание, исследование и публикацию как своего собрания, так и собрания Центрального музея; 4. [а также описание, исследование и публикацию материалов] Мензелинской экспедиции». Он настаивал на своём преимущественном праве при обработке «не только по праву их собирания, но и потому, что мною уже обработано и опубликовано несколько ценных документов» [4–7], исследование которых получили «хорошие отзывы как в местной, так и в столичной печати» [13].

Арабские и тюркские рукописи ИВР РАН, одного из богатейших рукописных собраний России, каталогизированы [1; 11]. По этим каталогам из всего рукописного собрания Института еще предстоит выделить и проанализировать материалы рукописей, переданных С. Вахиди в ЛО ИВ АН СССР. В числе 362 рукописей[1], переданных С. Вахиди, 181 рукопись содержит сочинения на арабском языке, остальные – сочинения на персидском и тюркском языках. Не менее трети всех этих рукописей – сборники произведений и различных выписок. Нередко в сборник включались сочинения, написанные на разных языках. Большая часть арабских рукописей содержит широко распространенные в мусульманской традиции сочинения. Например, «Шарх бад’ ал-амали» [1, A1036], «Джами‘ ар-румуз» [1, D471], «Шарх ‘ала-л-мулхас ли-л-Чагмини» Мусы Кади-заде ар-Руми (ум. после 830/1427) [1, A1061]. К редким рукописям его собрания можно отнести датированный 973/1565–66 годом автограф (чистовой вариант) сочинения Пир-Мухаммада б. Мустафы б. ал-Халила ар-Руми «Китаб рах ал-кулуб» – краткая переработка «Марах ал-арвах», посвященного султану Селиму II [1, A1056]. Среди этих рукописей имеются списки произведений татарских алимов. Печатью С. Вахиди отмечены список 1854 года «Шарх ал-‘акаид ан-насафиййа» (Комментарий на «Догматы [веры]» ан-Насафи), «Шарх мухтасар ал-манар» (Комментарий на сокращение «Ал-Манар»), «Иршад ал-муридин» (Наставление мюридам) Абу-н-Насра ‘Абд ан-Насира ал-Газани ал-Булгари [ал-Курсави] [1, A1058]; «Му‘джизат ан-набий» (Чудеса Пророка) ‘Убайдаллаха б. Са‘да ал-Булгари;

[1] Профессор М.А. Усманов указывает 500 рукописей, переданных С. Вахиди [10, 16]. Возможно, он имел в виду перечень названий сочинений в переданных рукописях.

фрагмент сочинения Ш. Марджани – «Нубза мин вафиййат ал-ахлаф ва тахиййат ал-ахлаф» [1, В2667], содержащая биографию Хусейна Фейзханова (ум.1283/1866-67), а также автограф «Мунтахаб вафиййат ал-аслаф ва тахиййат ал-ахлаф» Ш. Марджани [1, В2675].

В отличие от вышеназванных собраний, переданных С. Вахиди государству в 20–30-е годы XX века, Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ обрел свою часть рукописей собрания С. Вахиди 20 ноября 1962 года: его вдова передала хранившуюся в семье часть коллекции С. Вахиди в библиотеку КФ АН СССР. Позднее эта коллекция поступила в Архив ИЯЛИ КФ АН СССР.

В Центре по неполным данным хранится около 140 рукописей из коллекции С. Вахиди (в составе 39-го фонда). Специальное исследование этой коллекции С. Вахиди пока не завершено. Коллекция содержит сочинения на арабском, персидском и тюрко-татарском языках по фикху, догматике, логике, сборники хадисов, тафсиры и многое другое в ближневосточных, среднеазиатских и местных списках. Относительно ранними списками представлены «Тафсир ал-Куран» Абу-л-Лайса ас-Самарканди, «Китаб ал-мустасфа» (Книга очищения) ан-Насафи. К интересным рукописям можно отнести «Китаб ал-муфрадат» [14, Д240]; красивый османский список «Тафсир ат-тибйан», датированный 1248/1832–33 годом [14, Д279]; список «Фатава татарханиййа», составленный в 1013/1604 году [14, Д285], список «Китаб ал-хидайа» ал-Маргинани 1111/1699 года. Среди этих рукописей есть раритеты, например, рукопись XIV в. на персидском языке сочинения по математике Хасана б. ‘Али ал-Касани (ал-Кашани) «Китаб ал-муршид фи-л-хисаб» (Книга, направляющая в счете). В современных казанских коллекциях она в числе немногих рукописей, имеющих миниатюру [14, Д263]. К значимым рукописям относится цензорский экземпляр «Мукаддимы…» – изданной части (введения) сочинения Ш. Марджани «Вафиййат ал-аслаф…». Среди персоязычных сочинений собрания С. Вахиди – поволжский список 1158/1745 года «Персидско-турецкого словаря» (Лугат Ни‘маталлах), составленного в 977/1540–41 году Ни‘маталлахом б. Ахмад б. Мубарак ар-Руми (ум. 969/1561–62) [14, Д225; 9, с. 112–113]; переписанный в 1285/1868 году в Бухаре муллой

Хусам ад-дином б. дамулла ‘Абд ал-Вали ал-Казани ал-Булгари ал-Бадал-Биги список сочинения Камал ад-дина Карима Нагури «Маджму‘ хани фи ‘илм ал-ма‘ани» (Ханское собрание [фатава] для одоления знаний со скрытым значением) (14, Д263; 9, с. 130–131); список рубежа XVI–XVII веков «Кимийа-и са‘адат» (Элексир счастья) – персидского переложения сочинения Абу Хамида ал-Газали «Ихйа’ ‘улум ад-дин» (Воскрешение наук о вере) [14, Д283; 9, с. 139–140].

ЦНБ КНЦ РАН располагает небольшой коллекцией мусульманских рукописей, которые явно случайно остались в библиотеке КФ АН СССР после передачи основного объема рукописного собрания в архив ИЯЛИ КФ АН СССР. Среди них есть две рукописи, отмеченные владельческой печатью С. Вахиди. Одна из них – рукописный сборник (антология!?) поэтических произведений Сулеймана Бакыргани (ум. 1086 г.), ученика и последователя Ахмада Ясави (1103–1166), одного из первых суфийских мистиков тюркоязычного мира. В Поволжье поэмы С. Бакыргани были популярнее, чем произведения его наставника. В сборник, названный «Кул Сулейман Бакырган китабы», включены следующие произведения, написанные на чагатайском языке: «Ярты алма», «Марьям-ана», «Ахыр заман», «Такий ‘аджиб» и другие [18, лл. 2б–66б]. Список, составленный каллиграфическим насталиком[1] на тонкой среднеазиатской бумаге, датируется концом XVII века[2] (по оценке

---

[1] Стихотворный текст, записанный черными чернилами, обведен рамкой красными чернилами. Проставлены кустоды.

[2] Рукопись была сильно повреждена, реставрирована несколько раз. Из-за влаги смазаны чернила на части листа, текст поврежден [18, лл. 25а–28а, 32б, 45б, 48б, 61б–66б]. Часть повреждений бумаги были искусно починены заплатами из среднеазиатской бумаги, относительно соответствующей оригинальной бумаге [18, лл. 2–4, 8–9, 25, 66–67 и др.]; полностью заменены российской, плотной мануфактурного производства (первой половины XIX в.) бумагой, текст восстановлен другим переписчиком [18, лл. 19–24]; Последняя реставрация была выполнена с использованием бумаги промышленного производства [18, л. 19], вклеены два листа [18, лл. 1, 69].

Среднеазиатский переплет. Обложки из тисненного картона. Бордовые кожаный корешок и края обложки. Верхняя обложка потеряна. Кожа по краям повреждена, а по нижнему краю отпала.

З. Максудовой[1]). В рукописи сделана запись о владении рукой С. Вахиди [18, л. 2а], сделан оттиск владельческой печати С. Вахиди [18, л.66б]. Рукой С. Вахиди поставлен «номер 170»; чуть ниже синим карандашом поставлен номер «276» [18, л. 2а][2].

В фондах РНБ (С. Петербург) хранится отмеченный владельческой печатью С. Вахиди список сочинения Ш. Марджани «Ал-‘Азб ал-фурат ва-л-ма’ аз-зулал ан-наки‘ ли ‘илла раввам [ал-абрар ли асрар] шарх ал-Джалали» (Вкусное свежее питье, утоляющее жажду стремящихся раскрыть тайны «Шарха» Джалал [ад-дина]) [15].

По сохранившимся в архивах личным записям С. Вахиди, видимо, можно восстановить перечень рукописей его коллекции до того, как он передал ее по частям в разные учреждения. Собранные С. Вахиди рукописи отличают качественные характеристики – в преобладающем большинстве это рукописи, составленные татарскими копиистами в Поволжье на российской бумаге. Как коллекционер он искал редкие тексты или тексты сочинений татарских алимов; его интересовали редкие списки известных сочинений (автографы, протографы); или рукописи, ценные своим художественным оформлением. С. Вахиди, видимо, не собирал арабографичные печатные книги.

С. Вахиди собрал десятки рукописных списков таких татарских литературных памятников, как «Кисса-и Йусуф» (Сказание о Йусуфе) Кул Гали, «Нахдж ал-фарадис» (Врата рая) Махмуда б. ‘Али ас-Сараи ал-Булгари, «Кисса-и ики булбул» (Повесть о двух соловьях), рукописи сочинений Г. Курсави, автографы Ш. Марджани и Каюма Насыри и многих других известных татарских алимов.

---

[1] Рукопись, видимо, детально была исследована известным коллекционером и знатоком мусульманских рукописей З. Максудовой (1897–1980). Есть подписанная ею запись о предполагаемой датировке списка [18, л. 66б]. Этим же почерком, сделана запись о расхождении с текстом издания 1913 г. Текст на реставрированной странице восстановлен ее рукой [18, л.19а].

[2] Есть отметки и записи, сделанные до С. Вахиди: оттиск печати в дореволюционной орфографии (с «Ъ»): «Х.Х. Бакировъ» [18, л. 66б]; запись о том, что книга осталась в наследство Мансуру и Мухаммаду от матери [18, л. 9а]; а также другие пометки и записи на татарском языке разными почерками (разных людей?) [18, л. 1а–2а; л. 69а–б].

Современные цифровые технологии позволяют соединить разрозненные части большого рукописного материала, собранного С. Вахиди почти за четверть века разысканий. Реконструкция его коллекции позволит получить полное представление о содержащихся в рукописях сочинениях и ценности его собрания. Исследование всего комплекса материалов, собранных С. Вахиди, – необходимая репрезентативная составляющая для воссоздания характерной для татар книжной культуры во всех гранях ее проявления.

**Литература**

1. Арабские рукописи Института востоковедения Академии наук СССР: краткий каталог. Под редакцией А.Б. Халидова. Части 1–2. М.: Наука, Главная редакция восточной литературы. 1986. Часть 2. С. 199.

2. Ахметзянов М.И. Первый татарский ученый археограф (к 100-летию Саида Вахиди) // Научный Татарстан. 1997. № 2. С. 87–89.

3. Ахметзянов М.И. Мәдәни мирасыбыз сакчысы (Сәет Вахиди) // Татарстан. 1997. № 5. С. 36–41.

4. Вахидов С. Исследование ярлыка Сахиб-Гирей-хана // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казанском Университете, т. 33, вып. 1, 1925. С. 61–92.

5. Вахидов С. Ярлык хана Сахиб-Гирея // Вестник научного общества Татароведения. 1925. № 1–2. С. 29–37.

6. Вахидов С. Татарские легенды о прошлом Волжско-Камского края. Казань, 1925.

7. Вахидов С. Мәрҗәни көтепханәсе һәм аның соңгы язмышы // Безнең юл. 1929. № 6–7. Б. 14–17.

8. Гараева Н. Г. Библиотека Вахиди С. // Татарская энциклопедия. Казань, 2002. Т. 1. С. 369.

9. Гилязутдинов С.М. Описание рукописей на персидском языке из хранилища Института языка, литературы и искусств. Выпуск II. Казань, 2006. 191 с.

10. Госманов М.А. Сәет Вахидиның игелекли мирасы // Казан Утлары. 1987. № 5. Б. 164–168.

11. Дмитриева Л.В. Описание тюркских рукописей Института востоковедения РАН. М.: Восточная литература РАН. 616 с.

12. Забиров В.А. Предварительное сообщение о работе Археографической экспедиции Академии наук // Исторический сборник. 1935. № 5. С. 281.

13. Заявление Вахиди С.Г. в ТНИЭИ [о пожертвовании рукописей и документов] // НБ КФУ, ОРРК, 1012Т.

14. ИЯЛИ АН РТ, Центр письменного и музыкального наследия, Ф. 39.

15. Российская национальная библиотека, Отдел рукописей, Ар.н.с. 550.

16. Усманов М.А. Вахидов (Вахиди) С.Г. // Татарская энциклопедия. Казань, 2002. Т. 1. С. 549. Собрал свыше трёх тысяч древних рукописей.

17. Фатхи А.С. Описание рукописей Научной библиотеки имени Н.И. Лобачевского. Вып. V. Рукописи татарских писателей и ученых. Первая часть / отв. редактор А.Г. Каримуллин. Казань. 1960. С. 7–12.

18. Центральная научная библиотека Казанского научного центра РАН.

19. Ahlwardt W. Handschriftenverzeichnisse der Königlichen Bibliothek zu Berlin: Verzeichnis der arabischen Handschriften. 10 Bände. Berlin, 1887–1899.

**Ибрагимов М.И.**
**Казань**

# ЛЕКЦИИ ПО ФОЛЬКЛОРУ КАЗАНСКИХ ТАТАР ГАЛИ РАХИМА КАК ИСТОЧНИК ПО ТАТАРСКОЙ ФОЛЬКЛОРИСТИКЕ

*В статье исследуются рукописные стенограммы курса лекций «Фольклор казанских татар», прочитанного татарским ученым Гали Рахимом в 1923 году в Восточном педагогическом институте. Определяются теоретические и методологические основы лекционного курса. Устанавливаются основные вопросы, освещаемые в рамках лекционного курса.*

В фонде Гали Рахима в Центре письменного и музыкального наследия ИЯЛИ «Мирасханә» сохранились лекции Г. Рахима по фольклору казанских татар [1].

Этот материал представляет собой ученические тетради (всего пять тетрадей), в которых содержатся стенограммы лекций, прочитанных Г. Рахимом в 1922/23 уч. году на отделении Востоковедения Казанского Восточно-педагогического института.

На обложках тетрадей указаны фамилия и инициалы стенографировавшего лекции студента – К.А. Шриро.

В архиве Восточного педагогического института среди отчетов преподавателей отделения Востоковедения за 1922/

1923 уч. год содержится отчет Г. Рахима о прочитанном им курсе. Из отчета следует, что Г. Рахим разработал этот лекционный курс за короткое время и курс читался им только в продолжение второго семестра, а в начале июня 1923 года был закончен. «Предложение о чтении этого курса, – пишет Г. Рахим в своем отчете, – было сделано мне только в конце первого семестра, вследствие отъезда профессора С.Е. Малова, которому он был поручен. Таким образом, я приступил к чтению лекций только по окончании зимних каникул».

Первая тетрадь с лекциями на титульном листе содержит дату – 4 марта 1923 года, которая, очевидно, и является датой начала всего курса. В одной из тетрадей (ед. хр. 36) содержатся материалы к курсу лекций, включающие датируемое 8 июня 1923 года «послесловие» к прочитанному курсу, оглавление, материалы к первой и одиннадцатой лекциям. Таким образом, уместно предположить, что курс читался с марта по июнь 1923 года.

Замандашлары хакында хатирәләр белән танышканда бер кызыклы фикергә юлыгырга туры килде. Б. Урманче татарның күренекле актрисасы Фатыйма Ильская хакында хатирәсендә

түбәндәге фикерен яза: «Ф. Ильская талантлы булса да, белеме уку-язудан артмаган шәхес», – ди. Гомумән, Б. Урманче белемле, киң карашлы, зыялы, эрудицияле шәхесләрне хөрмәтли, аларга күбрәк өстенлек бирә, шулар белән күбрәк аралашырга тырышкан. Әлеге фикерне яшь рәссамнарга карата язылган язмалары да раслый. Аның фикеренчә, яшь рәссамнар тема табалмыйча тилмерә, ә төп сәбәп итеп иҗатчының белемсезлеге, тар фикерле булуын күрсәтә. Нигездә, аның аралашкан кешеләре дә зыялы, татар, рус һәм башка халыкларның талантлы шәхесләре. Хәтта, үзенең күңеле тартмаган, сай карашлы кешеләрнең портретларын да ясарга алынмый.

Замандашлары турында сүз алып барабыз икән, архив чыганакларын күзәткәндә, Б. Урманченең гомер юлы һәм иҗат процессында азмы-күпме роль уйнаган шәхесләр, XX гасырны иңләгән дәһшәтле тарих белән дә очрашабыз. Ул үзенең «Кыска хатирәләр» исемле язмасында һәрбер шәхескә аерым бәя биреп уза. Кайсыберләренә киңрәк туктала, кайсыларын бер яисә берничә җөмлә белән генә искә алып китә. Бу хатирәләр архивта гарәп алфавиты тәртибендә төзелгән. Алар шактый күп, бу урында, татар мәдәнияте тарихында күренекле эз калдырган бары берничә фамилияне генә искә алып китү мәслихәт булыр, мөгаен. Башта кыска гына искәрмә дә кирәктер: Б Урманче 1907–1914 елларда Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. «Хатирәләр» арасында үзе белән бергә «Мөхәммәдия»дә укып, соңыннан татар халкы тарихында күренекле урын алган С. Вахиди, К. Тинчуриннар хакында тарих өчен кызыклы мәгълүмат бирә. «Хатирәләр»дә XX гасыр башында татар мәдәниятендә танылган шәхесләр – Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Г. Идриси, Г. Баруди һ.б белән дә очрашабыз, бу шәхесләрнең шәхси сыйфатларын күз алдына китерәбез. 1919 елда сәнгать мәктәбендә укыганда бөек рәссам Николай Фешин һәм сынлы сәнгатькә юл ачкан башка остазлары белән дә танышабыз, гомумән, «Хатирәләр» XX гасырның күренекле шәхесләре, тарихи вакыйгалары турында Б. Урманченең шәхси фикерләре аша бәяләнә, шуңа карамастан алар бүген кыйммәтле чыганаклар буларак хезмәт итәргә лаек. Гомумән, «Хатирәләр»дәге шәхесләрне санап бетерү мөмкин дә түгел. Шуны да ассызыклап үтү кирәк: шәхес кемнең кем булуына карамастан, ул, якын-тирәгә, мохиткә, кешеләргә күп очракларда субъектив

була. Б. Урманченең язмалары да шулардан азат түгел. Бу адымны гаепләп тә булмый шикелле. Автор шәхесләргә карата бары шәхси фикерен генә яза.

Б. Урманче иҗатында зур урын алган Тукай образына аерым тукталып үтәргә кирәк. Рәссам XX гасырның 20 нче елларында ук Мәскәүдән укуын тәмамлап кайту белән, Тукай рәсемнәрен, әсәрләрендә гәүдәләнгән образларын һәм басылган китапларына иллюстрацияләр ясый башлый. Соңрак Тукайның бюстын, скульптурасын, Кырлайдагы мемориал музеенең архитектура комплексын төзүдә турыдан-туры катнаша һәм җитәкчелек итә. Бу эшкә аңа шактый көч куярга туры килә. Ул проектның да караламалары архивта шактый очрый.

Мәгълүм ки, Б. Урманче 1941 елның башында Мәскәүдән Казакстан хөкүмәте чакыруы буенча иҗади командировкага китә. Рәссамга казак халкының бөек әдибе Абайның портретын һәм скульптурасын эшләү бурычы йөкләнә. Ул Абай картинасын һәм скульптурасын, аның образын ача алырлык бик күп материаллар туплый, эскиз һәм рәсем караламалары ясый. Берничә варианты Казакстан рәссамнар берлегенә тәкъдим ителә. Кызганыч, соңыннан аның эшләрен үткәрмиләр. Архивта Б. Урманченең Казакстан мәдәният министрына атап язган гаризасында бу факт бөтен нечкәлеге белән тасвирланган һәм ул шәхес хакында «Кыска хатирәләр»гә дә теркәп калдырырга онытмаган.

Бу темага кагылганбыз икән, совет системасында бүген дә уңай яктан искә алырлык күркәм традицияне язып үтмичә булмастыр, мөгаен. Совет идарәсе хакимлек иткән елларда әдәбият һәм сәнгать әсәрләре коллектив һәм сәнгать берлекләре аша җентекле тикшерелеп, шул ук вакытта объектив һәм субъектив тәкъдимнәр белән узган. Б. Урманче эшләре дә әлеге таләпләрдән азат булмаган, әлбәттә. Мәсәлән, скульптура әсәрләреннән Абай һәм Галимҗан Ибраһимовка багышлап ясалган эшләре рәссамнар берлегендә тикшерелеп, камилләштерү кирәклеге әйтелә. Скульптор ул тәкъдимнәрне кабул итеп, эшен дәвам иткән. Шул заман өчен бу гадәти күренеш саналган.

Б. Урманче 1929 елның август аеннан 1933 елның декабренә кадәр Мәскәүдә Бутырка һәм Соловки төрмәләрендә утыра. Архив материаллары арасында рәссамның бу чорны чагылдырган истәлек язмалары да сакланган. Төрмәдә кемнәр белән

утыруы, аралашуы хакында да мәгълүматлар бар. Алай гына түгел, төрмәдә бергә булган һәм заманында танылган төрек-татар, рус, немец һәм башка милләт вәкилләренең танылган шәхесләрен күрсәткән исемлекләр, кем кайткан, кем калуы турында искәрмәләр дә бирелгән. Ул исемлекләр шактый озын – 20–30 чамасы шәхес искә алына. Б. Урманче төрмә һәм сөргеннән исән-имин кайта, яраткан эше белән шөгыльләнүен дәвам итә. «Кыска хатирәләр» арасында кызыклы истәлек белән очрашырга туры килде. Татарстан автономия республикасы төзелү белән 1920–1924 елларда ТАССР Җир эшләре халык комиссары вазифасын башкарган Юныс Вәлидев рәссамның Мәскәүдә укыган вакытында очрашуында, Б. Урманчедән партиядә тору-тормавы белән кызыксына. Һәм соңыннан ул, иҗат белән шөгыльләнәсең һәм талантыңны үстерәсең килсә, партиягә кермә, дигән фикер әйтә. Рәссамның партиягә кермәве, бәлкем, аның төрмәдән сау-сәламәт кайта алуына бер сәбәп тә булгандыр.

Иҗат кешесе бары тик үз өлкәсенә караган материаллар белән генә чикләнә алмый. Аны мәдәниятнең күп төрле темалары, проблемалары кызыксындыра, шулар буенча материаллар җыя, саклый. Алар арасында аеруча Б. Урманченең рухына җавап биргән, С. Рәмиев һәм Дәрдемәнд (Закир Рәмиев) иҗатлары хакында материаллар туплаган. Шуны да искәртү кирәк: ике талантлы шагыйрьнең шигъриятенә гашыйк шәхес, үз шигырьләрендә күп очракта аларның шигъри алымлары, стильләрен кабатлый. Материаллар арасында Дәрдемәнднең шәхесе, балалары турында истәлекләр, аларның хатлары саклана. Рәссам татарның күренекле архитекторы, хәзерге Әтнә районы Олы Мәңгәр авылында туган, Мәскәү архитектура институтында профессор дәрәҗәсенә ирешкән, СССРда күп кенә төзелеш архитектурасының авторы, аның җитәкчесе булган Исмәгыйль Гайнетдиневнең иҗат мирасына карата да материал җыйган, аның басылып чыккан хезмәтләре, архитектура әсәрләренең исемлекләре, тәрҗемәи хәле турында язмалар туплаган, хәтта ул материаллар арасында Б. Урманченең И. Гайнетдинев хакында язылган мәкаләсенең каралама варианты да сакланган. Шунысы ачык: киңкырлы рәссам һәм скульптор заманы өчен әһәмиятле саналган проблемаларга бервакыт та битараф кала алмаган. Болар – шуның бер дәлиле.

Архив чыганакларын күзәткәндә тагын бер мөһим проблемага игътибар итмичә булмый. Б. Урманче татар халкының милли йола, традицияләренең борынгылыгын саклануын теләде. Аның язмалары арасында Сабан туе һәм Җыен йолаларына карата язган мәкаләләре саклана. Рәссам сабан туе һәм җыен йолаларының Тау ягында ничек үткәрелүе, аның икесе ике нәрсә булуына басым ясый, ике бәйрәмне чуаш халкының милли йолалары белән чагыштыра, шунда ук кыскача тарихын да әйтеп уза.

Иҗатчының эше һәрвакыт уңай яктан гына искә алынган яисә уңышлар белән генә барган дисәк, безнең тарафтан зур ялгышлык булыр иде. Б. Урманче дә – тормышның вак проблемалары, шәхесләр арасында барган интригалар һәм идеология корбаны. Җәмгыять һәм тормышның язылмаган кануннарын рәссам да сикереп чыга алмаган. Бу фикергә дәлил булырдай мисаллар Урманченең иҗат дәверендә шактый булган. Аның берсе, югарыда атап үткәнчә, Абай скульптурасына бәйле килеп чыккан проблема. Казанга кайту белән дә андый каршылыклар дәвам итә. Беренчедән, рәссамнар берлегендәге атмосфера, икенчедән, иҗат эшчәнлегенә киртәләр кую, заказлар, алар өчен вакытында акчасын ала алмау, скульптура әсәрләре өчен төзелеш материалларын табу һәм башка мәсьәләләр килеп чыга. Әлеге проблемалар турында рәссамның зары шул заманда Татарстан Министрлар кабинетында рәис урынбасары вазифаларын башкарган Мансур Хәсән улы Хәсәновка атап язган күләмле хатында ачык күренә. Болар – Б. Урманченең иҗат лабораториясен тикшерүчеләр өчен кыйммәтле чыганаклар.

Б. Урманче – XX гасыр башы иҗтимагый хәрәкәте һәм мәдәни мохитендә формалашкан шәхес. Ул татар халкының милли һәм мәдәни үсешенә шул күзлектән чыгып кына бәһа бирә, шуны гына таләп итә ала. Рәссам тел проблемасына да шул яктан гына якын килә, тел һәм сүзнең мәгънәләрен аңламауларын тәнкыйтьли. XX гасырның 50–80 елларында еш кына матбугатта тел проблемасын күтәргән мәкаләләр басылган. Бу бәхәскә рәссам да кушыла. Архивтан аның бу проблемага караган мәкаләләре, язмалары өчен туплаган материаллар да урын алган, алар кызыклы һәм дәлилле. Мәгълүм ки, Дәрдемәнд шигырьләренең беренче китабы латин графикасында 1929 елда һәм икенче тупланмасы 1959 елда дөнья күрә. Б. Ур-

манче 1907–1914 елларда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укып, гарәп-фарсы телләрен яхшы белгән шәхес буларак, бу басмаларга кергән шигъри әсәрләрнең дөрес укылышын, астөшермәләргә сүзләрнең мәгънәләрен аңлатудагы җитешсезлекләрне китапка карандаш белән теркәп барган, алай гына түгел, карточка да тутырган. Алар – филологлар, текстологлар өчен шактый кызыклы чыганаклар. Гомумән, рәссамны татар теленең сүз байлыгы, мәгънә тирәнлеге, этимологиясе кызыксындырган.

Киңкырлы талант иясе рәсем, гомумән, сынлы сәнгать белән генә шөгыльләнгән дисәк, ялгыш булыр. Инде бу хакта алдарак искә алып үтелсә дә, кабат кабатларга туры килә. Б. Урманченең  иҗат мирасы әдәбият, тарих белән бергә үрелеп барган. Мәсәлән, заманында мөселман һәм төрки дөньяга, шул исәптән татар халкына да мәгълүм, яратып сөйләнгән һәм укылган Ләйлә һәм Мәҗнүн дастанын төрек теленнән тәрҗемә итеп, Ф. Әхмәтова дастаннар тупланмасында бастыра. Әлеге күркәм эшнең дәвамы – ХХ гасыр башында Риза Фәхретдин тәрҗемәсендә басылган, Болгар дәүләтенә ислам динен алып килгән Ибне Фазланның сәяхәтнамәсен, күп кенә чыганаклар белән чагыштырып һәм күләмле генә кереш мәкалә язып матбугатка әзерли. Бу материалларның каралама вариантлары гарәп графикасында архивта саклана.

Б. Урманче озын һәм катлаулы гомер юлы узган шәхес. ХХ гасырның 60 еллар ахырында сәламәтлеге, аеруча аяклары сызлап борчый башлый. Больницаларда озаклап дәвалануга карамастан, нәтиҗәләр уңай булмый. Ул төрле кешеләрдән, чыганаклардан үз авыруына карата рецептлар туплый башлый. К. Насыйриның медицинага багышланган «Хифзысыйхәт» исемле хезмәтеннән дә шактый рецептлар күчереп ала.

Фондта рәссамның васыятьнамәсе белән дә танышырга мөмкин. Алар берничә вариантта һәм берничә нөсхәдә. Васыятьнамәдән күренгәнчә, ул беренче чиратта, үзенең эш коралларын, картиналарын саклау һәм тиешле урыннарга тапшыру, кирәк булганда сатуны хатыны Флора Әхмәтовага тапшыра. Улы Айдарны тәрбияләү, укытуны да аңа йөкли. Васыятьнамәләр арасында вафатыннан соң ничек күмәргә кирәклеген язганы да сакланган. Аның буенча, тавышсыз, музыкасыз, митинглар ясамыйча  гына күмү тиеш булган. Гомумән, мөселманнарга хас йолалар белән озатуны күздә тоткан. Бу хакта

Б. Урманченең шәхси архивында 1958 елда ук язылган «Васыять» исемле шигыре дә сакланган.

Күзләрем бу дөньяга йомылса,
Каным җансыз, дәртсез суынса,
Барабаннар кагып,
зинһар,
йөрмәгез.
Акырын, Тәңремнең дәргяһенә *(ишек төбе, сараена)*
лаек,
Тын гыйбадәт белән җирләгез.
Мөселман мин,
Тәмам исламча күмегез.

Чынлыкта исә рәссамның әлеге васыяте үтәлми – Б. Урманчене Г. Камал театры фойесында күпсанлы халык һәм чыгышлар, музыка белән соңгы юлга озаталар.

Гомумән, Б. Урманченең шәхси архивында сакланган материаллар, татар мәдәнияте өчен кыйммәтле чыганаклар болар белән генә чикләнми, әлбәттә. Әлеге кыска гына чыгыш-мәкаләдә алар хакында өстән-өстән генә язарга, шулар нигезендә азмы-күпме фикер белдерергә туры килде. Татар сынлы сәнгатенең нигез ташларын салучыларның берсе булган Б. Урманче турында сүз алып барганда милли сынлы сәнгатьнең барлыкка килү тарихына да тукталырга кирәк саналды.

Кыскасы, татар халкының Бөек шәхесе Габделбакый Идрис улы Урманченең шәхси архивын эшкәртү, системага салу эше әле башланып кына килә. Киләчәктә архив материаллары арасында рәссамның шәхесен, күпкырлы талантын ачкан документлар тагын да табылыр, алар Б. Урманченең бөеклеген, шәхесен мәңгеләштерүдә зур роль уйнар, чөнки фондны тәртипкә китерү барышында Б. Урманче шәхесе, иҗади таланты бүген дә Татарстан хөкүмәте тарафыннан тиешле югарылыкта бәяләнмәгән дигән фикер кала. Киң катлау укучыга аның хезмәтләрен пропагандалау проблемасы әле хәл ителгәнме соң? Архив белән танышканда бу сорау да ачык кала. Бер үк вакытта бөек рәссам һәм скульптор, портретлар һәм графика остазы, совет идеологиясе корбанына әйләнгән, ислам мәдәниятендә рәсем сәнгатенең гүзәл үрнәге саналган, гарәп язуының каллиграфик сәнгатен озак еллардан соң татар сынлы сәнгатенә

кабат кайтаручы һәм остазы, шагыйрь һәм тирән аналитик фикерле галим, күп телләр белгән полиглот, музыкант һәм музыка белгече, шул ук вакытта көчле тавышлы талантлы җырчы була алган рәссам, әдип яисә галимне татар халкы бүген хәтерлиме икән?! Юктыр, мөгаен. Башка милләтләр дә андый феноменаль талантның барлыгы ишетелгәне юк кебек. Гомумән, Б. Урманче Табигать-Ана тарафыннан бүләк ителгән, төрле яктан камил үскән, иҗат иткән бөек талантлы шәхесләрнең берсе. Аның исеме, бүген инде татар халкы һәм мәдәниятенең символик образлары югарылыгына күтәрелгән Г. Тукай, М. Җәлил, С. Сәйдәшевләр белән янәшә торырга тиеш. Күпкырлы талант, бай эрудициясен искә алганда, аларга караганда күпкә өстен шәхес икәнен дә онытырга ярамас. Шәхси архив белән танышканда шундый нәтиҗәләр ясарга һәм фикер чыгарырга туры килде.

**Насыйбуллина Н.Ш.**
**Казан**

## XVIII–XX ГАСЫР ТАТАР МӘДӘНИЯТЕНДӘ ЭСТӘРЛЕБАШ МӘДРӘСӘСЕ

*В статье рассматривается роль Стерлибашевского медресе как одного из центров исламского образования XVIII–XX вв. Определяется вклад династии Тукаевых (Нигматуллиных) в развитии татарского просветительства.*

Эстәрлебаш төбәге борынгыдан мәгърифәтле як булганы тарихыбызга яхшы мәгълүм. Эстәрлебаш мәдрәсәсе үз вакытында дөньякүләм мөселман халыкларын агартуда мөһим урын тота, иң данлыклы, иң мәшһүр уку йортларының берсе булып танылa.

Унтугызынчы гасырга кадәр ике мең кешесе булган авылда кырыкка якын мәдрәсә эшли. Тирә-якта яшәгән халыкларның аң-белемен үстерүгә шагыйрьләр, җәмәгать эшлеклеләре, руханилар Утыз Имәни (1754–1836), Хөснетдин Жданов (1767–1869), Әбелмәних Каргалы (1782 –1833), Һибәтулла Салихов (1794–1869), Зәйнулла ишан Хосраушир улы Галикәй, Әхмәтгали (казак мәдрәсәсе хәлфәсе), Гали Чалатай (казак мәдрәсәсе хәлфәсе), Шәмсетдин Зәки (1822–1865), Мөхәммәтъяр хәлфә,

Мөхәммәтхафиз хәлфә, Халиулла хәлфә, Гали Чокрый (1826–1889), Мифтахетдин Акмулла (1831–1895), мулла һәм таш язу остасы Габдулла Тукаев, Мирсәет Солтангалиев (1892–1940), Гали Рафикый (189–1944), Төхфәт Янәби (1894–1938) көчле йогынты ясый.

Эстәрлебаш авылының иң беренче имамы – Монасыйп мулла, чукындырудан качып, Казан ягыннан килә. Авылда беренче мәчет һәм мәдрәсә 1724 елда төзелә дип фараз ителә.

Эстәрлебаш мәдрәсәсеннән белем алып чыккан шәхесләр бөтен тирә-якта мөгаллимлек итәләр. Гыйлем учагы буларак танылган мәдрәсәнең зур үсеш чоры 1800 елларга туры килә.

Бохарага барып укып кайтканнан соң, Нигъмәтулла Биктимеров (Тукаев) 1812 елда мөдәррис итеп тәгаенләнә һәм гомеренең соңгы көненә кадәр (1842) шушы вазифаны үти. Нигъмәтулла мәдрәсәнең абруен күтәрү өчен зур тырышлык куя. Ул иң беренче чиратта хәлфәләрне һәм шәкертләрне һәртөрле дәреслекләр, уку китаплары белән тәэмин итәргә тырыша. Мәсәлән, җәмәгать эшлеклесе, педагог, «Тарихи Эстәрлебаш» китабының авторы Мөхәммәтшакир Тукаев: «Нигъмәтулланың үз кулы белән язылган мәҗмугаләре бар... Эстәрлебашта язылган һәм Бохарадан алдырылган күп кулъязма китаплар бүгенге көнгә кадәр саклана», – дип яза [3].

Нигъмәтулла хәзрәт китап туплауга зур игътибар биргән, үзе дә күчереп язган, кешеләрдән дә яздырган, Бохарадан да алдырган: «“Китаплар хасил итү өчен, күп иҗтиһад вә маллар сарыф әйләгән” Эстәрлебаш мәдрәсәсе аның вакытында Казан, Оренбург, Уфа, Әстерхан, Урта Азия якларында үзенең кулъязма һәм басма китапларының күплеге белән данлыклы булган», – дип язды күренекле замандашыбыз Зәки Зәйнуллин [1].

Нигъмәтулла үлгәннән соң мөдәррислек вазифасы аның өлкән улы Мөхәммәтхариска (1810–1870) күчә [7]. Бу чорда шәкертләргә белем бирү күзгә күренеп яхшыра. Ул мәдрәсә тормышына тәүге карашка бик сәер, мөселман схоластикасы белән бик үк ярашмаган яңалыкларны кертә. Мөхәммәтхарисның хәлфәләр һәм шәкертләр арасында абруе шул кадәр көчле була, ул керткән үзгәрешләргә фанатик дин әһелләре дә каршылык күрсәтергә батырчылык итмиләр.

Мөхәммәтхарис Тукаев: «Россия мөселманнары өчен дәүләт телен белү лазим», – дип, мәдрәсәдә рус телен укыту өчен

аерым мөгаллим тота, шәкертләргә русча газета уку да бик кирәклеген аңлап, «Голос» газетасын алдыра һәм анда язылганнарны махсус тәрҗемәче ярдәмендә шәкертләргә җиткерә [6].

Мәдрәсә мөдәррисе заманы өчен атаклы булган язучышагыйрьләрне, шәкертләрне укытырга җәлеп итәргә тырыша. Мәсәлән, күренекле суфый шагыйрь Шәмсетдин Зәки (1825–1865) үзенең туган авылы Зәк Ишмәттән (Оренбург өязе) бөтен шәкертләрен ияртеп, Эстәрлебашка күчеп килә һәм гомеренең соңгы көненә кадәр шунда укытучы булып эшли. Бөре өязенең Иске Чокыр авылында туган шагыйрь Гали Чокрый да (1826–1889) 1849 елда Эстәрлебашка килеп, мәдрәсәдә белем ала һәм шунда ук Шәмсетдин Зәки белән хәлфәлек тә итә.

Бу шәхесләр Көнчыгыш һәм Европаның алдынгы язучылары, галимнәре белән якын бәйләнештә булалар. Шиһабетдин Мәрҗани үзенең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» дигән китабында түбәндәгеләрне яза: «Мелла Нигъмәтулла бине Биктимер бине Тукай бине Урманай әл–Эстәрлебаш чыгышы белән Казан иленең Малмыҗ өязе Салавыч карьясеннән... Дөньясы киң, шәкертләре күп була. Үз илендә чиктән тыш шөһрәт казана. Габделнасыйр әл-Курсави карашларын яклаучылардан һәм аның дусларыннан була» [2].

Риза Фәхретдинов үзенең «Асар»ында: «Нигъмәтулла хәзрәтнең дөньясы иркен, шәкертләре күп, якыннары хисапсыз, абруе югары, үзе чиксез диндар, дин юлындагы тугрылыгы белән көчле, данлыклы, атаклы, шөһрәтле булдыгыннан моның заманасында Эстәрлебаш карьясе дәрелгыйлем, ягъни югары белем бирү урыны булды», – дип яза [5].

Нигъмәтулланың ике улы (Мөхәммәтхарис белән Мөхәммәтхаррас) булып, шуларның икенчесенең улы Мөхәммәтшакир (1862–1933) Тукаев II–III Дәүләт Думасына әгъза итеп сайлана [3]. Халкыбыз галимне беренче чиратта тарихчы буларак кабул иткән. Аның китапларында Эстәрлебаш төбәгенә кергән авыллар, алардагы мәчетләр, мәдрәсәләр, анда укыткан шәхесләр, аларның нәсел шәҗәрәләре тарихларына караган мәгълүматлар урын алган. Бу безнең өчен әйтеп бетергесез хәзинә, Эстәрлебаш тарихы нәкъ менә аның 1899 елда Казанда нәшер ителгән «Тарихи Эстәрлебаш» исемле хезмәтенә таянып язылა.

Мәдрәсәнең китап фонды да заманы өчен ифрат бай була. Анда көнчыгыш илләрдән килгән кулъязма һәм басма китаплар

күп тупланган. Аларның байтагы сәяхәт, хаҗ сәфәрләре, кәрванчылар аша килгән булса, күпчелеге күчереп алынган, һибә кылынган (бүләк ителгән) китаплардан гыйбарәт булган. Моның шулай икәнлеге хакында Рәмиевләр тырышлыгы белән чыга башлаган «Вакыт» газетасының 1913 ел, 9 июнь санында академик В. В. Бартольдның Оренбургтан Уфага сәяхәте хакында язылган мәкаләдән укып белергә мөмкин. «В.В. Бартольд мәдрәсә китапханәсен актарып, 200–300, хәтта 500 ел элек язылган кулъязма китапларны дикъкать вә ләззәт белән караган», – дип яза газета [6].

«...Эстәрлебаш Рәсәй Европасындагы мөселман фәненең иң төп үзәкләренең берсе, – дип яза азактан В.В. Бартольд үзе. – Мәдрәсә китапханәсеннән тыш, кулъязмалар XIII гасырга карый. Миңа Шаһрух солтанның (1407–1447) мөһере басылган кулъязмасын күрсәттеләр» («Аннотированная библиография трудов В.В. Бартольда», с. 327–328).

Эстәрлебаш мәдрәсәсендә күп тапкырлар булган Ризаэддин бине Фәхретдин, Нигъмәтулла хаҗи китапханәсендә һиҗри 787, икенчесе 785 елда язылган кулъязма китаплар бар иде, ди. Ягъни алар XIV гасырга караган китаплар [4].

Нигъмәтулла гарәп-фарсы телләрен, грамматика нигезләрен өйрәнү барышында күнекмә, нәхү, сарыф буенча да кулъязма китаплар язган, сүзлекләр төзегән. 1794 елда аның тарафыннан төзелгән гарәпчә-төрекчә чагыштырма грамматика бик әһәмиятле лингвистик язма байлык булып санала. Шулай ук Нигъмәтулла фарсы телендәге тарих китабын төркиләштергән.

Кулъязма китаплар арасында шәҗәрә китаплары да бар, шуларның берсе Эстәрлебаш мәдрәсәсендәге хәлфә Гали Чалатай тарафыннан язылган. Әлеге зур шәҗәрәдә имам Һибәтулла Каргалыйның нәселе (шагыйрь Һибәтулла Салихов) Мөхәммәт пәйгамбәрдән үк башланып язылган. Хәзер бу коллекция Башкортстан Фәннәр академиясендә саклана.

1921 елда Эстәрлебаш мәдрәсәсе эшләүдән туктатылгач, мәдрәсәнең соңгы мөдәррисе Мөхәммәтшакир Тукаев китапларны авылның укымышлы кешеләренә алырга рөхсәт итә. 1923 елда Оренбургка күченгән вакытында, үзе дә әлеге китапларның күпмедер өлешен алып киткән булырга мөмкин. 1928 елда ГПУ махсус операция үткәреп, авылның иң затлы 87 кешесен кулга алып, төрмәгә озаталар, китапханәдә калган

китапларның бер өлешен конфисковать итеп, Уфага алып китеп яндыралар.

Авыл аксакаллары тарафыннан яшереп саклап калынган китапларның 150 дән артыгы Абдрахман Айдабуловта (1876–1969) саклanган. Алар күн тышлы бик калын китаплар була. Канлы елларда Абдрахман Айдабулов аларны тирескә күмеп яшереп кала. Шул китапларның унсигезе Гайсә Хөсәенов тарафыннан Уфага Тел, әдәбият һәм тарих институтының кулъязма һәм иске басма китаплар фондына кайтарыла. Калган китапларның язмышы билгеле түгел.

Берничә китапханә һәм мәдрәсә урнашкан йортларның сызымнары Эстәрлебаш тарихына нигезләнеп авыл музее төзегән һәм шунда эшләгән Галиев Владимир Лотфрахман улында саклана. Бу сызымнарны заманында шушы мәдрәсәдә укыган Габдерәхим Галиев (1866–1966) ясаган. Габдерәхим бабайның атасы Гали Чалатаев, Казахстаннан килеп, биредә гыйлем эстәгән, соңыннан шунда хәлфәлек иткән – казах балаларын укыткан. Үзе дә язу-сызу эше белән шөгыльләнгән. Гали Чалатаевның XIX гасырның уртасында язылган берничә кулъязма китабы Уфада Әхмәтзәки Вәлиди исемендәге Милли китапханә фондында саклана.

Берничә генә данә калган мирас китаплар буенча да Эстәрлебаш мәдрәсәсендәге укылган китапларның, дәреслек әсбабларының характерын күпмедер чамалап, күз алдына китереп була. XI гасырда яшәгән бөек шагыйрь Йосыф Баласагунлы:

Җыйган дөнья байлыклары таралыр,
Язылган сүз җиһанда мәңге калыр, –

дип язган. Эстәрлебаш хәттатларының эшчәнлеге дә шушы сүзләргә дәлил булып тора. Ата-бабаларыбыз үз тырышлыклары белән тапкан табышлары, мал-мөлкәтләре, белемнәре белән киләчәк буыннарны, милләтебезне аң-белемле итәр өчен тырышканнар, дөньякүләм мөселман халыкларын агартуга зур өлеш кerтkәннәр. Үткәннәрне белмәсәк, бүгенгенең дә, киләчәкнең дә кызыгы булмас. Тукаевларның, гомумән, Эстәрлебаш мәдрәсәсе тарихына теге яки бу дәрәҗәдә өлеш керткән зыялыларның көнкүреш-яшәешен, аларның иҗтимагый фазыйләтен өйрәнү сорала. Һәр шәхес – үзе бер дөнья. Аны ачу исә безнең мөкатдәс бурычларыбызның берсе булып кала.

**Әдәбият**

1. Зәйнуллин З. Эстәрлебаш мәдрәсәләре // Казан утлары. 1990. № 6. 178 б.

2. Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Казан, 1989. Б. 245–246.

3. Тукаев Ш. Тарихи Эстәрлебаш. Казан, 1899.

4. Усманов В. Эстәрлебаш төбәгендә тарихи истәлекләр /В.Усманов // Өмет. 2000. 7 июль.

5. Фәхретдинев Р. Асар. 2 т. 9 җөзьә. Оренбург, 1904.

6. Харисов Ә. Башкорт халкының әдәби мирасы. Уфа, 1965.

7. Мухаметхарис Нигаметуллин (Тукаев), по архивному источнику, имам-хатыпом и мударрисом Стерлибашевской мечети стал по указу Оренбургского губернского правления за № 14816 от 20 октября 1845 г. См.: ЦГИА РБ. Ф. И-295. Оп. 10. Д. 66. Л. 106.

**Наширбанов И.К.**
**Казань**

# ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ ИНТЕРНЕТ-ПОРТАЛА DARUL-KUTUB.COM КАК ФАКТОР СОХРАНЕНИЯ И РАЗВИТИЯ ТАТАРСКОГО БОГОСЛОВСКОГО НАСЛЕДИЯ

*В статье освещается деятельность интернет-портала darul-kutub.com. Важнейшая задача работы портала – поиск и оцифровка трудов классиков богословской мысли мусульманского мира. Основной фокус направлен на оцифровку трудов татарских богословов XIX–XX вв.*

В рамках деятельности Издательского дома «Хузур» Духовного управления мусульман РТ функционирует проект darul-kutub.com. Главная цель проекта заключается в создании условий по поиску и оцифровке классических источников мусульманской богословской мысли, а также в облегчении доступа к цифровым версиям этих трудов. Для реализации данной цели в 2013 году на базе цифровых мощностей ИД «Хузур» был создан интернет-портал darul-kutub.com.

Данный портал представляет собой интернет-площадку, куда ежедневно в свободный доступ выкладываются сканы книг по исламу, объединенные тематикой традиционного восприятия мусульманского мирового наследия. В данном контексте, поня-

тие «традиционный ислам» означает приверженность ханафитской правовой школе, системе вероубеждения Абу Мансура Матуриди, предполагает апологетику суфизма. Немаловажно, что такая трактовка исторически считается общепринятой в Республике Татарстан и в регионах с преобладающим тюркским мусульманским населением (Республика Башкортостан, некоторые районы Ульяновской и Пензенской областей, южные районы Ставропольского края). Таким образом, в фокусе деятельности портала darul-kutub.com книги по ханафитскому праву, вероубеждению школы имама Матуриди, а также классическая философия суфизма и ее отражение в трудах татарских богословов.

Книги, оцифрованные сотрудниками редакции интернет-портала, каталогизируются и распределяются по таким категориям, как: фикх (мусульманское право), акыда (мусульманское вероубеждение), суфизм, Священный Коран и коранические науки, тафсир (мусульманская экзегетика), этика, педагогика и методика преподавания и многие др. Все категории перекрестные. То есть одна и та же книга может быть в разных категориях. Такая функция была реализована с целью облегчения поиска необходимой книги. Важно отдельно отметить разделы «татарское богословское наследие» и «альманах Шура». В категорию «татарское богословское наследие» попадают книги, написанные татарскими богословами и изданные до 1912 года в Казани, Уфе, Астрахани и других центрах мусульманского книгопечатания Российской Империи. 1912 год стал переломным в плане религиозного книгоиздания. Причиной тому стали вносимые после 1912 года в мусульманскую литературу, изданную в Российской империи, изменения, искажающие и дискредитирующие суть традиционного для татар Поволжья ислама. Исключение было сделано только для книг издательства «Матбуга-и исламия», отпечатанных в Токио в 1930-м году. Данное издание интересно в первую очередь с исторической точки зрения. Издательство «Матбуга-и исламия» было основано татарскими иммигрантами в Японии и издавало книги татарских просветителей на родном языке. В архиве этого общества хранится огромное количество книг татарского богословского наследия.

Категория «татарское богословское наследие» на интернет-портале darul-kutub.com насчитывает на сегодняшний день 403 книги (ноябрь 2017), что является половиной от всего

объема книг портала. Среди авторов представлены: Ш. Марджани, Г. Курсави, А. Максуди, Х. Атласи, Р. Фахретдин, М. Бигиев и многие др. Среди трудов этих выдающихся богословов на сайте представлены редкие книги и рукописи, представляющие особый научный интерес. Кроме того, по некоторым рукописям специалистами ДУМ РТ была выполнена работа по набору и перенесению текста в электронный формат.

Примечателен раздел «альманах Шура», который включает в себя все выпуски альманаха за 10 лет существования (1908–1918 гг.). Публикация первого татарского общественно-литературного журнала «Шура» на портале darul-kutub.com стала возможной благодаря деятельности электронного архива Российской национальной библиотеки.

К сожалению, архив интернет-портала в данный момент пополняется исключительно за счет частных коллекций мусульманских религиозных деятелей Казани. Обращение к фондам библиотеки им. Н.И. Лобачевского и Национальной библиотеки РТ не принесло результатов, поскольку оцифровка рукописей и трудов татарских мусульманских богословов монетизируется[1]. Тем не менее между ИД «Хузур» и Институтом языка литературы и искусств АН РТ достигнуто соглашение, в рамках которого архив сайта darul-kutub.com будет пополняться из фондов Центра музыкального и письменного наследия ИЯЛИ.

Информационное освещение деятельности интернет-портала darul-kutub.com осуществляется за счет публикации статей в блоге на сайте islam-today.ru, а также в социальной сети facebook. По адресу https://www.facebook.com/kitapxane публикуются статьи на русском и английском языках.

На данный момент портал darul-kutub.com функционирует на русском и английском языках. В ближайших планах запуск татарской и арабской версии сайта.

Резюмируя вышесказанное, интернет-портал darul-kutub.com предоставляет возможность найти и получить в личное пользование цифровые версии классических книг по исламу, а также труды выдающихся татарских богословов, что в долгосрочной перспективе будет способствовать сохранению богатейшего татарского богословского наследия.

---

[1] Здесь монетизировать означает «осуществлять (осуществить) деятельность, направленную на извлечение прибыли от какого-либо продукта».

**Сафиуллина-Аль Анси Р.Р.**
**Казан**

# ТАТАР ИЛАҺИЯТ ФИКЕРЕ НИГЕЗЕ БУЛАРАК ТАТАР КИТАП ТРАДИЦИЯСЕ

*Наличие богатой книжной традиции и традиции библиофильства у татар видится одним из основных факторов формирования богословского знания. Благодаря письменным источникам можно проследить картину эволюции мировоззренческих установок татарского народа в средневековый период и теологических представлений Нового времени.*

Татар халкында китаплылык традициясе күпгасырлык рухи тормышта аерып алгысыз бер өлеш булып тора. Ислам дөньясында киң таралган «китап сөю» (библиофильство) – аеруча татарларга хас сыйфат.

Ислам дөньяның «китаплы диннәре»ннән берсе, ул үсештәге язма мәдәнияткә ия, ислам дине буенча, аның тарафдарлары гыйлемгә омтылырга тиеш. Идел буе мәгариф системасы гомуммөселман мәгарифе һәм мәдәнияте йогынтысында үскән, ә ул исә халыкның төрле катлам вәкилләренә мөселман цивилизациясе белән танышырга мөмкинлек биргән: татарлар күп гасырлар буе Коръән һәм Сөннәт, мөселман дин галимнәре, шагыйрьләре, фәлсәфәчеләре хезмәтләре белән яхшы таныш булган. Җирле авторлар үз әсәрләрен шәрык авторларына ияреп язган, шәрык авторларына шәрехнамәләр һәм шәрехләргә шәрехнамәләр (субкомментарий) төзегән, аларның идеяләрен Идел-Урал регионында тараткан. Ул заманнар ислам дөньясында хезмәтләрне гарәп телендә язу кабул ителгән, шул сәбәпле күп галимнәрнең һәм дин белгечләренең хезмәтләре Россиядән читтә дә билгеле булган.

Казан ханнарының, Казанны яулап алу вакытында Явыз Иван гаскәрләре юк иткән, бик бай китапханәләре булуы турында мәгълүматлар бар. Монгол-татар явы вакытында да исәпсез сандагы матди һәм мәдәни, шул исәптән, язма ядкәрләр дә югалтылган. Совет чоры вакытында сугышчан дәһриләр гарәп язулы китапларны массакүләм яндырып юк иткән. Утта харап булмасын дип, меңнәрчә китапларны җиргә күмгән булганнар, алар череп бетеп, кире кайтарылмаслык итеп югалтылган.

Нәтиҗәдә, Идел буе Болгар дәүләтендә, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларының халык хәтерендә телдән сакланып калган дини-дидактик әдәби әсәрләре безгә соңгарак чорларга караган нөсхәләр буенча гына килеп җиткән. XVII гасырдан башлап татар авторлары язган хезмәтләрнең һәм татар кятибләре (күчереп язучылары) эшләгән күчермәләрнең кулъязмалары, сирәк булса да, күренә башлыйлар һәм гасыр ахырына таба библиофильлек традицияләре торгызыла. Гарәп язулы кулъязмаларның күпсанлы каталогларында әл-Болгари, әл-Казани һ. б. җирле нисбәсе[1] булган күпсанлы татар-төрки авторларын күрергә була. Нигездә, бу – XVII гасыр ахыры–XIX гасыр һәм XX гасыр башы татар дин белгечләренең (голәмалар) хезмәтләре. Россиядә татарларга билгеле бер вакытка кадәр интеллектуаль эшчәнлекнең бары тик бер төре – дин белеме белән генә шөгыльләнергә рөхсәт ителгән, шуңа күрә татарларның бар рухи-иҗади потенциалы руханиларда тупланган булган диярлек.

Татар кулъязмаларының зур өлешен дини тематикадагы хезмәтләр тәшкил итә, алар – гарәп һәм фарсы телләрендәге популяр әсәрләрнең татарчага тәрҗемәләре, аларга шәрехнамәләр һәм шулай ук социаль-көнкүреш һәм дини-дидактик эчтәлекле әдәби әсәрләр.

Гомумән алганда, ул әсәрләрнең репертуры киң колачлы, ул дини фәннәрне дә берләштерә, астрономия, табигать белеме һәм тыйб (медицина), философия һәм логика, тарих һәм этнография, грамматика һәм лексикография кебек табигый һәм гуманитар фәннәрне дә. Татарлар оешып (компакт) яшәгән урыннарда табылган кулъязма әсәрләргә караганда, шундый фикергә килергә була: татарларда Әбу Насыйр әл-Фараби (873–950), Әбу Гали ибн Сина (980–1037), имам әл-Газзали (1058–1111), Ибн әл-Гарәби (1076–1148), Сәгъди (якынча 1181–1291), Хафиз Ширази (якынча 1325–1389/1390) кебек Шәрыкның күренекле фикер ияләренең хезмәтләре киң таралган булган. Кулъязма бу мирасның билгеле бер өлешен татар авторлары хезмәтләре тәшкил итә, алар арасыннан Кадыйр-Гали-бәк (XVI гасыр ахыры – XVIII гасыр башы), Хисаметдин Мөслими һәм Таҗетдин Ялчыгол (XVIII гасыр ахыры –XIX гасыр башы),

---

[1] Нисбә – гарәп (мөселман) исемнәренең этник, дини, сәяси, социаль чыгышын, аның тууын яки яшәвен һ. б. аңлата торган өлеше.

Габденнасыйр Курсави (1776–1812), Шиһабетдин Мәрҗани (1818–1889) һәм башка бик күпләрне күрсәтергә була.

Урта Азия суфыйлары Ясәви һәм Бакырганиларның (XI–XII гасырлар) шигъри кыйссалары, Кече Азия суфый шагыйрьләре Җәләлетдин Руми (XIII гасыр), Мөхәммәд Чәләбиләрнең (XV гасыр), Урта гасыр авторлары Кол Гали (XII гасыр ахыры – XIII гасырның беренче яртысы), Мәхмүд Болгари, Хисам Кятибләрнең (XIV гасыр), Казан ханлыгы авторлары Кол Шәриф, Мөхәммәдьярларның әсәрләре билгеле. Кулъязмаларның һәм басма текстларның иң күпләре – Мәүла Колый (XVII гасыр), Габдерәхим Утыз Имәни (1754–1834) һәм башка XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы әдипләренең әсәрләре.

Дини эчтәлекле китаплар арасында Коръән исемлекләре, тәфсирләр, Коръән тексты аңлатмалары (экзегезалары) билгеле бер урын алып тора. Алар арасында урта гасыр авторларының канунлаштырылган хезмәтләре дә, татар авторлары тәфсирләре дә бар.

Кулъязма мирасның шактый өлешен догалыклар тәшкил итә, алар татарлар арасында таралыш алган дини әдәбиятның бик бай катламы булып тора. Алар – төрле зикерләр, вирдлар, хизблар һәм аларга аңлатмалар, пәйгамбәргә догалар, аерым, бергәләп укый торган, йола, бәйрәм, ниндидер бер вакыйга уңаеннан яки ниндидер бер эшләрне башкарган вакытта укыла торган һ. б. дога җыентыклары. Китап традициясенең бу төре мөселман дөньясында борынгы вакытлардан ук булган.

Язма чыганакларның шул ук типларына суфыйларның шөкер кылу догаларын, вирдларын һәм зикерләрен кертергә була. Төрле җыентыклар тупланган кече форматлы китаплар киң таралыш ала. Алар арасында гарәп һәм татар-төрки телләрендә язылган догалар, Коръәннең аерым сүрә һәм аятьләре тупланмалары, дини йолаларны, төш күрүләрне аңлата торганнары һәм шулай ук төрле авыруларны дәвалау ысуллары күрсәтелгән җыентыклар бар. Күз тиюләрдән һәм башка төрле бәла-казалардан саклау чаралары буларак, бөтиләрнең дә әһәмияте зур була.

Татар кулъязмаларын төзегәндә шәрык мөселман традицияләре йогынтысы сизелә. Типик форматлары, тышларының бизәлеше, алардагы язу рәвеше, җирле чималлардан әзерләнгән каралар, текстларны бизәүнең үзенчәлекләре, Россиядә эшләнгән кәгазь буенча Идел буе регионында эшләнгән

кульъязмаларны башкалардан аерып танырга була. Бу кульъязмалардагы гарәп һәм фарсы хезмәтләренең тематикасы, дини хезмәтләрнең мәдрәсәләрдә шәкертләргә укытылган стандарт бер даирәсен тәшкил итә. Мәдрәсәләрдә укыту методикасы үзе һәм басма китапларның кыйммәт торуы – шәкертләр үзләштерергә тиеш булган хезмәтләрнең күчермәләрен эшләргә мәҗбүр иткән.

Мөселман Шәркында югары руханилар китапларны күбәйтүнең гасырлар буе килгән күчереп язу традициясен яклаган, изге текстларга карата матбага ысулын куллануны мөртәтлек дип исәпләгән, дини китапларны матбагада басуны тыю фәкать XIX гасыр башында гына туктатыла. Ул вакытларда инде Казанда гарәп телендәге китапларны да, гарәп шрифты кулланып, татар телендәге китапларны да бастыра торган матбага эшли. Татарларда басма китаплар кульъязма китапларны тиз арада алмаштырып бетерә. Китап продукциясенең киң таралуы ул вакыт татарларында уку-яза белүчеләрнең зур процент тәшкил итүе белән аңлатыла.

Матбага ачылу белән Казан мөселман китаплары бастыруның иң зур үзәкләренең берсенә әверелә.

Татар наширләре гарәп телле басмаларны гына да дүрт меңгә якын чыгарган. Иң беренче чиратта, алар кануни текстларны (Коръән, хәдисләр, тәфсирләр), ислам фәннәренең аерым бер өлешләрен (фикъһе (ислам хокукы), гакыйдә (ислам илаһияте), әхлак (ислам этикасы), мантыйк (ислам логикасы) һ. б.), гарәп филологиясен, суфыйчылык характерындагы басмаларны, догалыкларны һ. б. бастырган. Шулай да аларда билгеле бер урынны җирле темалар буенча дини һәм социаль эчтәлектәге катгый бәхәсләр алып тора. Алар арасында дини мәсьәләләр буенча Ш. Мәрҗани һәм аңа каршы фикерлеләрнең бәхәсләшүләрен, кадимчеләр һәм җәдитчеләрнең педагогика, илаһият мәсьәләләре буенча фикер каршылыкларын искә алырга була [4, с. 121].

Әгәр татар басмалары буенча ачыкланган саннар турында сүз алып барсак, үзенең гомерен татар басма китабы тарихын торгызуга багышлаган китап белгече, академик Ә.Г. Кәримуллин (1925–2000) китергән саннар буенча, татар басмаханәләреннән 30 000нән күп китап чыккан дип беләбез [3, б. 141]. Бу сан соңгы елларда Татарстан мөфтие тарафыннан, дин әһелләре тарафыннан даими рәвештә гел телгә алына.

Шулай да татар басма китапларының төгән саны турында фикер йөртү авыр, алар, әлбәттә, әлеге 30 000 белән генә чикләнми. «Рус басма китабына 400 ел...» юбилей басмасы материалларыннан күренгәнчә, Россиянең бар губерналарында 1801–1855 еллар аралыгында 1463 китап бастырылган [1, с. 291]. Димәк, хәтта якынча гына исәпләүләр буенча да XIX гасырларда провинцияләрдә басылган һәр дүртенче китап, ә кайбер вакытларда һәр өченче китап – татар китабы булган.

Гарәп графикасындагы китаплар, кулъязмалар, вакытлы басмалар татар китап культурасы тарихын чагылдыра, аларның басма вариантлары да, кулъязма формасында булганнары да төрле фондларда тупланган. Татар кулъязмалары Казан, Санкт-Петербург, Мәскәү, Уфа, Ташкент, Баку, Истанбул, Ереван, Каһирә, Тәһран, Лондон, Париж һәм дөньяның башка шәһәрләре китапханәләрендә саклана. Бу язма мирасны саклау, өйрәнү һәм фәнни әйләнешкә кертү – гуманитар фәннең иң актуаль мәсьәләләренең берсе булып тора һәм ул алга таба да шулай булып калачак. Татар кулъязмаларын фәнни тасвирлау һәм аларны кодлаштыру тикшерүе үткәрү – озакка сузыла һәм күп хезмәт сорый торган процесс, ә хәзергә ул үзенең төгәлләнүенә бик ерак. Китап саклауның төрле фондлары: Казан (Идел буе) федераль университеты Н. Лобачевский исем. Фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегенең Көнчыгыш секторы, Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге, Татарстан Республикасы Милли музее һәм Татарстан Республикасы Милли архивы фондлары белгечләренең тырышлыгы белән бу өлкәдә җентекле эш алып барыла: сакланып калган бар кулъязмалар буенча мәгълүматлар җыела, тупланмалардагы кулъязмаларны тәртипләп тезү һәм фәнни тасвирлау эшләре башкарыла.

Татарстан Республикасының көнчыгыш кулъязмалары үзенең билгеле бер өлешендә, бик нигезле рәвештә, аның үз тарихи казанышы булып танылу алган. Россия, Бәйсез Дәүләтләр Берлеге (СНГ), Европа һәм Шәрык илләренең китапханә фондларында татар чыгышлы күренекле фән һәм мәдәният эшлекләре язган гарәп графикалы шактый күп сандагы

кульъязмалар һәм басмалар саклана. Аларның күпчелеге бүгенге көнгә кадәр өйрәнелми калуын дәвам итә. Соңгы дәвердә илебез фәнендә гарәп графикалы кульъязмаларны өйрәнү буенча шактый зур тәҗрибә тупланугa да карамастан, иң беренче чираттагы күп мәсьәләләр, бүгенге көнгә кадәр, ахырынача хәл ителмәгән хәлдә кала бирә. Бүгенге көнгә кадәр республикабызда һәм аннан читтә булган гарәп телендәге татар кульъязмаларын исәпкә кую һәм каталоглаштыру эшләнеп бетмәгән, шәрык кульъязмалары һәм кульъязма традицияләре буенча ил күләмендә гомумиләштерелгән хезмәтләр җитми. Шәрыкны өйрәнү буенча хезмәтләрнең һаман да киңрәк колач һәм киңрәк гамәли төс алу шартларында бу җитешсезлекләр ныграк сизелә бара. Тарихи-мәдәни, кодификация һәм китап тарихын өйрәнү буенча алып барыла торган тикшеренүләр һәм фәнни нәтиҗәләр аерым-аерым хезмәтләрдә генә таралып, таркалып кала. Тар белгечлеккә күчү тенденциясе кульъязмаларны төрле яклардан: археографик, текстологик, тарихи, лингвистик, теологик, сәнгатьне өйрәнү һ. б. яклардан өйрәнергә мәҗбүр итә. Ачык күренгәнчә, кульъязмаларны өйрәнүнең аерым бер республика, хәтта аерым бер шәһәр кысаларында гына аерым-аерым алып барылуы, гәрчә алар җентекләп өйрәнелсә дә, ышанычлы гомуми нәтиҗәләр бирә алмый. Татар кульъязма мирасын өйрәнгәндә гомум Россия тәҗрибәсен дә, дөньякүләм тәҗрибәне дә исәпкә алу зарурдыр. Бүгенге көндә гарәп дөньясы, гуманитар фәннәрнең төп мәсьәләләренең берсе итеп, мирасны (*турас*) өйрәнү, аңлату һәм танытуны игълан итә. Ә ул, билгеле булганча, нигездә кульъязмаларда чагылыш алган. Бу мирас тарихы мөселман мәдәнияте белән бәйле булган бар илләрдә дә гаять зур кызыксыну уята.

Бүгенге көн бу өлкәдә төрле яклы күп мәсьәләләрне кичектергесез чишүне таләп итә. Бу – шәрыкны өйрәнүнең мәгълүмати яктан тәэмин ителешен, сирәк кульъязмаларны саклау өчен уңайлы шартлар, аларны яңарту, реставрацияләү һәм саклауны тәэмин итү системасын, кулланучыларга китап җиткерүнең камилләштерелгән ысулларын һ. б. булдыруны күз алдында тота.

**Әдәбият**

1. 400 лет русского книгопечатания. 1564–1964: в 2 т. М.: Наука, 1964. Т. 1. 664 с.

2. Ахметзянов М.И. Татарская рукописная книга. Казань: Таткнигоиздат, 2000. 270 с.

3. Каримуллин А.Г. У истоков татарской книги. Казань: Татар. кн. изд-во, 1992. 208 с.

4. Сафиуллина Р.Р. Арабская книга в духовной культуре татарского народа. Казань: Алма-Лит, 2001. 212 с.

5. Сафиуллина Р.Р. История книгопечатания на арабском языке в России у мусульман Поволжья. Казань: Алма-Лит, 2003. 113 с.

6. Халидов А.Б. Арабские рукописи и арабская рукописная традиция. М.: Наука, 1985. 301 с.

**Таиров Н.И.**
**Казань**

# ФОТОДОКУМЕНТЫ КАК ИСТОЧНИК ИССЛЕДОВАНИЯ ТАТАРСКОЙ КУЛЬТУРЫ (конец XIX – нач. XX в.)



Фотографии сто лет.

*Стремление к знаниям было характерно для наших предков. Это ярко прослеживается в периоды развития Волжской Булгарии и Казанского ханства. К большому счастью, преданное и*

*любовное отношение к знаниям и образованию не были утеряны татарами и в последующие периоды истории.*

Весьма заметный взлет в области образования татары России сделали на рубеже XIX–XX вв., в первую очередь благодаря джадидизму. Немалые материальные средства на развитие просвещения вложили семьи Акчуриных, Апанаевых, Рамиевых, Хусаиновых, Яушевых и других татарских купцов и фабрикантов. В стороне от благороднейшего дела не остались и татары со средним и небольшим достатком. Характерной чертой тех лет стало широкое приобщение к обучению не только мальчиков, но и девочек. В те годы места проживания российских татар покрылись густой сетью медресе, мектебе и школ. Параллельно с этим на деньги тех же татарских купцов и фабрикантов развернулась широкомасштабная подготовка и переподготовка кадров татарских учителей в Казани, Троицке, Оренбурге, Иж-Буби, Уфе, Симбирске, Крыму. Одновременно организовались и проводились краткосрочные курсы по подготовке учителей. При поддержке татарских предпринимателей в 1915–1916 годах были подготовлены и проведены летние курсы для татарских учительниц в дер. Дюртили Уфимской губернии. Основную финансово-материальную нагрузку взяли на себя представители торгового дома Галеевых. Ими, в частности, были оборудованы необходимые помещения, учебные классы. На запланированных с 15 мая по 15 июля 1916 года курсах предполагались следующие дисциплины: педагогика, основы ислама, грамматика (татарская и арабская), география, история, алгебра, естествознание, гигиена, домашнее хозяйство, рукоделие, кройка и шитье[1].

К большому сожалению, часть из названных курсов осталась лишь на бумаге. Причины этого явления были самые разные. В качестве примера можно назвать курсы татарских учителей Симбирской губернии, организатором которых планировал стать щедрый меценат и крупный фабрикант сукна Хасан Тимербулатович Акчурин.

В марте 1908 года фабрикант Х.Т. Акчурин обратился к директору народных училищ Симбирской губернии с прошением.

---

[1] Каспий. 1916. 27 апреля.

В нем, в частности, говорилось, что в конце 1906 года просителем был учрежден мектеб в г. Симбирске на Лосевой улице (ныне ул. Федерации) в доме Мангушевых. В школе учительствовал Нугайбеков, преподававший по новому методу. Далее Х. Акчурин, в частности, писал: «...желая возможно скорее распространить этот метод обучения во всех остальных школах, обращаюсь к Вашему Превосходительству с покорнейшей просьбой исходатайствовать мне разрешение собрать в летние месяцы (июнь и июль) человек 40 учителей мектебе в г. Симбирске, где им в этот промежуток времени Нугайбековым будет преподан новейший метод обучения татарской грамоте [1]. Хасан Акчурин хорошо знал состояние школьного обучения татар в губернии, содержание и методику преподавания учебных дисциплин. Известный меценат стремился, как можно быстрее распространить новую прогрессивную методику на все татарские мектебе Симбирской губернии.

Итак, один из богатейших людей губернии, одновременно со своими делами по производству сукна, брался за решение неотложных проблем просвещения. Фабрикант предлагал органам просвещения губернии свои конкретные услуги, причем делал это заблаговременно, в начале марта 1908 года. Прошение Х. Акчурина спровоцировало переписку между чиновниками, результатом которой стал ответ, подготовленный на имя просителя. Директор народных училищ Симбирской губернии И.И. Ишерский писал: «Вы, учредив в г. Симбирске мектебе, являетесь содержателем частного учебного заведения, учредитель которого не имеет никакого отношения к тем мектебе Симбирской губернии, которые им не содержатся, и учителям, которых он не имеет никакого законного основания созывать на учительский съезд». Ответ датирован 7 апреля 1908 года [2].

Таким образом, на благие намерения Х.Т. Акчурина был наложен запрет. Формально директор народных училищ был, наверное, прав, а фактически... На деле несколько десятков учителей медресе и мектебе Симбирской губернии были лишены редкой возможности собраться и ознакомиться с новейшим методом обучения.

Именно с организацией подобных женских учительских курсов и связан предлагаемый вниманию фотоснимок, которому 100 лет. Он сделан в с. Кабан (близ Оренбурга). Здесь

летом 1917 года функционировали курсы юных татарских (мусульманских) учительниц, приехавших сюда из разных регионов Российской империи. Курсы проводились при активном участии руководителей знаменитого медресе «Хусаиния», их директором и организатором выступила известный педагог Багбстан Вильдановна Мукминова. На фотографии она сидит в центре. Рядом с ней известный писатель, издатель, общественный деятель Мухаметфатых Гильманович Каримов (Фатых Карими) (в шляпе). По авторитетному утверждению писательницы и исследовательницы Мадины Рахимкуловой, кроме преподавателей знаменитого медресе (одного из самых престижных учебных заведений татар и других мусульманских народов Российской империи.) «Хусаиния» (С. Бикбулатова, И. Бикчентаева, Дж. Валидова, Ф. Карими), на этих курсах преподавали Б. Мукминова, С. Шакулова, М. Латифия и другие.

Следует сказать, что данное во многом уникальное фото выявлено нами в домашних архивах людей-уроженцев Поволжья и Приуралья, ощутивших на себе помощь и поддержку со стороны татарских предпринимателей.

Интересно как сложились судьбы татарских курсисток и педагогов? Может быть, кто-то из исследователей, читателей данной публикации узнает своих родных, близких, учителей, земляков? В любом случае данное коллективное фото из далекого и бурного 1917 года говорит об огромном стремлении наших предков к знаниям накануне крутых и кардинальных перемен в истории народов нашей страны, в том числе и татар.

**Литература**

1. Государственный архив Ульяновской области. Ф. 99. Оп. 1. Д. 710, Л. 1.

2. Таиров Н. И. Татарская буржуазия Поволжья и Приуралья: социальная деятельность, благотворительность и меценатство (60-е гг. XIX в. – 1917 г.). Казань: Изд-во КГУКИ, 2011.

**Усманов В.М.**
**Казан**

# ТАРИХЧЫ-АРХЕОГРАФ СӘЕТ ВАХИДИНЕҢ ЭПИГРАФИКҺӘЙКӘЛЛӘРГӘ БӘЙЛЕ ХЕЗМӘТЛӘРЕ ТУРЫНДА

*Историк и археограф Саид Вахиди (1887–1938) оставил после себя много значимых научных трудов, связанных с богатым духовным наследием татарского народа, в том числе относящихся к изучению эпиграфических памятников, найденных в различных кантонах Татреспублики и за его пределами. Среди его работ особый интерес для эпиграфистов представляют отчеты о его поездке, состоявшейся летом 1929 г. в Мензелинский кантон, связанной с исследованиями около сотни намогильных камней XVII века, находившихся на старом кладбище дер. Катмыш. Кроме этого, интересны исследования С. Вахиди по Тамьян-Тугашским эпитафиям (Муслюмовского района) того же времени, о которых нам ничего не известно. Мы надеемся, что со временем эти бесценные архивные материалы ученого будут обнаружены и станут доступными широкой общественности.*

Мәгълүм ки, Сәет Вахиди төрле төбәкләргә (борынгы шәһәр-авыл биләмәләренә) оештырылган фәнни экспедицияләр барышында элекке кабер ташларын өйрәнү (тәфтишләү) һәм исәпкә алу эшендә бик тә әһәмиятле хезмәт башкарып калдырган. Мәсәлән, ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә аның зур фонды саклана (53 нче фонд). Мәкаләдә аның бер кульъязма хезмәтенә тукталырбыз (1 тасфир, 58 сакл. бер.). Әлеге хезмәткә 1928 елның июнь аенда Спас кантоны авылларына оештырылган археографик экспедицияләрнең хатирә язмалары тупланган. Кульъязмада кабер ташлары, каберстаннар, шәһәр хәрабәләре (кала өсләре), курганнар, хәндак-траншея кебек нәрсәләр вә аларның тарихи кыйммәтләре, ул ядкәрләрнең моңа кадәр гыйлем ияләре тарафыннан укылып-укылмаулары, аларның тәләф (юк) булган нөсхәләре турында тулы шифаһи (телдән сөйләнгән) мәгълүматлар белән бергә, кабер ташларының текст күчермәләре дә беркетелеп барган. Болардан башка кабер ташларының зурлыгы (мәсәлән, биеклеге – туфрактан очына чаклы биш сөям, киңлеге – бер чирек аршын,

калынлыгы 5 вершок), ташының сыйфаты я торышы, рәсеме, каллиграфиягә яисә палеографиягә бәйле күзәтүләр (мәсәлән, хәтты күфи, «бозык күфи» һ.б. шуның кебек язу рәвешләре) «калкытыб яки казылыб язылу» шикелле хосусиятләре, имлясендәге аерымлыклар, ядкәрнең Чулман ташыннан ясалулары, ташның кашкасында, ягъни иң югары михраб урынындагы бадьян билгеләре һәм башка шуның кебек күренешләр тулы рәвештә тасвирланып барган. Шулай ук эш барышында борынгы ташъязмалар эстампажга (мөмкинлек булганда фотоаппарат белән рәсемгә дә) алынып барылган дип аңларга кирәк (вә ләкин аларның сакланып калу-калмавы турында төгәл белешмә юк).

С. Вахидинең дәфтәрләрендә Спас кантонына караган Ташбилге, Янбакты, Иске Рәҗәб, Төгәлбай, Коры Көрнәле, Чуаштандагы – Урмар, Әтнә төбәгендәге Әтнә, Югары Бәрәскә, Иске Өҗем һәм башка авылларның борынгы каберстаннары вә андагы ташъязмалар турында бай мәгълүмат бирелә.

Бу урында шунысын да әйтеп үтәргә кирәктер, Мөслим төбәгендәге Катмыш авылындагы XVII гасырга караган зират ташъязмаларын 1929 елда Сәет Вахиди күчереп алганлыгы мәгълүм... Кызганыч ки, андагы 100 гә якын ташларның язмышы аянычлы. Бүгенге көндә шул истәлекләрнең берничәсе генә кисәк-фрагмент рәвешендә сакланып кала алган.

**Фәйзрахманов И.Җ.**
**Казан**

## ГАРАБШАҺ МУЛЛАНЫҢ КУЛЪЯЗМА МИРАСЫ

*Гарабшах сын Мухаметшаха (1887–1961) – пока неизвестная татарской общественности личность, но достойная того, чтобы ее рукописные труды были изучены и представлены широкой аудитории. В советское время Гарабшах долгие годы выполнял обязанности смотрителя Татарского кладбища в Новотатарской слободе г. Казани, будучи религиозным человеком, являлся неофициальным муэдзином и муллой. В нашем распоряжении более 200 страниц его рукописных текстов, где он делится своими воспоминаниями детства и юности, пишет историю родной деревни и своей родословной, в которых через собственные переживания*

*автора раскрывается глубокий мир татарского общества конца XIX – начала XX века.*

Гарабшаһ Мөхәммәдшаһ улы – әлегә татар җәмәгатьчелегенә билгесез, әмма исеме дә, тормыш кыйбласы да, эшләгән эшләре дә, кулъязма рәвешендә сакланган хезмәте дә билгеле булырга лаеклы шәхес дип әйтер идем. Гарабшаһка Тукайның тәэсире көчле булган ахры. Гарабшаһның үзенең балачагы, гаиләсе, туганнары, туган авылы тарихы буенча зур күләмле истәлекләре, Тукайның «Исемдә калганнар»ы кебек үк, классик автобиографик повестьны хәтерләтә. Өстәвенә Тукайның да, Гарабшаһның да язулары төгәлләнмичә кала. Гарабшаһның, гомумән алганда, иң күп язганы аның 1887 елда тууыннан алып XX гасыр башында Уральскига һәм аннан да арырак Казахстан далаларындагы бер авылда кибеттә хезмәтче-приказчик булып ялланып эшләгән балачак, үсмер чорларын гына үз эченә ала.

Гарабшаһ Казан губернасы Чар өязе Кышлау авылында туып үскән, Уральск, Оренбург, Казан шәһәрләрендә байларда хезмәттә булып, авыл белән дә элемтәне өзмичә, авылдагы кибеттә дә приказчик вазифаларын башкара. 1917 елдан, шактый укымышлы буларак, Түбән Шашы авылының мәктәбенә килеп укытып йөри. Гаиләдә бердәнбер ир кеше буларак аңа солдатка алынмауга бронь бирелә. Шулай да ул чордагы михнәтләр фронтка бармаучы халык җилкәсенә дә җитәрлек авыр төшә. Ул чактагы тормыш авырлыклары Гарабшаһны һәм аның гаиләсен, якыннарын бик күп сыный. Гарабшаһ 1924 елда ашлык тапшырыла торган пунктка икмәк илткәндә сул аягын каты өшетә, гангрена китеп, аягын тиздән югары кисәләр. Гарабшаһ шулай калган гомерен таяк белән генә йөреп үткәрә. Шулай булса да, бер аяклы килеш тә, 1920 нче елларның икенче яртысында, әле совет хөкүмәте рөхсәт иткәндә, Аллага тапшырып, тәвәккәлләп, хаҗ сәфәренә барып кайта. 1936 елда авылдагы йортын сатып, инде тулысынча Казанга гаиләсе белән күчеп килә. Казанда аны гел Коръән укытырга чакыра торган булганнар. Үзенең язуларында ул үзен Казан шәһәрендә Яңа бистә зиратында мөҗавир (кабер сакчысы, дәрвиш – *И.Ф.*) хезмәтен кылучы «әл-хаҗ әл-зәгыйф вә әл-фәкыйрь Гарабшаһ Мөхәммәдшаһ углы Әхмәдиев» дип күрсәтә. Кызы Сәгыйдә апаның искә алып сөйләүләреннән, аның әтисе биргән кечкенә

генә чиләге булган, шуның белән ул Тукай һәм татар халкының башка бик күп мәшһүр шәхесләренең каберташларын юып, зиратны чистартып торганнар. Сәгыйдә апа – ул вакытта кечкенә кыз бала – каберләр арасына керергә курка икән. Янында этисе: «Курыкма, кызым, мин монда догаларымны укырмын, син менә шуларын кара әле», – дип, каберләрне күрсәтеп, догаларын укып торып кызының күңелен тынычландырган.

Гарабшаһ абзый – аңлы-белемле кеше, һәрчак битарафлыктан, игътибарсызлыктан ерак торган. Язуларының кереш өлешендә ул үзенең яза башлавының максатын, мәгънәсен җиткерергә тели: акылы һәм зиһене булган һәркем Аллаһы Тәгаләдән бирелгән бу бүләкләрне (һәдияләрне, ягъни акыл белән зиһенне/ – *И.Ф.*) эшкә җикмәсә, бер нәрсәсе белән дә хайваннан аерылмый, ә инде имансызлары, эшчән булсалар да, хайваннан да яманрак һәм азгындыр, чөнки эшкә җигелгән акыллары булса да, хаклыкны аңламыйлар, маңгай күзләре күрсә дә, күңел күзләре күрми, колаклары ишетсә дә, үзләре ишетәсе килгәнне генә ишетәләр, хакны ишетмиләр.

Ул урта гасыр шагыйре Мәҗлисинең «Сәйфелмөлек» китабыннан берничә шигырь юллары китерә:

Кешедин калса яхшыдыр йәдкәре
Ки юкдыр бу җиһанның вә кадәре.
Димәк будыр ки сүзләрем бездин калды
Укыб, тыңлаб ки дустларым файдаланды.
Әгәр сүз булмаса, кем кемне белер,
Сүзләредин адәмләр мәгълүм ирер.
Кем укыса бу язмам гыйбрәт улсын,
Дустымларым тәмамы хуш хәл булсын.

Гомере буе Аллаһы Тәгаләгә ышанып яшәп, хаҗларга барып кайтып, 1958 елда инде 71 яшендә Гарабшаһ абзый үзе булдыра алган кадәр «укучыларга вә тыңлаучыларга гыйбрәт алырга, дөнья вә ахирәттә бәхет-сәгадәткә ирештерерлек соңгы буыннарга калдырып, мөмкин кадәр тәрҗемәи хәлемне, нәсәб шәрифемезне язмага» керешәм дип, инде совет халкы җирнең беренче иярченнәрен космоска очыра башлаган бер заманда, үзе яшәгән чордан аерылып, балачак хатирәләрен, ата-бабалары, олырак туганнары сөйләп калдырганнарны исенә төшереп, бисмилласын әйтеп, ак кәгазьгә терки башлый.

Иң элек ул үзе үскән Кышлау авылының ерак тарихына – авылны нигезләгән Колый бабай, аның нәсел тарихына туктала. Колый бабайдан Толмәмәт, аңардан Колмәмәт, аңардан Котлымәмәт, аңардан Әхмәр, аңардан Әхмәди, аңардан Мөхәммәдшаһ, аңардан Гарабшаһ туган. Колый бабайның кабере Иске Өҗем авылы янындагы Изгеләр зиратында, Колый бабай үзе дә шул авылдан Кышлауга күчеп килгән, имеш. Гарабшаһ мулла Кышлау авылындагы имамнар, аларның нәселләре хакында да мәгълүматлар китерә. Кышлау авылының урам, елга, күл, басу атамаларының килеп чыгышы, авыл җирләре, агачлыклары, тегермәннәре, чишмәләре, атна саен үткәрелгән базар, елга аша салынган күперләр турында тәфсилләп яза. Авыл халкының элекке чорларда урманга барып агач кисүләре, лашман хезмәтен башкарулары хакында зур гына өлеш китерә.

Гарабшаһ үзенең туганнары, шул исәптән, кияүгә чыгып киткән апаларының, ир туганнары хатыннарының күрше авыллардагы гаиләләре хакындагы мәгълүматларны да кәгазьгә бик күп терки.

Шул чор кешесенең тормышы туганнар, күрше-күләннәрдән аерылгысыз булып, кечкенә генә йортларда зур, ишле гаиләләрнең бергәләп тормыш иткәнлекләрен искәртеп, абыйлы-энеле туганнарның бер-берсеннән аерылышмый, килен-килендәшләр бер-берсеннән көнләшми, ачуланышмый гына матур, тату гомер итүләрен дә иманнары камил, әдәпләре нык булу белән аңлата. Шулай да, мөмкинлектән чыгып, хуҗа кеше улларын башка чыгару ягын караганын күрсәтә. Гарабшаһ абзый «Бер-береңнән юк-бар өчен үпкәләшеп, ташлашып йөрсәң, туганлыгыңны яки дуслыгыңны сүндерсәң, Аллаһы Тәгалә синең нурыңны сүндереп, мәртәбәңне төшерер», дигән фикердән чыгып, эш-гамәлләрендә дә шул нигезләргә таянуны хуп күрә. Элек заманда кешеләр наданрак булсалар да, әдәп, оят саклауда булганнар, тиешсез эшләрне эшләүчене хурлап, халык алдыннан үткәреп, урам әйләндереп йөрткәннәр.

Төп шөгыльләре үзләренә тиешле иманада иген игү булса да, җирнең азлыгы крестьянны баерак кешеләргә ялланып, күрше һәм ераграк авылларда да төрле эшләр эшләргә этәргән. Гарабшаһның атасы Мөһәммәдшаһ та такта яру остасы булган.

Гарабшаһ – гаиләдә бердәнбер, көтеп алынган ир бала. Атасы улы туып бер елдан соң ук бөтенләй сукырая, гаиләдә

тормыш алып барырлык ир калмагач, эшләре катлауланып, фәкыйрьлекнең чигенә җитәләр. Гарабшаһның олырак апалары Нәфисә белән Гафифәне хәллерәк кешеләргә асрау кыз итеп биреп торганнар. Гарабшаһ, кечкенә булса да, сукыр атасын җитәкләп һәрчак мәчеткә дә, зиратка да йөртә, урак вакытында басуга алып барып, байларга ялланып, аларның ашлыгын ура. Атасы да, дөм сукыр булса да, ашлыкны ура, көлтәгә генә бәйли алмый, анысына хатыны, малае ярдәм итә. Шулай атасын җитәкләп, Гарабшаһ авылдагы күршеләре, туганнары буенча йөриләр, күрше авылдагы туганнарына да баралар, үзләренә килүчеләр дә бик күп булган. Мөхәммәдшаһ абзый бик дини кеше була. Зиратка баргач, бик матур бер тавыш белән Коръән укый торган булган, мәчеттән кайтышлый хәзрәтләр белән озаклап сөйләшеп торырга яраткан. Ләкин атасының гомере озын булмый, авырып үлеп китә.

Гарабшаһ татар халкының кунакчыллыгы турында сөйләп, әгәр берәр кеше йортка барып керсә, йорт хуҗасы хәзинәсендә булган ризыгын өстәлгә куеп, чәен эчертеп, ашын ашатып, ашыгыч булса, ашъяулыгын гына булса да җәеп, икмәк-тоз куеп, бераз ашатып чыгару кебек электән килгән саваплы гореф-гадәтләрне матурлап тасвирлый.

Гарабшаһ абзый үзе дә, аның аталары да, фәкыйрь булсалар да, авылдагы иң бай Сафиуллин Гайнулла гаиләсе белән бик дус булалар, аларның эшләрен дә эшләшеп китәләр. Ләкин колхозлашу елларында әлеге бай гаиләнең бөтен малын-мөлкәте тартып алына, үзләрен Себергә сөрәләр. Шулай булса да Гарабшаһ бабай гомере буена Гайнулла абзыйларын, аларның балаларын гел яхшы яктан гына искә ала. Аларның авылдагы ярлы-хәерчеләргә ярдәм итеп, мәдрәсә салдырып, аны кирәк-ярак белән тәэмин итеп торуларын матурлап яза. Әйтерсең лә байлар белән аның кебек фәкыйрьләр арасында бернинди дә сыйнфый каршылык булмаган. Һәм Гарабшаһ абзыйның 1950 еллар азагында язылган язуларыннан, гомумән дә аны совет власте да, революция дә, дөньяда барган үзгәрешләр дә читләтеп үткән сыман, ул үзенең иманына тугры калып, гомеренең актык көннәренә кадәр биш вакыт намазын калдырмыйча, дин өйрәткәнчә, гадәткә кергән тормышын алып барып, шул иманын балаларына да тапшырасы килүе күренеп тора.

Авылдагы үзе истә калдырган вакыйгалардан Гарабшаһ абзый 1897 елгы переписьне исенә төшерә. Ул елда «безне чукындырырга телиләр» дигән сүз чыгып, халык переписька бик нык каршы төшә. Бу вакытта мәдрәсәдә укучы Гарабшаһны һәм башка шәкертләрне алдан өйрәтеп куйган булалар. Ул болай яза: «Әгәр-дә мәгәр мәдрәсәгә кереп, сез балалардан “Сез нинди малайлар?” дип сорасалар, “Без барыбыз да мөселман балалары”, диегез. “Ничек мөселман булдыгыз?” дисәләр, “Әлхәмделиллаһ, мөэмин мөселманнарбыз”, диярсез дип, “Ничек мөэмин буласыз?” дисәләр, “Әлхәмделиллаһ, мөэмини Хакка”, дип әйтеп, һәркайсыгыз да җавап бирерсез». Күп аңлата торгач, анда да күрше Олы Әтнә волостенда халык ризалашып, перепись башлангач кына, Кышлау волостендагы авыллардагы халык та переписька ризалык бирә.

Гарабшаһ абзый мәдрәсәдә бик тырышып укучылардан була. Ул заманда укучыларның яшенә карап, нинди китаплар укуы, мәдрәсәдәге тәртипләр, җәдиди һәм кадими укыту ысуллары турында күп мәгълүматлар бирә. Шулай ук үзләре тирәсендә булган пожарлар хакында, 1892 корылык елында ашарларына булмыйча, алабута орлыгын он итеп уып алабута икмәге ашаганнары, кодаларына ияреп әле Әтнәне дә күрмәгән малайның ерак Уральск шәһәренә чыгып китүе, юлда күргәннәренең аңа зур тәэсир ясаганы турында бик матур әдәби тел белән яза. Аның төзек әдәби тел белән язуы, шулай ук кулъязмаларының басма текст кебек төз, тигез булуы күп нәрсә турында сөйли. Гарабшаһ абзый гомере буе гыйлемгә-белемгә омтылып, тормышка битараф булмыйча яшәгән. Мәрҗани мәчетендә дә дуслары күп булган. Аның Иске татар зиратындагы кабере янәшәсендә дә совет заманында Мәрҗани мәчетенең имам-хатибы Габделхәбир хәзрәт Яруллинны (1905–1994) җирләгәннәр.

Гарабшаһ абзый язмаларында дини тәрбия, яшәеш турында киләчәк буыннарга гыйбрәт алырлык вакыйгалар гади генә сүзләр белән күңелгә үтеп керерлек итеп сурәтләнә. Аның язулары – күңел дәфтәрләре, XX гасыр башы татар кешесенең менталитетын, «татарлык» дигән төшенчәнең мәгънәсен күп яктан ачып бирәләр. Шуңа күрә дә күңелләребездә татарлыкны саклауда ярдәм итә ала торган Гарабшаһ абзый кебек кешеләрнең хезмәтләрен популярлаштырасы да популярлаштырасы бар әле.

Хәзерге заманда гел яңарып торган тормыш шаукымнары аеруча тәрбиясе, әхлагы ныгып җитмәгән яшьләрне баса һәм һәрчакта да уңай якка түгел, билгеле. Бүгенге 9 май бәйрәмен дә балаганга әйләндереп, башкасы булмаганнан кешедә бары кыска вакытлы кызыксыну гына уятырга сәләтле кемнең сугышта катнашкан бабасы крутойрак булган дигән сыман пиар-акцияләргә әйләнеп баручы мероприятеләрнең кирәклеге шик тудырган бер мәлне Гарабшаһ абзый кебек ныклы иманлы шәхесләрнең безнең барыбыз өчен дә гомерлек маяк булып барырлык дәрәҗәдәге тормыш үрнәген үзебезгә өлге итеп алсак, алар үрнәгендә үзебезне тәрбияләсәк һәм үз фигылебез белән шул ук уйны якыннарыбызга сеңдерсәк, болай да кыска гына гомерләребезне тикмәгә үткәрмәгәнлегебезгә ышаныч белән яши алыр идек.

**Харрасова Р.Ф.**
**Казан**

## ЕГЕРМЕНЧЕ ЕЛЛАР МАТБУГАТЫНДА С. ВАХИДИ ЭШЧӘНЛЕГЕН ЯКТЫРТКАН КАЙБЕР ЯЗМАЛАР

*В статье освещаются исследования и заметки, посвященные деятельности Саида Вахиди и опубликованные на страницах татарской периодической печати в 1920-е годы. В этих материалах такие авторы, как М.Г. Худяков, М.Н. Фирсов, Г. Губайдуллин и другие, касаются многогранной деятельности С. Вахиди как археографа, этнографа, историка, отмечая важный вклад ученого в развитие отечественной науки.*

Соңгы елларда С. Вахиди исеме тарих фәненә, бигрәк тә аның археография, архив гыйльме, тарихи география, дин яисә төбәк тарихы, хронология, этнография һәм башка өлкәләренә караган хезмәтләрдә еш телгә алына башлады, онытылыбрак торган язмалары да фәнни әйләнешкә шактый керде, чөнки ул татар чыганакчылыгының башында торган, милләтебезнең үткәнен яхшы белгән һәм алга китешен кайгырткан кешеләрнең берсе иде. Ә бит үз заманында С. Вахиди галим буларак бик хөрмәтләнгән, гыйльми эшчәнлеге киңрәк җәмәгатьчелеккә, Татарстаннан читтә дә билгеле булган, югары бәяләнгән. Бу

хакта ТӘһСИ мирасханәсендә сакланган архив документлары һәм вакытлы матбугат материаллары да ачык сөйли. Шуларның бик мөһимнәре – «Сәхибгәрәй хан ярлыгы» табылуның фән өчен кыйммәтлелеген язган хезмәтләр, рецензияләр, хәбәрләр. С. Вахиди эшчәнлегенә мөнәсәбәттә егерменче елларда язылган газета материаллары бергә җыелып, кулланылыштагы графикага күчерелеп, галим архивындагы махсус папкаларга тупланган. Шуларның кайберләре белән танышып узыйк.

«Татарстан» газетасының сәркатибе иптәш Сафин 1922 елның 17 сентябрь санында «Нахождение важных исторических документов древнего Казанского ханства» язмасын бастыра. Анда галимнең озак еллар дәвамында тарихи ядкәрләрне өйрәнүе, узган чорларны объектив яктыртуга мөмкинлек биргән күпсанлы документлар табуы әйтелә. Мәкалә авторы моңа кадәр галимнәрнең төрки-татар тарихын яктыртканда русча яисә башка телләрдәге материалларга таянуын сөйли һәм хәзер үз язмачыларыбыз калдырган тарихи истәлекләрне файдалану мөмкинлеге туугa сөенеч белдерә. Журналист, моннан тыш, галимгә ияреп, Мамадыш, Спас, Чистай кантоннарында сакланган тарихи истәлекләрне җыю экспедицияләрен оештыру өчен хөкүмәтнең ярдәме кирәклеге мәсьәләсен дә күтәрә.

Шушы ук елның 27 октябрендә Казанда дөнья күргән «Известия» газетасында тарихчы галим М.Г. Худяковның «Көнчыгыш фәннәре» өлкәсенә хезмәт күрсәтүче «С.Г. Вахитов ачышлары» хакында сүз алып бара. Ул, Казан ханлыгын буйсындырганда бөтен дәүләт архивларының юкка чыгарылуын, шунлыктан бүгенге чор галимнәренә елъязмаларга, дипломатик язышуларга, чит халыкларда сакланган белешмәләргә таянырга туры килүен әйтә.

Галим соңгы елларда татарлар арасында үз мәдәниятләре, үткәннәре белән кызыксыну арта барганлыкка, аларга кагылышлы чыганаклар табыла башлаганлыкка мисал итеп, Сәет Вахидов исемле фәнгә омтылышлы, зур эрудицияле, җитди тарихчының Казан ханлыгы чорына караган һәм төп нөхсә булган Сәхибгәрәй хан ярлыгын табуын билгели. Алга таба М. Худяков аның фәнни эшчәнлек елъязмасы һәм мөһим документка ия булу тарихы белән дә билгеле бер дәрәҗәдә таныштырып үтә. Аның язуынча, С. Вахиди, әле авыл мәктәбендә укыганда ук, бер хезмәттә җирле галим язган болгарлар тарихы хакында

мәгълүмат таба һәм, мәктәпне тәмамлаганнан соң ук шуны эзләү эшенә керешә. Тарханлык грамотасының иясе 1912 елда табылса да, бары тик сигез ел узганнан соң гына, С. Вахиди аны хуҗасыннан алу һәм Казанга китерү бәхетенә ирешә. М. Худяков шушы вакытларда галим ярлыкны фәнни өйрәнү эшен тәмамлап килә дип белдерә. Ул бу табышның татар авылларында борынгы тарихи документлар сакланганны дәлилләде, алга таба башка документлар да табылачакка өметне арттырды, ди.

Җирле рус галимнәре арасында С. Вахиди эшчәнлегенең татар-төрки дөньясы өчен ни дәрәҗәдә кыйммәтле икәнлеген шул ук «Известия» газетасының 1923 ел 16 гыйнвар санында хезмәттәше Н.Н. Фирсов бик тәфсилле яктырта. Ул «Историческая ценность» язмасында аның табышлары арасында Сәхибгәрәй хан тарафыннан туганлык җепләре белән тоташкан җиде кешегә бирелгән «тарханлык» грамотасының әһәмиятен шулай ук югары бәяли, чөнки ярлык Казан ханлыгының сәяси корылышына күз ташлау мөмкинлеге тудыра дип саный. Алга таба галим ярлыкның Болгар дәүләте белән Казан ханлыгы төзелешендәге аермаларга күрсәтүен, икенчесенең патшалык төзелешендә, сәяси тәртибендә Алтын урда тәэсиренә бирелүен яза. Н. Фирсов Идел-Кама Болгарстанының, шуның аркылы гарәпләрнең Казанга тәэсирен мәдәният өлкәсендә күрә. Ул С. Вахидовның шушы игелекле хезмәтләренә милли республиканың хакимият органнары да ярдәм итәргә тиеш дигән караштa тора.

1923 елның 6 февралендә Газиз Гобәйдуллин «Татарстан» газетасында «Сәхибгәрәй ярлыгы турында» мәкалә бастыра. Ул билгеле бер дәрәҗәдә татар галимнәренең тарихи документларны эзләү юлындагы С. Вахидовка кадәр алып барган эшчәнлеген яктыртып уза. Г. Гобәйдуллин Ш. Мәрҗани, И. Хәлфиннарның тарихи ядкарьләрнең халыкта сакланган булуына ышанганнарын әйтә, әмма инкыйлабкача аларны эзләү белән шөгыльләнү мөмкинлеге юк иде, ди. Алга таба галим болай дип белдерә: «Хотя у Гади Атласова мы находим некоторые сообщения о ярлыке Сахиб-Гирея, но Атласов не мог приобрести этот ярлык, а также и не мог правильно прочитать. Особенно приходится сожалеть о том, что Атласов не мог добиться тех выводов, которые могли объяснить положения относительно экономической и социальной структуры Казанского ханства. Приобрести оригинал ярлыка, сфотографировать его,

прочитать его правильно, сравнить его с другими ярлыками, наконец, дать его русский правильный перевод выпало на долю Саида Вахидова. С.Г. Вахидову удалось написать труд об этом ярлыке, который (труд) в настоящее время у С.Г. Вахидова находится в виде рукописи, ожидающей печатания».

Газиз Гобәйдуллин ярлыкта Казан ханлыгындагы идарәчелек, сыйныфлар, хөкем һәм налог эшләре, мәдәният, ислам дәүләтләре белән бәйләнешләр һәм башка яклар турында мәгълүмат барлыгын әйтә.

Казанда чыгучы икенче бер рус газетасы «Красная Татария» 1925 елның 13 февралендә чыккан «Ценное пожертвование в музей Татреспублики» язмасында С. Вахидигә Татар Республикасының Баш Музеена Сәхибгәрәй ярлыгын һәм аның белән бергә, 210 башка кулъязмаларны да тапшыруы өчен рәхмәт белдерә. Башка газеталар исә республикабызның Мәгариф Халык Комиссариаты каршындагы Академик үзәкнең С. Вахидигә адресланган рәсми рәхмәтен күчереп баса яисә укучыларына шушы хакта хәбәр ирештерә [1].

Билгеле булганча, 1925 елда Татарстан фәннәр Академиясенә башлангыч биргән «Татароведение» (Татарны өйрәнү) фәнни җәмгыяте төзелә. С.Г. Вахиди 1925 елның 17 маенда Татарны өйрәнү һәм Археология җәмгыятьләренең берләшкән утырышында Сәхибгәрәй хан ярлыгы хакында чыгыш ясый. Шуннан соң «Красная Татария»гә һәм башка редакцияләргә хатлар, бәяләмәле хәбәрләр, тулыканлы рецензияләр килә башлый. Әле 26 майда ук исеме белгә алынган газетадагы имзаланмаган хәбәрдә, ярлыкның төп әһәмияте итеп, аның әлегә кадәр Казан ханлыгының XVI гасырның беренче чирегенә кагылышлы ядкарьләр арасында бердәнбер юридик документ булуы һәм галимнәр алдына ханлыктагы дәүләти хокукны өйрәнү юлында күптөрле сораулар куюы билгеләнә.

Алга таба профессор Н.Н. Фирсов шушы ук газетада С. Вахидинең «Татарские легенды о прошлом Волжско-Камского края» (1925) хезмәтенә югары бәя бирә, рус укучысына да барып ирешүен хуплый [2]. Мәкалә шушы рәвешчә башлана: «С.Г. Вахидов усердно собирает материалы для истории татар в период их самостоятелҗного существования. В ряду этих материалов свое место займут и легенды, напечатанные в только-что вышедшей вышеназванной брошюре.

Легенд здесь несколько, некоторые из них в иных вариантах, уже были известны, но это не мешает приветствовать и то, что вновь напечатано на русском языке нашим энергичным собирателем, найдутся тут черты, которые дадут возможность более отчетливо определить отношение татарского народа к своему далекому прошлому».

Егерменче елларда С. Вахиди эшчәнлеген яктырткан хезмәтләр эчендә төп урынны Н.Н. Фирсов язмалары алып тора. Ул хезмәттәше башкарган эшләрне, шуның белән беррәттән, татар фәне ирешкән уңышларны башкаларга да пропагандалау эше белән махсус шөгыльләнә. Алда аталган хезмәтләре янәшәсендә 1925 елны галим «Исследование ярлыка Сахиб-Гирея-хана» исемле мәкалә бастыра [3]. Аннан без татар крестьяннарыннан чыкканлыгын, башта фән белән үзешчән дәрәҗәдә шөгыльләнгәнлеген, хәзер археографияне төп хезмәт юнәлеше итеп алганлыгын, инде Үзәк музейга 500 кульязма бирүен укыйбыз. Н.Н. Фирсов тасвирламалары С. Вахидинең ярлыкны өйрәнүгә ни дәрәҗәдә фәнни, җентекле якын килүен, ул тапкан тарихи ядкәрнең үткәнебезне яктырту өчен фәнни әһәмиятен ачык күрсәтеп тора.

С. Вахидинең археографик, этнографик экспедицияләренә, фән өлкәсендәге табышларына, чыганакларга якын килү алымнарына бу чорда башка галимнәр дә югары бәя бирә.

**Әдәбият**

1. Кзыл-Татарстан. 1925. 15 февраля. № 37 (1207).
2. Фирсов Н.Н. Казань в легендах // Красная Татария. 1926. 21 марта.
3. Фирсов Н.Н. Исследование ярлыка Сахиб-Гирея-хана // Новый Восток. 1925. № 10–11. С. 361.

**Хасавнех А.А.**
**Казан**

## МӘШҺҮР ВӘ УКЫМЫШЛЫ БУЛГАН ФӘРХАД БЕЛӘН МӘГЪШУКАСЫ ШИРИН ХИКӘЯСЕ

*В статье рассказывается о недавно найденном рукописном сборнике татарского поэта-суфия XIX века Ахметзяна Тубыли; приводится его научное описание. Примечательно, что в данном сборнике нашло место поэтическое произведение поэта «Пове-*

*ствование об известном и просвещенном Фархаде и его возлюбленной Ширин». В исследовании раскрываются содержание любовной поэмы, особенности композиционного строения, образы и мотивы; определяются роль и место данного произведения в литературном наследии Востока и всего тюркского мира. В статье приводится сокращенный пересказ поэмы, переплетенный с поэтическими отрывками из оригинала.*

Әле күптән түгел генә Казан университетының кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә XIX гасыр татар шагыйре Әхмәтҗан Тубылиның (1825–189?) [1; 2; 4] 701-т номеры белән тагын бер кызыклы кульязмасы табылды. Аның кем тарафыннан, кайда табылуы билгеле түгел. Ә. Тубыли аны Тубыл (Тобольск) шәһәрендә сөргендә вакытта язган. 1–11 нчы битләрендә көйләп укыла торган әхлакый характердагы кыска гына хикәяләр урын алган. 11–49 нчы битне шактый зур күләмле «Мәшһүр вә мөтәгәрриф улан Фәрһад гашыйк илә мәгъшук Ширин хикәясе» тәшкил итә. Ә. Тубыли кульязманың беренче битендә үк Фәрһад һәм Ширин турындагы әсәрен кайчан тәмамлаганын әйтеп китә: «Тарих миляди 1879 нчы сәна бөрҗи-җәүзәнең 13 нче йәүмендә тәмам улынды».

Татарлар арасында Ләйлә-Мәҗнүн, Таһир-Зөһрә, Йосыф-Зөләйха, Сәйфелмөлек-Бәдигылҗәмал турындагы мәхәббәт әсәрләре киң таралган. Ләкин Фәрһад һәм Ширин мәхәббәте турындагы тарих фольклорда һәм әдәби әсәрләрдә бик сирәк очрый. Моның сәбәбе бәлки шунда ки, Низами, Нәваи, Әмир Хөсрәү Дәһләви, Җами кебек Шәрыкнең бөек классиклары әсәрләрендә Фәрһад белән Ширин мәҗүси диндәге кешеләр булып күрсәтеләләр һәм бу ике гашыйкның мәхәббәте күбрәк дөньяви планда сурәтләнә. Эчтәлеге буенча һәм композицион яктан Ә. Тубыли әсәре, Низами, Нәваи поэмаларыннан аермалы буларак, Фәрһад һәм Ширин турындагы төрки легендаларга якын тора.

Татар әдәбиятында бары тик ике генә шагыйрь бу сюжетка мөрәҗәгать итә: Алтын Урда чоры әдибе Котб (XIV г.) һәм XIX гасыр шагыйре Әхмәтҗан Тубыли. Котбның «Хөсрәү-Ширин хикәяте» текстын җентекле һәм җитди рәвештә Х.Й. Миңнегулов һәм Р.Г. Әхмәтьянов тикшереп чыктылар [5]. Р.Г. Әхмәтьянов аны хәзерге татар әдәби теленә күчерде. Әхмәтҗан Тубылиның Фәрһад белән Ширин турындагы

хикәясенә килгәндә исә, шуны әйтергә мөмкин: ул төрки-татар әдәбиятларында киң таралыш тапкан катнаш проза белән шигъри рәвештә язылган. Ихтимал, әсәрнең фольклор варианты булгандыр. Тик анда әдәби интерпретацияләр шактый гына күп урын алып тора. Шуңа күрә аны татар авторының оригиналь әсәре дип атап була. Кызганыч ки, кульъязманың соңгы битләре сакланып калмау сәбәбле, бу гүзәл әсәрнең азагы юк. Шулай да «Мәшһүр вә мөтәгәрриф улан Фәрһад гашыйк илә мәгъшук Ширин хикәясе»нең сакланып калган өлеше 76 кульъязма сәхифәдән гыйбарәт.

**(Кыскартылган рәвештә басыла[1]).** «Равилар түбәндәге риваять һәм шундый хикәят итәләр ки, Гаҗәм икълимында һәм Хөрәсән өлкәсендә бер зур шәһәр бар иде. Һавасы әйбәт урында урнашкан булып, тирә-ягын баг-бакчалар, гөлбакчалар биләп, һәр бачада бер зур гына иңеш бар иде. Һәм шәһәрдән дүрт якка ераграк киткәндә киң сәхрә, анда куаклыклар, сөнбелләр, миләүшәләр, лаләләр үсә иде. Һәм ул сәхрәнең уртасыннан зур елга шаулап ага иде.

Ул шәһәр халкы барчасы күңел ачу, кәеф-сафа илә мавыга иде. Өстәвенә шәһәрнең ире булсын, хатын-кызы булсын бик матурлар иде. Берәрсенең йөзенә баксаң матур бөдрә чәчләре күңленә уралып әсир итәр иде. Һәм ул илнең патшасы хатын кеше иде, һәм ул илдә шундый кагыйдә бар иде – патша үлеп, аның углы калмаса, кызын тәхеткә утыртып, патша итәләр иде. Һәм менә бер заман патша булып Мәһмәнәбану[2] исемле хатын тора иде. Аның берничә акыллы вәзирләре бар иде. Һәрберсе гакыл вә гамәл иясе иде. Һәм ошбу падишаһның дәүләт башында торган елларында бар тирәдәге дәүләтләр тыныч иминлектә иде. Тик тирәдәге хәтта күп гаскәрле булган шаһлар да, Мәһмәнәбанудан хәвефләнеп, ел саен һәдия-бүләкләр бирәләр иде.

Мәһмәнәбануның кыз карендәше бар иде. Исеме Ширин булып, Зөләйхага тиң матур иде. Йөзе-күзе ачык, керфекләре ук, кашлары җәя. Һәм бу ир-атның күңелен багларлык заман

[1] Алга таба поэманың эчтәлеге безнең шәрехләүдә Ә. Тубылиның бәетләре белән (курсивта) үрелеп бара.

[2] Мәһмәнәбану – борыңгы легендар Иран патшабикәсе Семирамида. Мәһмәнәбану аның прототибы.

афәте. *Нибары ундүрт яшендә, Дәүләт көлаһы*[1] *башында* иде. Шунлыктан мәзкүр шәһәрдә бик атаклы иде. *Адәм заманыннан бирле килмәгән синдәй бер гүзәл, Исемең Ширин, сүзең ширин, син инде шундый бер гүзәл.* – диерләр иде.

Мәһмәнәбану Ширин өчен матур күшек[2] һәм күркәм касер[3] төзетмәкче булды. Чөнки Мәһмәнәбану Ширинне шулкадәр ярата иде ки, ансыз бер минут торалмас иде. Мәһмәнәбанунының бер оста төзүчесе бар иде. Һөнәрдә гаять үсешкән, һәртөрде сәнгатьне үзләштергән иде. Һәндәсә[4] гыйльмендә җиде дәрәҗәсе[5] бар иде. Һәм аңарда берничә шәкерт өйрәнә иде. Алары да һәндәсә гыйльмендә маһир иделәр. Бәс, Мәһмәнәбану ул төзүчене чакырып әйтте: «И, төзүче, Ширин өчен бер күшек[6] ясатырга телим, ләкин ул шундый булсын, дөньяның дүрт өлешендә дә тиңе булмасын иде», – диде. Тәзүче җир үбеп: «Шаһ фәрманыңа, мин әзер», – диде.

Мәһмәнәбану аңа бәясе бөтен өлкәдән алынган салым акчасы кадәр торган кием бүләк итте. Төзүче шатланып, шаһинә ягыннан чыгу белән, һәндәсә гыйльмен кулланып, һәр көн таңнан алып йолдызлар кабынганчы кадәр эшләде. Мәһмәнәбану ул касерне җиде кат күккә охшатып, җиде кат күкнең һәрберсенә тиеш итеп эшләргә кушты. Әүвәлге касер тулган ай[7] шикелле ак төстә булса, диван әһле шул төстәге киемнәр кисен. Падишаһның аңа килгәндә кигәне дә ак була. Икенче касернең исеме Меркурийга нисбәтле, төсе зәңгәрсу, шуның өчен анда намаз укырга зәңгәрсу киенәләр. Өченче касернең аты Зөһрәдер. Төсе ал һәм һәммә диван әһеле ал кияләр. Дүртенче касер Ай төсендә сарыдыр, диван әһеле сарыдан киенәләр. Бишенче касер Миррих-Марс, кызыл төстә һәм диван әһеле вә шаһ үзе

---

[1] Көлаһ – гадәттә дәүләт кешеләре һәм кызлар кия торган ялбыркоңлаклы киң бүрек.

[2] Күшек – җәйге зиннәтле сәрайчык.

[3] Касер – зур булмаган хәрби ныгытма.

[4] Һәндәсә – геометрия; монда – инженерлык.

[5] Дәрәҗәсе – осталык дәрәҗәләре мөселман илләрдә элек тә булган.

[6] Күшек – кечкенә сәрай.

[7] Семирамида (Мәһмәнәбану аның прототибы) борынгы Бабил-Вавилон патшабикәсе Саммурамат (Шаммурамат) белән ярыша кебек. Алар да җиде төстәге касерләр корганнар. «Семирамида баглары» борынгы антик заманнарда дөньяның «җиде гаҗәеп корылмасының» берсе булган.

кызылдан киенә. Алтынчы касер Юпитерчә, төсе яшел, диван әһле яшелдән киенә. Җиденче касер Сатурнча булырга тиеш, төсе карасу, диван әһле кара киенәчәк.

Шуннан соң төзүче оста шул күрсәтмәләр буенча касерләрне төзеп бетерде. Хәзер бизәкләргә кирәк иде. Ул шәһәрдә бер оста бизәкче бар иде. Бәһзад нәккаш диерләр иде. Төзүче-архитектор ул Бәһзадны чакырып, [касерләр янындагы] күшекне буяу-бизәүне аңа тапшырды.

Әлеге нәккашның бер углы бар иде, атына Фәрһад диерләр иде. Ул да этисе кебек һөнәрче иде. *Әле тик унбиш яшендә, Дәүләт таҗы башында. / Гыйззәт һәм шәрәф кафтаны*[1] *өстендә, Кулы һаман эшендә.* Кашы, керфеге кара, муены ак, күз бәбәкләре кара, үзе гаять якты төстә, яңаклары гөл, күзләре хыялый шикелле. Тәне камфара һәм гомумән тулган ай кебек иде ки, аны бер күргән кеше җаны белән мәфтүн булыр, тартылыр иде.

Ничектер бер көнен болар аталы-угыллы ул күшекне бизәгәндә иркә кыз Ширин эшне карарга дип, аның белән бергә Мәһмәнәбану да йөрергә чыгып, икәүдән-икәү бакчага килделәр. Күшек тирәли карап йөргәндә Шириннең күзләре нәккашның углы Фәрһадка төште. Һәм Ширин шул сәгатьтә җаны-тәне, эче-тышы белән гашыйк булып, үз-үзен көчкә кулга алып баш төзүчегә: «Болар нинди бизәүчеләр?» – диде. Төзүчеләр башлыгы: «Болар, солтаным, ике нәккаш, этисе һәм углы, этисе Бәһзад, углына Фәрһад диләр», – диде. Шулай итеп Ширин боларны бик яратты, Фәрһад та бер карауда Ширингә шундый мәхәббәт баглады, әйтеп-сыйфатлап бетермәле түгел.

Мәһмәнәбану белән Ширин сәрайдан чыгып, күңел ачулар һәм уенлы-чынлы сөйләшүләр белән мәшгуль булдылар. Әмма Шириннең дәртенә гыйшык уты кабынып, сабыры-карары калмыйча, бер сылтау белән кулына гаҗәеп алтынсу лимон алып, бергәй кеше-фәлән булмаганда Фәрһад эшләгән төшкә барып, нәзәкят белән үзен күрсәтте. Һәм Фәрһад [кем йөри икән дип] әйләнеп караса, Ширин алтын лимонны аның нәкъ күкрәгенә тондырды да, Фәрһад лимонны тотып, үзенә атканны күргәч, тиз генә бер якка тайпылды. Һәм Фәрһадның да гашикъ икә-

---

[1] Кафтан – төрки-татар сүзе (каты «к» белән әйтелә). Тексттан күренгәнчә, «кафтан» татарча «каптал»; һөнәрчеләрнең киеме булган.

нен аңлап, артык мавыкмыйча сәрайга кайтты, һәм Фәрһад та ахшамгача көчкә эшләп, төнен күзләренә йокы кермичә, иртән иртүк торып, атасыннан өч сәгать элек эшкә тотынды. Равилар әйткәнчә, бу тарафтан Шириннең гыйшкы ялкынланып яна башлады. Тагын кулына алтын лимон алып, сак-сак кына килеп, гөлләр арасыннан ай кебек күренеп, тагын Фәрһадка лимон ыргытты. Фәрһад шундук әйләнеп карады һәм Ширинне күрү белән кулындагы фөршаты[1] төшеп китте – ул һуштан язды. Шуннан Ширин сәрайга кайтты. Фәрһад бераз ятып, аһваһлар белән һушына килеп кичен өйгә кайтып бераз ял иткәч, төн уртасыннан торып, ахшамда ук эш урынына килде. Ике көн узды. Шириннең сабыры-тәкате калмады. Галәмдә беркем булмаган кебек вакытта бакчага килде. Һәм бичара Фәрһад тагын да элекке тиешле даирәсеннән чыгып, биһуш булып егылды. Ширин бу хәлне күрде дә, форсатны ганимәт белеп, тиз генә килеп, Фәрһадныә яңакларын берничә тапкыр үбеп, түбәндәге бәйтне язып дивана Фәрһадның баш очына куеп калдырды. **Бәйт** *Белмәм, мәләкме син яки фәрештә, Аклым алдың, әфәндем, бер күрештә. / Мин бит дәрт хәлләрен һич тә Белмәгән идем һичбер гәз. / Мәхәббәт бер бәла шәйдер, Грифтар булмаган белмәс.*

Шуннан соң Ширин сәрайга кайтып китте. Шунда Фәрһад һушына килеп, ул кәгазьне табып укыды. Тагын аһ итеп, һушыннан язды. Соңыннан акылына килеп, алтынлы рам һәм буяулар илә Шириннең рәсемен ясады.

Кич-иртән ул тасвиргә багып-карап, күңелен юатыр иде. Ләкин кичә-көндез күзләреннән яшь урынына кан агар иде[2]. Әмма бу тарафта Ширин дә саргаеп сулды. Менә бервакыт төн чагында гөлстанына сәрай паркына барып күшеккә каршы утырып, бу бәйтне сөйләде: *Ширин әфәнде бер ширингә*[3] *төште: Аһ итеп күңеле Ширингә төште. / Күзләребез шундук язмышка баглап, Фәрһад белән Ширин бу көнгә төште.* Фәрһад капка янында эшләр икән. Бу былбыл авазларын ишетеп, күңеле бер үлеп, бер терелеп, сабыры-тәкате калмыйча, шунда тагын бер

---

[1] Фөршат (гар.) – пумала.

[2] «Күздән яшь урынына кан агу», әлбәттә, төп-төгәл мәгънәдә түгел, фольклорда да төрелгән фразеологизм гына (күп тапкыр очрый).

[3] Ширин – төп мәгънәсендә «шикәрле су».

тапкыр аһ итеп, бу бәйтне әйтте: *Күзләрем шикәр имеш, Кем дисәң, Ширин имеш. / Мин аны шикәр дисәм, Чыннан да ширин имеш,* – дигәчтен, Шириннең сабыры-тәкате калмыйа, шундук йөгереп килеп, болар бер-берсенә сарылып гуя ки лаякыл исерек булдылар. Бераздан үз-үзләрен кулга алып, бераз шатлыча сөйләшеп, шуннан соң Ширин сәрайга китте. Фәрһад бичара тагын ялгыз калып бу бәйтне укып әңләнде[1]: *Минем күңелем дәртеннән, Һәр кала багып әңләнер. / Әңләнмичә мөмкин түгел, Бу хәлгә багып әйләнер.*

Шулай итеп, ул көн ахшам булып төзүчеләр башлыгы кул астындагыларга ялга рөхсәт бирде. Ширин белән Мәһмәнәбану килеп күшекне карадылар. Бик кәнагать булдылар вә тагын кечерәк күшек ясатырга карар кылдылар. Мәһмәнә төзүче башлыкны чакырып: «Афәрин осталыгыңа, әмма бу күшекнең каршысында тагы кечерәк бер күшек булуын телим һәм аның монысыннан бераз матуррак нәкышьле[2] булуын эстәр» – диде. Төзүче башлык «фәрман солтаннан» дип, киләсе иртәдә эшкә керешеп, берничә көн эчендә тагын бер күшекне төзеп куйды.

Бу көннәрдә Шириннең дайәсе[3] аның белән Фәрһад арасында мөгамәләрне күзәтеп тора иде. Һәм күңеленнән «бер нәккаш углы белән бер патша кызы арасында нинди мөнәсәбәт булырга мөмкин» дип, гыйшык уты барлыгын башына да китермәде. Ә тегеләр исә кичә-көндез гыйшык утында яндылар. Ул арада, кыскача әйткәндә, күшек тәмам булды. Нәккашлар да китеп бардылар... Мәһмәнәбану белән Ширин күшекне бер тамаша кылдылар да сәрайга киттеләр.

Көннәрдән бер көн Мәһмәнәбану сарае тирәсендә гизгәндә бер тирән чокырны ябып-бикләп торган зур бер таш күрде. Ул зур ташны заманында Сөләйман пәйгамбәр диюләре китереп куйганнар иде. Моның тирәсендә йөргәләгән җарияләр «әллә бу бер кое микән» дип, килеп колак тоттылар. Аста су агып ятканлыгын Мәһмәнәбануга хәбәр иттеләр. Мәһмәнәбану әмере буенча хезмәткәрләре килеп, ул ташны тырыша-тырыша бераз кузгатып, бер бакыр чиләк илә бераз су чыгардылар. Тик берәве дә ул суны эчергә җөрьәт итмәде. Үлемгә хөкем ителгән

[1] Әңләнде – моңланып җырлады.

[2] Нәкышь – бизәк, рәсем.

[3] Дайә – мөселманнарда балаларны билигъ булганчы (уналты яшькәчә) карап-багып йөрүче хатын.

бер кешене төрмәдән китереп, ул суны эчерделәр, берни булмады. Шуннан барысы да эчтеләр. Шикәр ширбәтенә охшаш эчемлек татыдылар. Ширин әйтте: «Бу су безнең касеребезгә[1] булса иде. Бер хәвез ясатыр идек». Мәһмәнәбану осталар чакырып каратты, чара таба алмадылар. Чөнки касер белән теге ташландык кое арасында зур тау бар иде. Мәһмәнәбану әмер итте: кем дә кем шул суны килтерер исә, ни теләсә шуны бирәм, – дип. Беркем дә батырчылык итмәде, чөнки «мөмкин түгел» диярләр иде. Тик Фәрһад кына бу хәбәрне ишетү белән: «Мин суны күчерә алам», – диде. Мәһмәнәбану: «Әгәр син бу эшне булдыра алсаң ни теләгең булса да, үтәрмен», – диде. Фәрһад әйтте: «И, шаһым! Минем синнән теләгәнем – капу агалыгыдыр[2]», – диде. Мәһмәнәбану: «Мин сине сәрайга эшкә алам, тәхеткә утыртам», – диде. Фәрһад: «Минем карашымда капу агалыгы синең тәхетеңнән дә биегрәктер», – диде. [Бу сүзләр] Мәһмәнәбануга ошап, шундук әмернамә булып, [сәрай хезмәткәрләренә] «эшкә ни кирәк булса, бирәсез», – дип фәрман итте.

Равилар әйтер ки, бу тарафта Ширин-назның хәле көннән-көн пәришан-кайгылы булып, гыйшкы ялкынланып, ниһаять, Мәһмәнәбанудан Фәрһадны барып күрергә рөхсәт сорады. Мәһмәнәбану рөхсәт итте. Ширин сәрайдагы күпсанлы кызлар вә җарияләр белән йөреп, җирле-мәхәлли мүрәдкә[3], арба-көймә остасына барып, бер мәгәлдәк[4] алып, юлга карар итте.

Ә бу тарафта Фәрһад бичара күрде ки, Ширин килә. Шундук кулындагы киркәсен куеп, сәламләүгә урынынннан торды. Мәрхәбәләшкәч Ширин сазын чиртеп, былбыл сайраган кебек бу бәйтне әйтте: *Мине җәфага салган җәя кашым каршымдадыр, Вә сөеп, бәндә итеп елаткычым каршымдадыр.*

Һәм кулындагы сазын Фәрһадка сузды. Карыйк, Фәрһад ничек җаваплар: *Бәндәсен җәфага салган, Йари-гарым[5] килде янә, гүзәлем. / Язгы гөлләр кеби миңа, гүзәлем, Һәрвакыт*

[1] Касер – ныгытылган сәрай.

[2] Капу агалыгы – капка сакчыларның башлыгы.

[3] Мүрәд – арба төре.

[4] Мәгәлдәк – ябулы карета.

[5] Йари-гар – Әбүбәкер сәхәбенең кушаматы, гомумилләштерелеп «тугры дус» мәгънәсендә дә кулланылынган.

*дөнья шатлыгы янә, гүзәлем. / Ләгылем*[1]*, күңел уем, рәхимле бул, Бул ягымлы Фәрһадыңа, гүзәлем. / Минем имкян юк хәзер үк, Сөймәгә, гүзәл шаһым. / Бар ки күкләрнең казасы, Валлаһи, шуңа аһым,* – дип сазын Ширингә бирде. Ширин дә тагы күрик ниләр сөйләде: *Ашкарә*[2] *булмас иде дәрт, бер кыенлык булмаса, Кемсәләр белмәс иде, аһ, бер кырын*[3] *як булмаса,* – дип болар бер-берләренә сарылып, ниһаять, серебезне берәрсе күрә калмасын дип, бәрәләп-куркынып тизрәк аерылдылар да, Ширин ялт-елт сараена килде. Шуннан соң Ширин һәр өч көн саен Мәһмәнәбанудан изен алып, тамаша итим дип Фәрһадны күрергә килер иде.

Равилар әйткәнчә, Фәрһад инде бер риваятьтә кырык көндә, бер риваятьтә бер елда Ширин гыйшыгында теге суны агызды. Су хәвезгә килгәч, бихисап корбаннар киселде – бәйрәм ителде. Мәһмәнәбану Фәрһадны баштанаяк кеш тиресеннән тегелгән киемнәргә төреп киендерергә теләде. Ләкин Фәрһад моңа бөтенләй игътибар итмәде. Фәрһадны мунчага җибәреп, бер букчайга затлы кием-салым күндерде һәм ул мунчадан чыккач шул киемнәргә киендерделәр. Шуннан Фәрһад Мәһмәнәбану каршысына килеп, җир үпте. Мәһмәнәбану әмер итеп, бер хушисле үлән түшәделәр, Фәрһадка бер хезмәткәр һәм бер кол тәгаен иттеләр. Әмма Фәрһад: «Мин үзем хезмәткәрмен, миңа хезмәткәр кирәкми», – диде. Ләкин Мәһмәнәбану ашчылар башлыгына әмер итеп: «Көн саен өч суфра миңа китергән шикелле тәгамьне аңарга бирәсез», – диде.

[Мәһмәнәбануның Фәрһадны үзенә ир итеп, патша ясарга тырышулары нәтиҗәсез кала. Шуннан соң Мәһмәнәбану Фәрһадны төрмәгә утырта. Фәрһад төрмәдә утырганда музыкаль аләтләрдә уйный, җырлый һәм шигырьләр яза. Аның шигырьләре бөтен илгә тарала. Бервакыт Мәһмәнәбануның төшендә Фәрһадны азат итәргә кушыла һәм Мәһмәнәбану аны төрмәдән чыгарта. Фәрһад шәһәрдән тауларга китә, анда берүзе, төрле кыргый хайваннар белән дус булып яши һәм Ширинне сагынып вә үз кайгысын белдереп җырлар чыгара. Бермәл

[1] Ләгыль – асылташ.

[2] Ашкарә (ф.) – Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән билге (знамение).

[3] Кырын – тискәре.

хайваннары белән калага килеп, Ширин яшәгән сәрай алдына тукталып, музыка чалып-җырлап Ширин белән аралаша. Ләкин Ширин сәрайда бикләнгән хәлдә, беркая да чыгалмый. Фәрһад тагын таулар арасына китә.

Бермәл ул таулар арасына Мәһмәнәбануга күрше дәүләт патшасы Хөрмүз яуга килә. Хөрмүз һәм аның аучылары төркеме бер тукталышта гаҗәп бер музыка һәм җыр авазларын ишетәләр. Эзләп барып карасалар – ерткыч хайваннар урталыгында үзе дә ерткычсыман булып беткән Фәрһад утыра. Хөрмүз аның белән сөйләшә, хәлен белә. Фәрһад бәйнә-бәйнә сөйләп бирә. Бу сүзләрне ишетеп, Хөрмүз Фәрһадны сөйгән яры Ширин белән кавыштырырга вәгъдә бирә].

Вә Хөрмүз шаһ Фәрһадка әйтте: «Егетем, шул кулыңдагы сазны беркадәр чал, минем өчен һәм дустың Ширин өчен. Һәм сукбайлык хәлләреңнән беркадәр шигырь сөйлә», – диде. Фәрһад та сазны кулына алып, карыйк, ни сөйләде: *Мин гашыйк, ялгыз вә хәйран кылды айрылу, Камәтем ким кылды, күзем яшь, коң*[1], *айрылу. / Айрылу чире кыйлгандыр күңелемне харап, Мондый кайгы күрмәдем күргәнче мең моң айрылу. / Язмышым елау икәндер дидем, и, шаһе-җиһан, И, ашинам*[2], *дәртең белән кайгы сондың (соңыннан) айрылу. / Кемне күрсәм дә хәлемә рәхим әйлә дим дә мин, Юк сине күргән берәү, кайчан беләр соң айрылу? / Аһ, нигә алдырдым кулдан, шундый назлы яр иде, Әй, гаҗәп, кемләр күрә ярны, булгач язмышың айрылу. / Фәрһадыңа йөз чөерде, дүнде бу чәрке-заман, Язмышым мал-мөлкемә гамьнәр өстәде бигөман. / Гадәтем булды шуннан соң миңа аһ илә фиган*[3], *Өсти гамьне вакыт үтү, җәй вә кышын айрылу,* – дип, тагын зар-зар елады. Болар хәйран калдылар. Шаһ әйтте: «Минем күңелем өчен тагын бер җыр җыла. Мин ант итәмен ки, Мәһмәнәбану минем таҗ вә тәхтемне тартып алалса да, мин вәгъдәмнән чигенмәм – Ширинне сиңа алып бирермен», – диде. Фәрһад бу сүзләрдән рухланып тагын шундый бер бәйт әйтте: *Айрылу кайгысын итәем мин кабаттан, Шулчаклы миңа ярымны күпсенде фәләк. / Галәм багында бардыр бер гөл-чәчәк аткан, Куймады шуңа мине, гүяки*

---

[1] Коң, куң – эрен.

[2] Ашина – якын дус, интим дус, әшнә.

[3] Фиган – ачы зарланулар.

*күп күрде фәләк. / Аерды ярым Ширинне миннән ул тиз үк, Тиз таптым, тиз югалттым аны тик бер үбеп. / Бу тауларда ялгызын ялыктым гел йөреп, Миңа бер сөйкемле сөйәкне*[1] *күп күрде фәләк. / Гаҗәпме белдерсәм һаман да мин аһ-зарны, Яндыргач бу вөҗүдемне кайгыру нары. / Адаштыргач мине монда кайгы моңнары, Миңа кайдан бер кисәкне шулай күп күрде фәләк,* – дип, аһ итеп сазын кулыннан төшерде. Хөрмүз шаһ моның хәленә хәйран калып торды һәм әйтте: «Сиңа бер тәкъдимем бар, һа Фәрһад. Синең белән сәрайга китик. Бер хат язып Мәһмәнәбануны күндерик. Әмма сиңа бу кыяфәттә йөрергә ярамас, киендереп бөтәйтик[2]. Шуннан Ширинне таләп итәрбез.

Фәрһад разый булып, сәрайга килделәр. Фәрһадны мунчага китереп, пакъ юындырып, чиста киемнәр киендереп, шаһ диванханәсенә китерделәр. Хөрмүз шаһ аның бу кыяфәтен күреп «афәрин!» диде.

Шунда ул Мәһмәнәбануга бер намә язып, капучылар җитәкчесенә – диздарга тапшырып, адресатка бирдерде. Фәрһад исә шаһ хезмәтендә калды, Кәтхода-диздар Мәһмәнәбануның сараена килеп намәне-хатны вәзиргә бирде. Вәзир исә Мәһмәнәбануга, Мәһмәнәбану исә Диван әфәндесенә[3] бирде. Ул хатны өнләп, кычкырып укыды. Намәдә болай язылган иде: «Мин ки, Хөрмүз шаһ, ярдәмчем Фәрһад агага[4] карендәшеңнең кызы Ширинне кәләш итеп, тиешлечә җиһазландырып миңа күндерәсең. Әгәр “юк” дисәгез, минем көчемә таулар да тагу[5] булмас! Сугыш ачып, кул[6] куәтем илә алырмын, соңыннан “белдем” яисә “белмәдем”, димәссең», – диелгән.

[Ләкин Мәһмәнәбану риза булмый. Моннан соң ул батырлары белән Хөрмүз шаһ батырлары арасында бергәбер көрәшләрне бәян итүгә күп урын бирелә. Көрәшләрдә Фәрһад та актив катнаша. Мәһмәнәбану үз тарафына бер-бер артлы

---

[1] Сөйкемле сөйәк – сөйгән яр.

[2] Киендереп бөтәйтик – матур гына киендерик.

[3] Диван әфәндесе – диван сүзе текстта дәүләт советы; диван әфәндесе – дәүләт советының рәисе, ул дәүләтара хатларны кычкырып укыган.

[4] Фәрһад монда беркемгә дә «ага» түгел, ага монда «официаль дәүләт кешесе» мәгънәсендә.

[5] Тагу, таңгу – киртә, комачау.

[6] Кул – гаскәр; колонна.

ике җадучыны китереп карый. Ләкин Хөрмүз шаһ тарафдарлары ул җадучыларның әмәлләрен җиңәләр һәм үзләрен дә юк итәләр.

Шул вакыйгалар эченә актив фигурант булып Хөрмүз шаһның углы Хөсрәү килеп керә. Җадучыларның кәсәфәте арасында, диелә, Хөсрәү Ширингә гашыйк була. Шулай итеп әсәрне Фәрһад-Ширин-Хөсрәү өчкеллеге җанландырып җибәрә. Мәһмәнәбануны берничек тә Ширинне туйлап бирергә күндереп булмагач, Хөрмүз шаһ бөтен гаскәре белән һөҗүмгә күчә һәм Мәһмәнәбану гаскәре тар-мар ителә, ул үзе көчкә исән кала (әсәрнең калган өзегендә аның турында сүз дә бетә).

Инде гашыйклар арасында барча кыенлыклар артта калды дигәндә, Хөсрәү Ширин өчен көрәш башлый. Аңа ярдәмгә (әсәрдә исемсез) бер даясе һәм яһүди Бәхтигян – Хөрмүз шаһның вәзире килә. Ширин белән Фәрһад инде кавышабыз, никях укытабыз дигәндә Фәрһадны янә канал казуга җибәрәләр. Эшеңне бетергәч өйләнерсең, диләр. Хөсрәү Фәрһадны шунда үтермәкче була].

Беркөн Хөрмүз шаһ диванга килеп күрде ки, Хөсрәү юк. Соңыннан сорады: «Углым ни өчен диваныма килмәде?» Әйттеләр ки, «кәефе булмаганга килмәде». Шуннан соң Хөрмүз биш хәким-табибны китереп әйтте: «Бар, шаһзадә янына бар, аның сәламәтле-әхвале ничек икән?» Хәким килеп күрде ки, гыйшык галәмәтләре бар, хасталык түгел. Һәм моны этисенә әйтте. Падишаһ углының дайәсен чакырып китереп әйтте: «Барып шаһзадәдән сөальәйлә – кемгә гашыйк, ул синнән яшермәс», – диде. Дайә шундук белдерде: «Шаһзадә Ширингә гашыйктыр», – диде. Хөрмүз шаһ вәзире булган яһүди. Бәхтигянны чакырып әйтте: «Мондый хәлгә чара нидер?» – диде. Бәхтигян әйтте: «Миңа өч көн миһләт бирегез, аның чарасын табыйм», – диде. Падишаһ: «Бик әйбәт», – диде.

Бәхтигян ханәсенә килеп бер шәйтани фикергә килде. Шуннан соң шаһка килеп әйтте: «Шаһым, фәлән тауның итәгендә бер сулык бар, су буылып тора, шул суны агызып бу тарафка китерсәң, Ширинне сиңа никяхлап-туйлап бирермен», – диде. Һәм Хөрмүз шаһ та бу фикерне хуп күреп, Фәрһадка тәклиф итте: «Ишеткәнемчә, Мәһмәнәбануның хәвезенә су китергәнсең», – диде. Фәрһад бичара гыйшыклык утында иде. Тик нишләсен? Моны ишетеп ай итте. Башын түбән салып,

фәләк, ае аңарга кара кебек күренде... Фәрһадның елап әйткәне: *И, фәләк, нишлисең, ничек котылыйм кулыңнан мин, И, кара бәхетем, нинди караңгы көннәргә салдың син».* Моңа өстәп әйтте: *«И, шаһым, баш өстендә җаным корбан булсын. Ярым юлында шундый кыенлыклар икән, монда Хак Тәгаләнең бер хикмәте бардыр, киркәмне китерегез».*

Күрсәтелгәнчә, Фәрһад өч йөз батманлы киркәсен алып текә кыяларны кырып-ватып түбәнтен юл ачмага булды. Равиләр әйтер ки, Хөрмүз шаһ Ширингә бер җария тәгаенләде. Ул җария Ширинне бик яратты һәм ислам диненә мөшаррәф булды, Шириннән гайре илә якынлашмады. Ширин дә ул җарияне үзенә ахирәт итте. Ул вакыт-вакыт Фәрһадка сәлам җиткереп, сәлам китерер иде. Атын Гөлбәйаз диерләр иде.

Көннәрдән бер көн Ширин сердәше булган җариягә: «Фәрһадка миннән сәлам әйлә һәм бер кәррә йөзен күреп кил. Һәм мин дә сиңа багып, күңелем ачылыр иде», – диде. Гөлбайаз тауларга юнәлде һәм Фәрһадны күреп килде. Кырык көнләп тагын тау кискәч, эше бетмәчәген әйтте. Ширин аһ итеп елый башлады. Гөлбайаз Ширинне юатып: «Кайгырма, ахыр чиктә Фәрһад синеке була», – диде. Шуннан бер-берсенең махсус серләре турында сөйләштеләр.

Бер көн Хөрмүз шаһ вәзиргә һәм Хөсрәү шаһзадәгә: «Бүген Фәрһадның хәлен белеп килик», – диде. Болар өчәүләшеп чыгып киттеләр. Күрделәр ки, Фәрһад янында бихисап арыслан вә капланнар әйләнгәләп йөриләр. Фәрһад шаһның килгәнлеген күргәч, киркәсен болгап, ул җанварларны читкәрәк куалап җибәрде. Болар читкә китеп тыныч кына утырдылар. Бу өчәү дә Фәрһадның эшен күреп, хәйран булдылар. Ташка бәргән саен таш тузан булыр иде. Диюләр дә эшли алмаганча эшли иде. Шаһ һәм вәзир таң калдылар. Тагы сәрайга кайтып киттеләр. Шуннан соң Гөлбайаз җария дә хуҗа туташына әйтте: «Бер көнен без дә барып Фәрһадның тау ярганын күрсәк иде», – диде. Һәм кичен барып, шаһтан рөхсәт алдылар. Иртән бүтән җарияләргә дә әйтте: «Сезләргә дә шаһтан рөхсәт алдым, әйдәгез Фәрһадны күреп килик», – диде. Ширин: «Менә мин дә барыйм», – дип өзгәләнде.

Кичә вә көндез аһ итеп аны уйлый иде. Хөрмүз шаһ та Фәрһадның янына барып, Фәрһад өчен тагы йөрәге янып, нык ачынды. Тиз арада Ширинне Фәрһадка никаяхландыру

уена килеп, сәрайга кайтты. Солтанга[1] әйтте: «И, минем банди-җиһаным[2], минем моннан Фәрһадка тыныч багарлык түземлегем калмады, сабыр-тәкатем бетте», – дигән кебек шактый сөйләште. Соңра читтән генә Ширингә: «Шаһың сиңа рөхсәт бирсен, тагын бер барып, Фәрһад белән күрешсен, моннан соң аңа ни булыр, ни булмас, дөнья халедер», – диде. Һәм Ширин вә Гөлбәйаз тагын бер кич җарияләр белән тауга бардылар. Ширин Фәрһадны күреп, аның бу хәлләргә грифтар булганлыгыннан күп елады. Фәрһад Ширинне тагын күреп ошбу бәйтләрне сөйләде: *Йөрәгеен көйдермә Фәрһадның, Ширинем – йөрәгемә дәртенымсың. / Гөлләргә көлмәк (?) ярашыр, ди, Былбыла гөлләр ярашыр, ди,* – дип бер-берсенә моңлы карашып, елаштылар. Инде Фәрһад та тагын сазын кулына алып, бер тапкыр аһ дип, җаны-күңеленнән алып, бу бәйтне әйтте: *Күзем кәбаб булды гыйшкың утында, Пәрванәмен, ләкин янып та тормам,* – дип сазын Ширингә бирде. Ширин сазны алып ошбу бәйтне әйтте: *Күңелсезләнмә хәзер, әйтмә аһны – Гашыйкларга аерылу килә инде. / Кил, тыңла сүзем, гүзәлләрнең шаһы, Елаганнар бер көнен көлә инде. / Тулган ай кебек әйләнмә-дуланма, Вә каршымда мескен булып кыланма. / Мине сөймәс диеп төрле уйланма, Сөярләр сөеп карар, белмисеңме,* – дип Фәрһадның кискән ташларын караштыра башлады. Күрде ки, эше күп калмаган икән. Бәс тагын Хак Тәгаләгә сине миннән, мине синнән аермасын, дип җырлап кабатлады: *Теләгем бу минем, и, Изге Мәүләм,Аермасын мине синнән, сине миннән,* – дип үзе дә Фәрһадның йөзенә багып, аһу күзләреннән[3] энҗе даналәре кебек яшьләре агып чыкты, Фәрһадның йөрәген даглады. Фәрһад шундук Ширингә: «Елама, җөкәреңнейөрәгеңне яндырма. Инде нибары дүрт-биш көнлеге эш калды», – дип ошбу бәйтне әйтте: *Китәр кальбеңдәге сары, Шатлык аятләре килде, / Ирештек – туйга аз калды, Сафа аятләре килде,* – дигәч, Ширин бер сүз әйтте: «Минем тугърылыклы гашыйгым, Фәрһадым, минем күңлемдәге телемдә, монда килгәндә атымның таягы каерылды, әйбәт галәмәт түгелдер.

---

[1] Солтан дип еш кына патша хатынына яисә кызына әйткәннәр.

[2] Банди-җиһаным – бу дөнья белән бәйләнгән әйбер-күренешләр.

[3] Аһу күзләр – тау кәҗәләре – аһуларның күзләре Шәрекъта традиция буенча иң матур күз мисалы санала.

Әмма, әй, Раббем, хәерлегә булсын», – дигәч Фәрһад та бер аһ итеп түбәндәге бәйтне сөйләде: *Бу дөньяда морадыңа ирешү ятлардан тора, Безнең дә бу эшебез, язмыш Алладан тора,* – дигәч, болар бер-берсе белән хушлашып, Гөлбәйаз белән Ширин тагы сәрайга килделәр. Ширин кабат төшендә күрде ки, Фәрһады каршына бер ерткыч хөйван килеп, һөҗүм итеп, атылып Фәрһадның өстенә менде, үзен яклый алмыйча калды. Ширин уянып, кайгыга төште. Гөлбәйазга сөйләгәч, ул: «Хәерлегә була, әфәндем». Әмма Ширин әйтте: «И, җаным Гөлбәйаз, Фәрһадны барып күр, иртәгә иртән кайтып җит». Ләкин соңра кешегә ышанмыйча төн уртасында үзе барып, Фәрһадны саусәламәт, йоклаган хәлдә күреп, Хакка күп мактаулар, данлаулар әйтеп, шөкерләр итеп кайтты. Ләкин халык арасында сүз чыкты ки, Ширин килеп йөри икән, дип. Һәм Фәрһад төннәрен уянып, куышында йокысыз ята торган булды. Ниһаять Ширин назамин (назлы) көндез килеп Фәрһадны күргәч: «Әлһәмделилляһ ки, сине сау-сәламәт күрдем, дип төнге вакыйганы сөйләп бирде. Һәм Фәрһад барысын да хәергә юрады. Ширин бәйт әйтте: *Әлһәмделилляһи төнлә сау-сәламәт таптым сине, Җан бәдәндә икән, Мәүләм аермасын синнән мине,* – диде. Фәрһад, Ширин үзенең куркыныч төшен сөйләгәч, бераз күңеле төшсә дә, белдермичә хәерлегә юрады һәм бәйт әйтте: *Эчкәнмен икән көлкеле бу ярым мәҗлесендә мин...».*

**Әдәбият**

1. Ахметзянов М.И. Новые археографические материалы и их значение в исследованиях по истории татарской литературы: дис. ... д-ра филол. наук, Казань, 1998. С. 285.

2. Әхмәтҗанов М. Шагыйрь Әхмәтҗан Тубыли // Казан утлары. 1997. № 1. Б. 147–154.

3. Казан (Идел буе) федераль университеты Н.И. Лобачевский исем. Фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. Ф. 22. Сакл. бер. 701-Т. Б. 11–49б.

4. Хасавнех А.А. Ахметзян Тубыли: жизнь и творчество татарского поэта-суфия XIX века. Saarbrücken: LAP LAMBERT Academic Publishing, 2012. 206 с.

5. Котб. Хөсрәү вә Ширин (шигъри роман). Казан. Мәгариф, 2003. 363 б.

**Хәйретдинов А.Г.**
**Казан**

# МУСА БИГИЕВНЕҢ КУЕН ДӘФТӘРЛӘРЕНДӘ XX ЙӨЗНЕҢ БЕРЕНЧЕ ЧИРЕГЕ ЯКЫН КӨНЧЫГЫШ ТАРИХЫ

*Статья посвящена обзору одного из дневников с личными записями выдающегося татарского религиозного деятеля и мыслителя Мусы Джаруллаха Бигеева (1873–1949), в которых ученый излагает свое видение проблем Ближнего Востока во второй половине XX века.*

Якын Көнчыгыш гомер-бакый дөнья тарихына юнәлеш бирүче үзәк нокта булган һәм булып тора. Яһүдилек, нәсара һәм ислам диннәренең шушы төбәктән чыгышы да, андагы бүгенге көн вакыйгалары бу фикерне катгый төстә раслый. Дөньяның иң әһәмиятле урыны булган Якын Көнчыгыш җирләренең тарихы, андагы хәлләр белән кызыксыну татар галимнәренең, аерым алганда, Муса Бигиевнең мирасында да чагылыш тапкан.

Белүебезчә, 1914 елдан башлап дөнья тарихы тәгәрмәче күчәреннән чыккандай үз ирке белән тәгәрәп китә. Үзгәрешләр туфаны Рәсәйне дә читләтеп узмый: 1917 елда Октябрь инкыйлабы, дүрт елга сузылган Ватандашлар сугышы, 1922 елда Советлар Берлеге исемле илнең барлыкка килүе... Мондый шартларда татарлар өчен ераклардагы Мәккә-и мөкәрәмә, Мәдинә-и мөнәвәрәне, Кәгъбә-и мөгаззәмәне һәм Пәйгамбәр мәчетен барып күрү генә түгел, авыл мәчетеннән азан тавышын ишетү, бергәләп намаз уку рәхәтлекләре дә хыял гына булып кала. Шулай итеп, татар мөселманнарының рухи тормышы торгынлык, караңгылык, эзәрлекләнү дәверенә керә.

Әмма Совет дәверенең беренче дистәеллыгында әлеге тискәре калыплар кысаларына сыймаган вакыйгалар да булган. Шундый вакыйгалар мисалын 1923 елда кулга алынып, өч ел дәвамында Мәскәүдә ОГПУ, соңрак НКВД күзәтүе астында калырга хөкем ителгән сәяси тоткын Муса Җаруллаһ Бигиевнең тормышында табып була. 1923 елда Берлинда «Ислам милләтләренә чакыру» исемле китабын нәшер итү һәм кайбер башка

сәбәпләр аркасында ОГПУ тарафыннан кулга алынган Муса әфәнде сөргендә 1924–1926 еллар дәвамында булган.

Шул елларда Якын Көнчыгышта барган кискен, киң колачлы һәм тирән сәяси зилзиләләрдән купкан давыллар Мәскәү сөргене хәлендә гомер кичергән Муса Бигиевнең тормышына да бәреп керә. Нәтиҗәдә, акылга сыймаслык, могҗизага тиң өч вакыйга булып ала.

Аларның беренчесе болай була: сәяси сөрген халәтендә Мәскәүдә яшәп яткан Муса әфәндегә 1926 елның май аенда Каһирәдә үткәреләчәк Бөтендөнья мөселман корылтаен оештыру комитетыннан чакыру килеп төшә. Совет хөкүмәте Бигиевкә Каһирәгә барып конгресс эшендә катнашырга рөхсәт бирә, тик ул вакытта Мисырның эчке һәм тышкы тормышын үз кулында тоткан Бөекбританиянең колониаль идарәсе Муса әфәндегә виза бирүне тыя.

Вакыйгаларның икенчесе будыр: Бөтендөнья мөселман җәмәгатьчелегенең Каһирә корылтаен танымавы аркасында мөселман конгрессын шул ук 1926 елның июнь аенда Мәккәдә үткәрү турында карар кабул ителә. Бу корылтайны оештыру комитеты Муса әфәндегә дәгъвәтнамә ирештерә. Бу очракта да Совет хакимият органнары Муса Бигиевкә чит илгә чыгуны рөхсәт итәләр. Шулай итеп, сәяси сөрген булган Муса әфәнде СССР мөселманнары делегациясе составында, Мәскәү мөселманнары вәкиле буларак, 1926 елда Мәккә корылтае эшендә катнашып, кире ватанына кайта.

Өченче вакыйга исә 1927 елның язы җиткәч, әле кичә генә диярлек сәяси тоткын халәтеннән чыккан Муса Бигиевнең мөбарәк хаҗ сәфәренә чыгып китә алуыннан гайбарәт. Аңлашыла ки, танылган дин галименә әлеге өч сәфәрне кылу мөмкинлеген бирүче Совет хөкүмәте үзе була. Бу өч вакыйга Муса әфәнденең СССР күләмендә никадәр абруйлы дин галиме булуын кабат таныта.

Бу мәкаләдә бәян ителәчәк хәбәрләр Муса әфәнденең 1927 елда кылган сәфәренә кагылышлы шәхси язмаларына нигезләнә. Галимнең куен дәфтәрләрендә сакланып калган ул язмалар аның шул чор Якын Көнчыгышның сәяси вәзгыятен тасвирлауга багышланган. Биредә ул язмаларга кыска тасвирлама биреләчәк. Әлегә кадәр ул язмаларның эчтәлеге, аларда каралган темалар беркайда да бәян ителмәгән, бу йөздән алар

фәнни җәмәгатьчелек игътибарына тәүге мәртәбә тәкъдим ителәләр.

Башта Муса әфәнденең мәзкүр куен дәфтәре турында бер-ике сүз әйтеп узыйм. Әлеге блокнот Анкарада урнашкан Төркия Милли китапханәсендә A5924 номерлы саклау берәмлеге буларак саклана. Блокнотның үлчәмнәре якынча 200х140 мм тәшкил итә. Блокнотның күләме 124 бит, аннан кала 4 бит форзацлары бар. Форзацлар куе яшел төсле калын кәгазьдән ясалган булса, язу сәхифәләрнең кәгазе саргылт төстә. Язу битләрендә аркылыга сузылган 20 шәр нечкә зәңгәрсу сызык бар. Блокноттагы һәр кушбитнең өске сул почмагында карандаш белән кушбитнең номеры язылган.

Блокноттагы язмаларның бер өлешен галимнең 1927 елда кыйлган хаҗ сәфәренә кагылышлы текстлар тәшкил итә. Шартлы рәвештә «хаҗнамә» дип аталган әлеге текст беренче номерлы биттән башланып, 28 нче номерлы кушбиттә тәмамлана, ягъни аның күләме 55 бит тәшкил итә. Хаҗнамәдән соң килгән 29-30 номерлы кушбитләрдә нинди дә булса язулар юк. Шул рәвешле автор хаҗнамә текстын башка эчтәлекле һәм башка вакытта теркәлгән язуларыннан аерган булса кирәк. Алга таба язулар 31 номерлы кушбиттән дәвам итә. Аларның тематикасы хаҗнамәгә турыдан-туры кагылмый. Моны истә тотып, куен дәфтәрендәге текстны ике өлешкә бүлеп өйрәнү мәгъкуль дип табылды: 1 нче кисәк – Хаҗнамә, 2 нче кисәк – Ислам дөньясының, аерым алганда Якын Көнчыгышның ул замандагы сәяси вәзгыятенә һәм мөселман корылтайларына кагылышлы язмалар. Шулай да әлеге бүленеш шартлы, чөнки Якын Көнчыгышка караган язмалар дәфтәрнең хаҗнамә өлешендә дә мул итеп сибелгән.

Гомумән алганда, Муса Бигиевнең хаҗнамәсе татар халкында шактый киң таралыш тапкан күркәм гадәтнең бер чагылышы булып тора. Муса әфәнде, мөгаен, хезмәтен бастырып чыгару турында уйламагандыр. Әмма ни генә булса да, Муса Бигиевнең хаҗнамәсе Совет дәверендә кылынган хаҗ турында уникаль әсәр булып калачак. Ул гына да түгел, бу истәлекле язманың хәтта бердәнбер шундый әсәр булуы да бик ихтимал. Блокнотның беренче өлеше, ягъни хаҗнамәгә караган язмалар нигезендә «Русиядән, димәк мөмкин, ялңыз бән» исемле китап чыгарырга насыйп булды [1].

Фәнни әдәбиятта 1926 ел Мәккә корылтаеның эшчәнлеген, анда күтәрелгән мәсьәләләрне, делегатларның активлыгын бәян иткән хезмәтләр бар, шуңа күрә бу темага биредә кагылып тормыйм. Безне кызыксындарганы, югарыда әйтелгәнчә, Муса әфәнденең 1927 елда хаҗ кыйлган вакытта кәгазьдә теркәп барган язмаларга карый. Чынлыкта, хаҗнамә дип телгә алынган язмалар бары тик изге сәфәрнең ничек булганын тасвирлауга, галимнең анда күргән-тойганнарын сурәтләүгә генә багышланмаган. Хаҗ белән бергә Муса әфәнде актив рәвештә сәяси эшчәнлек белән дә шөгыльләнә һәм шул чактагы сәяси вәзгыятьне сурәтли, аңа бәясен бирә. Бу хәлнең үз сәбәпләре бар. Беренчедән, 1926 ел Мәккә корылтаенда элеге Конгресс ел саен хаҗ вакытында җыелачак дигән карар кабул ителгән була.

Әмма 1927 елда билгеле сәяси сәбәпләр аркасында корылтай үткәрелми, әмма аның идарәсенең эшчәнлеге дәвам итеlә. Муса әфәнде нәкъ әнә шул идарә эшләрендә, аерым алганда, күренекле җәмәгать эшлеклеләре белән төрле очрашулар үткәрә, Корылтай идарәсенең мәҗлесләрендә катнаша. 1926 елның 10 гыйнварында үзен Хиҗаз, Нәҗед һәм Көньяк биләмәләрнең мәлиге дип игълан иткән Габделгазиз ибн Сөгудкә атап язылган махсус мөрәҗәгатьләр һәм башка төрле документлар әзерләүдә һәм аларны гамәлгә куюда үз ролен башкара.

Бу дәвердә Муса Бигиев очрашкан күренекле тарихи шәхесләрнең кайберләрен атап узам:

*Габдерәүф улы Кәрим Хәкимов* (1892–1938) – Советлар Берлегенең гарәп дөньясындагы беренче дипломаты. Кәрим Хәкимов ярлы гаиләдә туа, «Хөсәения»дә белем алган (1908–1910 елларда), анда 1909 елның көзендә мөгаллимлек кылган Муса Бигиев дәресләренә йөргән булуы да мөмкин. 1917 елдан башлап Кәрим Хәкимов гражданнар сугышында катнаша, Кызыл армиянең мөселман полкларын оештыра, Татар-Башкорт республикасына нигез салучыларның берсе була. 1920 елда Хәкимовны РСФСР ның Бохарадагы вәкаләтле вәкиленең, ягъни В.В. Куйбышевның урынбасары итеп куялар. 1921 елда Хәкимовны, Иранга җибәреп, Мәшһәд шәһәрендәге Генераль консулы итеп куялар. 1923 елдан шул ук вазифаларны ул Рәшт шәһәрендә башкара башлый. 1924 елның август аеннан башлап, Совет хөкүмәте Җәддәдә үзенең дипломатик агентлы-

гын һәм Генераль консуллыгын булдыра. Гарәпләр белән яхшы дипломатик мөнәсәбәтләр коруның никадәр әһәмиятле булуын аңлаган совет хөкүмәте әлеге хезмәтне бары тик мөселман кеше җитәкләргә тиешлеген аңлаганга күрә, Генераль консул итеп Кәрим Хәкимовны билгели. Шулай итеп, Кәрим Хәкимов Советлар Берлегенең башта Хөсейн әл-Һашими идарә иткән Хиҗаз мәмләкәте, соңрак Ибн Сөгуд идарәсендәге Хиҗаз, Нәҗед һәм кушылдырылган вилаятьләр солтанлыгы белән дипломатик мөнәсәбәтләрен җайга салган кеше була. Гарәпстанда үткән дипломатик хезмәт елларында Кәрим Хәкимов белән Ибн Сөгуд ныклап дуслашалар. К. Хәкимов СССРдан гарәп илләренә кирәкле промышленность товарлары китертүне җайга сала, җирле халыкка медицина ярдәме күрсәтүне оештыра. Мәсәлән, 1927 елда ул диңгез юлы белән Одессадан Җәддәгә шикәр, он, керосин поставкаларын оештыра. Шул заманнан бирле җирле халык югары сыйфатлы онны «мускуби», ягъни «мәскәүнеке» дип атый. Шул рәвешле татар дипломаты гади гарәпләрнең дә ихтирамын яулый. Моннан тыш К. Хәкимов хаҗилар өчен махсус рәвештә Одесса-Җәддә маршрутлы пароход рейсларын оештыра. Муса Бигиев хаҗга нәкъ әнә шундый пароходларның берсе белән килә.

*Йосыф Йасин* (?) – Сүриядә туган. Гарәпстанга 1923/24 елларда килеп, Нәҗед солтаны Габделгазиз ибн Сөгудкә якыная, аның сәяси сәркәтибе була, соңрак дәүләт министры, мәмләкәтнең сәяси департаменты рәисе дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Мәккәдә чыккан һәм Муса Бигиевның хаҗнамәле куен дәфтәрендә еш кына искә алынган «Өмме-л-Кура» исемле гәзитнең редакторы була.

*Шәрәф Гаднән* (?) – 1926 елда Мәккәдә үткәрелгән Бөтендөнья мөселман Корылтаеның Хиҗаз делегациясе вәкиле була, Корылтайның рәисе итеп сайланыла.

*Хафиз Ваһбә* (1889–1969) – Мисырда туган, 50 ел гомерен сөгуди мәликләргә хезмәт итүгә багышлаган кеше. Габделгазиз ибн Сөгуд 1925 елда Мәккәне яулап алгач, Хафиз Ваһбә шәһәр башлыгы (мэр) вазифаларын үти башлый. Соңрак мәмләкәтнең мәгариф департаментын җитәкли, 1938 елда, Сөгуд Гарәпстанының Япониядәге илчесе буларак, Токио мәчетенең ачылыш тантанасында катнаша. Хафиз Ваһбә шулай ук Рим папасы каршында Сөгуд мәлигенең вәкиле була. Соңрак

дəвердə ул Сөгуд мəмлəкəтенең Англиядəге илчесе булып хезмəт итə.

*Габдулла əд-Дамлуҗи* (?) – Гыйракта Мосул шəһəрендə туган, 1915 елда Ибн Сөгудкə тыйбби киңəшче һəм табиб буларак яллана. Француз телен белүе сəбəпле, аны əр-Риядта чит иллəрдəн килгəн кунакларны кабул итү өчен җаваплы кеше итеп куялар. Ибн Сөгуд Хиҗазны яулап алгач, əд-Дəмлүҗига мəликнең Җəддəдəге вəкиле вазифаларын башкаруны йөклилəр. Соңрак Сөгуд Гарəпстанының тышкы эшлəр министры урынбасары буларак 1930 елга кадəр хезмəт итə.

*Тəүфыйк Шəриф* (?) – 1926 елда Мəккəдə үткəрелгəн мөселман Корылтаенда Əсир вилаяте делегацисенең вəкиле була, Корылтайның сəркəтибе вазифасын үти.

*Мөхəммəд Əсадулла* (*Леопольд Вайс*, 1900–1992) – журналист, ислам темаларына язган язучы, дипломат. Русиядə туа, 1926 да ислам динен кабул иткəч, Мөхəммəд Əсадулла дигəн исем ала. 1927 елда гаилəсе белəн хаҗга чыгып китə. Көн күрер өчен Əсадулла Аурупа гəзитлəренə гарəплəр тормышы һəм җирле сəяси-икътисади хəллəр турында мəкалəлəр язып тора. Шундый эшчəнлеге аркасында Ибн Сөгудкə якыная. 1932 елда Əсадулла Һиндстанга китеп, Пакьстан мөселманнарының Һиндтан аерылуны күздə тоткан мөстəкыйльлек көрəшенə чума. Милли азатлык көрəшенең лидерлары Мөхəммəд Икъбал һəм Мөхəммəд Гали Җинна белəн дуслаша. Биредə Əсадулла урду телендə беренче гəзитлəр бастыруны оештыра. 1947 елда Пакьстан дəүлəте барлыкка килгəч, Əсадулла Ислами терелеш департаменты мөдире итеп билгелəнə, илнең конституциясе текстын əзерлəүдə катнаша. 1951 елдан башлап, Пакьстанның БМО (ООН)дагы вəкиле була. 1954 елда Əсадулла «Мəккəгə юл» исемле китап яза, инглиз теленə Коръəннең иң яхшылардан саналган тəфсирле тəрҗемəсен ясый, шəригатьнең дəүлəт аспектлары турында хезмəт яза, Каһирəдəге əл-Əзһар университеты профессоры да була.

Муса Бигиевнең куен дəфтəрендəге язмалардан күренгəнчə, Корылтай эшчəнлегендə катнашудан тыш, Муса əфəнде параллель рəвештə Якын Көнчыгыштагы сəяси халəтне дə игътибар үзəгендə тоткан, җирле матбугатта басылып килгəн язмалардан да хəбəрдар булган. Аеруча Хиҗаз, Мисыр, Төркия, Һиндстан кебек иллəрнең сəяси-икътисади халəтен,

тын-сулышын тоеп күзәтеп торган. Мисал өчен биредә Муса Бигиевнең куен дәфтәрендә аерып күрсәткән темаларның кайберләрен атап узам:

*Төркия-галәме ислам; Төркия хуҗалары*. Бу теманы Бигиев һәрчак игътибар үзәгендә тоткан, империя булудан туктап, яңа дәүләт буларак оеша башлаган Төрек Республикасы җитәкчеләре белән аралашкан, илдә барган үзгәрешләрне, казаныш вә югалтуларны анализлап торган.

*Габдел-Ваһһабның әйткәннәреннән*. Муса әфәнде ваһһабилык идеологиясенең килеп чыгышын, аның эчтәлеген тирәнтен өйрәнгән һәм моның өчен бу идеологик агымга нигез салучының да мирасы белән танышкан.

*Өммел-кура*. Ибне Сөгуд солтанлыгының дәүләт басма органы булган гәзит. Муса Бигиевнең көндәлегендә әлеге гәзит сәхифәләрендә басылып чыккан, төрле темаларга караган материаллар белән кызыксынган булуы чагылыш таба.

*Мөбәйага*. Ибне Сөгуд үзен Нәҗед, Хиҗаз һәм кушылдырылган вилаятьләр солтаны дип игълан иткәннән соң, яңа хөкемдарга гарәп кабиләләренең ант итүләре мәсьәләсе дә Муса Бигиевнең игътибары үзәгендә торган.

*Ибн Сөгуднең вәхдәт гарәбиядә гакыйдәсе*. Муса әфәнде Ибне Сөгуднең гарәпләрне берләштерү турындагы идеяләрен, бу хакта булган инануын анализлаган.

*Хәлифә тарыд кыйлынды*. Муса әфәнде Госманлы дәүләтенең юкка чыгарылуын авыр кичергән. Биредә ул Төркия Бөек Милләт Мәҗлесенең 1924 елның 3 мартында кабул иткән № 431 канун карары белән Хилафәтне юкка чыгаруы һәм шул ук көнне соңгы хәлифә II Габдулмәҗидне гаиләсе белән бергә Төркиядән куылуы турында хәбәр теркәгән.

*Хилафәт*. Муса әфәнде мөселманнарны берләштереп торган Хилафәтнең юкка чыгарылуыннан соң, аның язмышын хәл итү белән турыдан-туры шөгыльләнгән, мәсәлән, югарыда искә алынган Каһирә корылтае да, Мәккә корылтае да нәкъ әнә шул хилафәт мәсьәләсен чишү максаты белән үткәрелгән булалар.

*Һиндстан хакында инглиз сәясәте; Һиндта ислам*. Куен дәфтәрендә Һиндстан мөселманнары тормышы, андагы фикер агымнары, мөселман сәяси хәрәкәтләренә багышланган язмалар еш очрый.

*Хиҗаз тәгълимат әсасиясе; Шәкл-е хөкүмәт Хиҗазда; Мөлкият гаҗләсе*. Хиҗазда хакимлек иткән Һашимиләр солтанлыгы Ибне Сөгуд тарафыннан тар-мар ителгәннән соң барлыкка килгән сәяси вәзгыятькә багышланган язмалар әлеге темаларда искә алыналар.

Аңлашыла ки, әлеге кыска мәкаләдә Муса Бигиевне Якын Көнчыгышка кагылышлы сурәттә кызыксындырган барлык темаларның эчтәлеген генә түгел, хәтта исемнәрен генә атап чыгу да күп урын алачак. Шуңа күрә алга таба ул темаларны бәйнә-бәйнә атап кына чыгам:

Гакабә-Мәган хакында; Корылтай бәхәсләре; Хаҗ дәгъвәте; Өфө протесты; Галәме ислам ихтыяры; Сөгуднең протесты; Сөгуднең әүвәлге дәгъвәтләрендә биргән вәгъдәләре; Гарәп хәрәкәте хакында халыкның ул вакыттагы дөрест карашы; “Манар” сахибы Рәшид Рида; Алмания-Төркия; Гарәп дәгъвасы; Төркия белән ислам галәменең мөнәсәбәте; Гарәпләрнең нәһдәсе; Иранлыларның хаҗга бару мәсьәләсе; Бөтендөнья сугышында өч дәвер; Әл-Кудсның алынуы; Стокгольм; Һашимиләрнең игъланы һәм үтенече; Өч төрле солых хакында; Хакыйкый Хилафәт; Каһирәдә беренче корылтай; Каһирә корылтае; Хилафәт шартлары; Хилафәтнең алмашуы; Каһирәдә Хилафәт мәҗлесе; Зәгълул һәм Хилафәт; Большевизм; Хилафәтне юкка чыгару.

Әлеге башламнар Муса әфәнденең XX йөзнең 20 нче елларындагы Якын Көнчыгыш халәтенең нинди яссылыклары кызыксындырганын чагылдыра. Күренгәнчә, галимнең сәяситарихи мәсьәләләргә кагылышлы язмалары күпкырлы һәм күпсанлы. Шул сәбәпле биредә аларның эчтәлеге белән таныштыру мөмкин түгел. Әмма бу эш эшләнә: хаҗнамәле куен дәфтәренең бу икенче өлешен урыс теленә тәрҗемә итү тәмамланып килә. Иншаллаһ, бастырып чыгару мәшәкатьләренең дә чираты җитәр.

**Әдәбият**

1. Хәйретдинов *А.Г.* Русиядән, димәк мөмкин, йалңыз бән... (Муса Бигиевнең 1927 нче елгы хаҗнамәсе). Тарихи-документаль очерк. Кереш сүз Ә.Т. Сибгатуллина. Казан: ТФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2016. 156 б.

**Шарафеева Р.Г.**
**Казань**

# ВОСТОЧНЫЕ РУКОПИСИ ИЗ АРХИВА САИДА ВАХИДИ В ФОНДАХ НАУЧНОЙ БИБЛИОТЕКИ им. Н.И. ЛОБАЧЕВСКОГО

*В статье затрагивается история развития и формирования рукописного фонда Саида Вахиди в Научной библиотеке им. Н.И. Лобачевского. Отдельное место занимает история становления Саида Вахиди как первого татарского археографа.*

В 1925 году в Казани при Центральном музее Татарской республики открылся отдел восточных рукописей и документов. В основном он состоял из собрания рукописей известного татарского археографа Саида Вахиди (1887–1938), известного исторической науке во многом благодаря обнаруженному им ярлыку Сахибгирей хана, единственному дошедшему до нас письменному памятнику периода Казанского ханства. Собрание Саида Вахиди включало 210 единиц хранения, найденных в разных районах Татарии. Став заведующим этого отдела, Саид Вахиди продолжил работу по сбору рукописей. К 1930 году фонд насчитывал более 1000 единиц хранения, среди которых свыше 100 рукописей Ибрагима Закировича Камалова (Чистополь), рукописные материалы Каюма Насыри (дер. Шырдан).

В 1929–1931 годах после объединения рукописных и книжных богатств Центрального музея, Центральной Восточной библиотеки и Книжной палаты, образовалась Татарская Академическая библиотека (Научная библиотека Татарской республики). Коллекция рукописей значительно пополнилась в результате историко-этнографических экспедиций в Чистопольский, Бугульминский, Мензелинский кантоны ТАССР, Белебеевский кантон Башкирии (1929) и Челнинский, Бугульминский кантоны (1930). Из деревень Тютери, Сулабаш, Кашкары были привезены личные архивы татарских ученых Х. Габаши, Н. Тунтери. Фонд также пополнился собранием рукописей библиотеки Г. Баруди, чей каталог хранится в фондах ОРРК; многочисленной коллекцией Дамуллы Салахетдина. В результате 1932 году количество рукописей достигло уже 2651 ед. хр.

Согласно постановлению Совнаркома ТАССР от 7 декабря 1932 года, эта библиотека была объединена с библиотекой Казанского университета, с 1940 года – Научная библиотека КГУ. Таким образом, вся эта богатая коллекция книг и рукописей в настоящее время хранится в отделе рукописей и редких книг Научной библиотеки им. Н.И. Лобачевского.

К сожалению, в инвентарных книгах нет записи о том, кому принадлежала та или иная рукопись, в графе: откуда поступила рукопись только общая фраза: ТАССР Мәркәз көтепханәсе. Но Саид Вахиди был очень аккуратным и все рукописи описал. Также на всех его рукописях имеется овальная печать-экслибрис на русском и татарском языке. И, я надеюсь, в будущем найдутся молодые ученые, которые займутся изучением этих рукописей.

В фондах отдела рукописей Казанского университета имеется «Описание восточных рукописей и документов пожертвованных С.Г. Вахидовым в 1925 году в Центральный Музей ТР через Академический центр Татанаркомпроса в Отдел Восточных рукописей Центрального Музея ТР», в котором приводятся некоторые автобиографические сведения о Саиде Вахиди.

«С малых лет мне приходилась многократно прослушивать от своих родителей и от любимого моего деда Абдуллатыйф бабая и от глубокоуважаемой моей Магии эби рассказов, легенд и других исторических сведений о наших предках Волжско-Камских Болгарах и вообще и родной старине».

«В 1905 году я поступил учеником в медресе Мухаммадия в Казани, являвшееся в то время высшею школой для казанских татар. Посещая Центральную Мусульманскую библиотеку и читая книгу Марджани «Мустафадель-Ахбар», я узнал о письменных памятниках оставшихся от Болгарского ханства.

...Я задался мыслью найти утраченные сочинения и стал повсюду наводить справки о старинных книгах и рукописях. Пока я был учеником, ничего решительно не мог предпринять, но с окончанием школы мои разыскания пошли более энергично».

«Плачевное положение с сохранением письменных памятников. Многие из них стали добычей огня. Так, в 1880 году сгорела в дер. Иски-Режеб ценная библиотека муллы Ман-

сурова, 1910 году в дер. Семяк (Мензелинского района) превратилась в пепел другая большая библиотека. В обеих были такие ценные документы, как ярлыки татарских ханов и грамоты русских князей. Погибли также и многие другие библиотеки, например, во время пожара 1920 года в Казани библиотека татарского учёного историка Марджани. Кое-где ценнейшие исторические документы передавались на склады утильсырья» – с горестью отмечает Саид Вахиди в статье «Гибнут исторические памятники» в газете Красная Татария (1935. 2 августа (№177)).

Если бы его жизнь так трагически не оборвалась, многое бы успел он сделать на благо татарского народа.

Как отмечал академик Миркасыйм Ахатович Усманов в своей статье «Игелекле мирас» в № 5 за 1987 журнала «Казан утлары»: «Саид Вахиди был первым археографом, которому пришла в голову идея собирать рукописи среди народа. Мы являемся продолжателями его».

**Шәфигуллина Р.Ф., Казан**
**Хәйретдинов А.Г., Казан**

## КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ 130 ЕЛЛЫК КУЛЪЯЗМАСЫ: КОРЪӘН ӨЙРӘНҮ ТАРИХЫ

*Наследие Каюма Насыри и на сегодняшний день остается актуальным и востребованным, поскольку открывает для нас новые грани истории национальной и российской науки. Открытие рукописи «Мифтах аль-Куран», которая пребывала в растянувшемся на 130 лет забвении, даже для наших дней стало сенсационным. Рукопись представляет ценность для современной мусульманской науки, академического исламоведения и, в целом, для востоковедения. Уникальность рукописи «Мифтах аль-Куран» заключается в том, что она представляет собой первый в мусульманском мире конкорданс объединенных грамматически и по смыслу словосочетаний Корана. Для его создания автор применил сугубо научный подход и использовал никогда не применявшиеся в мусульманском мире методологию и принципы исследования Корана, что само по себе представляет настоящую методологическую революцию в мире исламской учености.*

Бәс, Коръән сүзләрен әлифбә тәртибендә җыеп, әһл-е исламга файдасы булсын өчен, һәм дә милләткә бер хезмәт булсын өчен ошбу китабны туплап тәртипкә салдым да, «Мифтах әл-Коръән» дип атадым.

*Габделкаюм бине Габденнасыйр, 1886 ел.*

Күренекле мәгърифәтче, педагог, әдип, энциклопедист-галим Каюм Насыйри (Габделкаюм бине Габденнасыйр, 1825–1902) халкыбызның иң мәшһүр шәхесләребезнең берсе, милләтебезнең тормышында яңа дәвер капкаларын ачкан кеше. Ул Көнбатышның прогрессив фикере белән Шәрык дөньясы казанышларын бергә үреп, үзара килештереп, татар мәгърифәтчелеген яңа баскычка күтәрде. Каюм Насыйринең мирасы бүгенге көндә дә актуаль, фән дөньясының үзәгендә, мәдәни тормышта лаеклы урын алып тора [7, s. 227–240]. Каюм Насыйринең безгә билгеле булган 40 тан артык басма хезмәте бар. Шул исемлеккә халыкта «Календарь» буларак билгеле булган, 24 ел дәвамында даими рәвештә басылып килгән фәнни-популяр альманахларын да кушарга була. Каюм Насыйри эшчәнлеге Совет еллары, хәтта соңгы дистә еллар дәвамында да дөньяви фәннәр яссылыгында өйрәнелде. Шуңа күрә Голландияле галим Микаэль Кемпернең Каюм Насыйрине татар секуляр (дөньяви) фәннәренең үзәгендә торучы галим булуын ассызыклавы да табигый [5, с. 575].

Шул ук вакытта Каюм Насыйринең мирасы һаман да серле булып кала. Бу бигрәк тә аның кульязма мирасына хас булган күренеш. Мәсәлән, әле күптән түгел генә бөек мәгърифәтченең «Мифтах әл-Коръән» («Коръән ачкычы») исемле уникаль кулъязма әсәре табылды. Әлеге хезмәт Каюм Насыйрине өр-яңа яктан ачып бирде; ислам гыйлемнәре, Коръәнне өйрәнү өлкәсендә дә гаять зур тырышлык куйган галим икәнен күрсәтте. Бер гасырдан артык вакыт үтүгә карамастан, бу хезмәт фән өлкәсендә ачыш буларак бәяләнә ала. Хәтта бүгенге көндә дә, ул шәрыкшенаслык, ислам гыйльме һәм мөселман дөньясы өчен актуальлеген һәм кыйммәтен һич югалтмаган.

Әлеге хезмәт турында без шактый соңарып белдек: дүрт ел дәвамында язылып, 1886 елның 13 декабрь аенда тәмам булган бу тиңдәшсез әсәр 130 ел дәвамында китапханә киштәсендә онытылып яткан. Кулъязманы табып дөньяга чыгаруга этәргеч бирүче исә совет татар галиме Мөхәммәт Галинең мәкаләсе

булды. М. Гали искә алынган кулъязма турында болай дип язган: «Басылмаган оригиналь кульязма китаплар арасында иң зурысы – Коръән аятьләрен эзләп табу турында, зур форматта 212 битле «Мифтахел-фөркан» исемендә зур әсәр. Насыйринең бу китабы хәзерге көн өчен үзенең әһәмиятен җуйган булса да, ләкин аның төзелү системасын әле хәзер дә файдаланырга мөмкин. Чөнки аның бу китабы буенча Коръәндәге 6000 нән артык аять яки бәетне һәм ул бәетләргә кергән аерым сүзләрне бик ансатлык белән эзләп табарга була. Безгә киләчәктә Насыйриның шушы китабында күрсәтелгән система буенча Г. Тукай яки М. Гафури кебек шагыйрьләрнең тулы җыентыкларына кергән аерым куплет, строфа, яки аерым юл шигырьләрне һәм алардагы сүзләрне эзләп табу өчен бик яхшы бер кулланма төзергә мөмкин булачак. Ул нәрсә, һичшиксез, кирәк» [3, б. 5].

Мондый кулъязманың барлыгы турында хәбәрне ишетү белән, аны табу һәм өйрәнү мәсьәләсен хәл итү башланды. Нәтиҗәдә, кулъязма Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә табылды.

«Мифтах әл-Коръән» кебек хезмәтнең барлыкка килүе Каюм Насыйринең дин әһелләре гаиләсендә тәрбияләнүенә һәм югары дини белемгә ия булуына барып тоташа [8, б. 23–27]. Мәсәлән, аның бабасы Хөсәен бине Әлмөхәммәт – Бәрәскә авылындагы (Татарстанның Әтнә районы) данлыклы мәдрәсәне тәмамлаган һәм XVIII гасырның икенче яртысыннан алып XIX гасыр башларына кадәр Олы Шырдан авылында имам вазифасын башкарган. Ә инде Хөсәен бине Әлмөхәммәт бабаның углы Габденнасыйр бине Хөсәен хәзрәт (Каюм Насыйриның әтисе), фәндә бик сәләтле булып, Казан каласында вә Бәрәскә белән Мәчкәрә (Татарстанның Кукмара районы) авылларының мәшһүр мәдрәсәләрендә дини белем алган, ислам дөньясында тирән фикерле, зирәк, киң карашлы кеше буларак танылган шәхес була [2, б. 5].

«Мифтах әл-Коръән» хезмәте – мөселман дөньясында Коръән белеме өлкәсендә дә аерым сәхифә тәшкил итә, дип әйтә алабыз. Беренче чиратта, Каюм Насыйри Коръәнне өйрәнүдә ислам дөньясында моңа кадәр булмаган фәнни тикшерену алымнарын кулланган. Әйе, Коръән белеме (голүм әл-Коръән) татарларда үзгә тарихка, үзгә эчтәлеккә ия. Бу

очракта без, нигездә, Изге китапның эчтәлеген аңлату (тәфсир) яки Коръән укылышы төрләре (кыйраәт сәбга) һәм кагыйдәләре (тәҗвид) турында сүз йөртергә тиеш булабыз. Мәсәлән, XIX гасыр – XX йөз башы аралыгында Коръән гыйлеме өлкәсендә язылган хезмәтләрне санап китсәк, татар галимнәренең түбәндәге исемнәрен искә алырга мөмкин: Габденнасыйр Курсавинең «Һәфтияк тәфсире»; Хөсәен Әмирхановның ике томлы «Фәваид» тәфсире; Мөхәммәд-Садыйк Иманколыйның ике томлы «Тәсхил әл-бәйан фи-т-тәфсир әл-Коръән» исемле тәфсире; Шәйхелислам Хәмидинең ике томлы «Әл-иткан фи-тәрҗемәтел-Коръән» атлы тәфсире; Ногманинең « Коръән тәфсире»; Камил Мотыгыйның «Татарча Коръән тәфсире» [1] һ.б.

Искә алынган хезмәтләр белән чагыштырганда Каюм Насыйринең «Мифтах әл-Коръән»е алардан тамырдан аерылып тора, чөнки галим Коръәнне өйрәнүнең бөтенләй яңа ысулын тәкъдим итә. Әлеге ысул ярдәмендә ул, беренчедән, Коръәннең кулланылышын җиңеләйтә, икенчедән Изге китап гыйбарәләрен әлифба тәртибендә урнаштырып, Коръәннең эчке фәлсәфәсен, аның биниһая тирән мәгънәви байлыгын үзләштерүнең яңа юлын тәкъдим итә. Шуңа күрә хезмәтнең «Коръәннең ачкычы» дигән исеме дә әсәрнең җисеменә туры килеп тора, чөнки аерымланып, сүзлектә тәкъдим ителгән һәрбер гыйбарә Коръәннең асыл мәгънәсен аңлау өчен ачкыч булып тора.

Шул ук вакытта Каюм Насыйри Коръәнне өйрәнүнең Көнбатыш шәркыят гыйлемендә кабул ителгән алымнарын да бик оста рәвештә кулланып, аларны Изге китапның мәгънәви һәм рухи тирәнлеген ачып күрсәтүдә үтә дә уңышлы итеп файдаланган.

Мөселман галименең хезмәте Аурупа галимнәренең дә бу өлкәдәге хезмәтләреннән аерылып тора. Аурупада Коръәннең беренче конкорданс-сүзлеге 1842 елда шәркыятьче галим Г. Флюгель тырышлыгы белән дөнья күргән. Икенче конкорданс 1859 елда атаклы русияле мөстәшрикъ Морза Казым-бәк (1802–1870) тарафыннан әзерләнә. Көнбатышның бу өлкәдә алга китүе аңлашыла да: империянең «үги балалары» булган татар гыйлем ияләреннән аермалы буларак Аурупа вә Русиянең фән вә мәгариф системасы дәүләт химаясе ышыгында көн күреп чәчәк аткан була. Әмма, каршылык вә кыенлыкларга карамастан, Габделкаюм Габденнасыйр Коръән сүзлекләре та-

рихында өченче мисал булып торган «Мифтах әл-Коръән»не төзи. Каюм Насыйриның бу хезмәте татар шәркыят белемен һәм филологиясен Русия империясе һәм Көнбатыш Аурупа фәне белән бертигез дәрәҗәгә күтәрә. Ә ислам дөньясында «Мифтах әл-Коръән», гомумән, беренче булып язылган хезмәт булып калачак. Каюм Насыйри кереш сүзендә үзе язганча: «Элек моның кебек башка китап юк иде» [5, б. 35].

Бу чыннан да шулай, чөнки мәгърифәтче галимебезнең хезмәте Аурупа галимнәренең хезмәтләреннән Коръәнгә булган мөнәсәбәт белән аерылып тора. Аурупа галимнәре Коръән сүзлекләрен төзегәндә аның текстын аерым сүзләргә таркатып, аларны әлифба тәртибенә салу белән чикләнгәннәр. Ә Каюм Насыйри исә, Коръәннең бербөтен эчтәлеккә ия булуын истә тотып, аны аерым фәлсәфи эчтәлеккә, мөстәкыйль мәгънәләргә ия булган берәмлекләрен аерып күрсәткән. Шулай итеп, Каюм Насыйри өчен Коръәннең таркатылмый торган иң кечкенә берәмлеге – коръәни гыйбарә.

Чыннан да, Коръәнне теге яки бу дәрәҗәдә белгән дин ияләре аның гыйбарәләре белән эш итәләр, аларны яттан беләләр, кирәксә, хәтта аерым аятьләрне, бербөтен сүрәләрне, Коръәннең үзен дә яттан укып чыга алалар. Үзенең сүзлеген төзегәндә Каюм Насыйри бер яктан Коръәннең таркатылмый торган бербөтен мәгънәгә ия булуын, икенче яктан инсан хәтеренең югарыда искә алынган үзенчәлеген күздә тоткан [6, б. 57–76].

«Мифтах әл-Коръән»не Каюм Насыйри махсус рәвештә Коръән белән эш итүче галим-голамәгә, хафизларга, дин әһелләренә, шәкерт-талибәләргә атап төзегән була. Әлеге хезмәтен Каюм Насыйри фәнни эшчәнлегенең иң югары ноктасы буларак: «Иҗтиһадымның иң олысы», – дип бәяләгән була. Максаты да зурдан була: «... исламга файдасы булсын өчен һәм дә милләткә бер хезмәт булсын өчен», – дип яза.

«Мифтах әл-Коръән»нең төзелеше дә үзенчәлекле – үз эченә 46200 гыйбарә сыйдырган, 28 бүлектән (баблардан) гыйбарәт булган белешмә-сүзлек. Ул бүлекләрнең исемнәре гарәп әлифбасы хәрефләре тәртибендә килә: бāб әл-һәмзәти-л-истифһāмийә (Сорау булып килгән «һәмзә» бүлеге), әл-әлиф мәѓа-л-ҁāф («Каф»лы әлиф бүлеге), әл-әлиф мәѓа-н-нӯн («Нүн»ле әлиф бүлеге). Моннан тыш автор Коръән җөзләренең

һәрберсен башлап җибәргән сүзләрне әҗзā’ү-л-кур’āн (Коръән җөзләре, ягъни өлешләре) исемле аерым бүлектә туплаган.

«Мифтахе-л-Коръән» кулъязмасы Каюм Насыйриның Коръәнне өйрәнү фәнендә тирән гыйлемле зур белгеч булганлыгын, гарәп телен камил дәрәҗәдә белүен күрсәтә. Монан тыш, әлеге кулъязмада зәвыклы нәфис сурәттә тезелеп киткән нәстәгъликъ язуы белән башкарылган хәреф вә сүзләрне күреп, без Каюм Насыйринең гарәби хат сәнгатенең чын остасы булганлыгын беләбез. Бүлек башларын кызыл төс белән башлау гадәтенең дә Борынгы Мисыр мәдәниятеннән сакланып калып, мөселман китап культурасына да үтеп кергән булуы турында әйтми калу ярамас. Хәтта «кызыл юлдан башлау», дигән гыйбарә әнә шул чал тарихка барып тоташа. Күрүебезчә, Каюм хәзрәтнең хезмәте дә борынгы традицияләрнең матур үрнәге булып тора.

